ISSN 2618-9623

Төбәк тарихы буенча журнал

Краеведческий журнал

# Туган җир

# Родной край

Специальный выпуск

2022




*Ногайның туган җиренә кайтуы*

Ногай рәссамы Алибек Койлакаев сүрәте

Бөтендөнья татар конгрессы
Татарстан Республикасы татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте

# ТУГАН ҖИР

Төбәк тарихы буенча журнал

**Махсус сан***
**2022, II**

Казан – 2022

Всемирный конгресс татар
Общество татарских краеведов Республики Татарстан

# РОДНОЙ КРАЙ

Краеведческий журнал

## Специальный выпуск*
## 2022, II

Казань – 2022

УДК 908
ББК 26.89 (2Рос.Тат)
Т 70

**Баш мөхәррир:**
Дамир Мәүләви улы Исхаков,
тарих фәннәре докторы

**Web-редактор:**
Гарифуллин Илнар Зөлфәт улы,
тарих фәннәре кандидаты

**Баш мөхәррир урынбасары:**
Борһанов Альберт Әхмәтҗан улы,
тарих фәннәре кандидаты

**Редакцион коллегия:**
Аблязов Камил
Акчурин Мәгъсум
Бәйрәмова Фәүзия
Гатауллин Ринат
Габдрафиков Илдар
Гыйләҗев Искәндәр
Закиров Ринат
Измайлов Искәндәр
Салихов Радик
Ситдиков Айрат
Сафин Фаил
Тычинских Зәйтүнә
Хисамов Олег
Шәйдуллин Рафаил

**Редакцион-нәшер итү төркеме**
***Җаваплы сәркатип:***
Сәгыйдуллина Мөнирә Хәлим кызы
***Чыгару редакторы:***
Дәүләтшина Гөлнара Фәрикъ кызы

**Главный редактор:**
Дамир Мавлявеевич Исхаков,
доктор исторических наук

**Web-редактор:**
Гарифуллин Ильнар Зульфатович,
кандидат исторических наук

**Заместитель главного редактора:**
Бурханов Альберт Ахметжанович,
кандидат исторических наук

**Редколлегия:**
Аблязов Камил
Акчурин Магъсум
Байрамова Фаузия
Гатауллин Ринат
Салихов Радик
Гилязов Искандер
Габдрафиков Ильдар
Закиров Ринат
Измайлов Искандер
Ситдиков Айрат
Сафин Фаиль
Тычинских Зайтуна
Хисамов Олег
Шайдуллин Рафаиль

**Редакционно-издательская группа**
***Ответственный секретарь:***
Сагидуллина Мунира Халимовна
***Выпускающий редактор:***
Давлетшина Гульнара Фариковна

**Басманың адресы:**
Казан шәһәре, Карл Маркс ур., 38/5
e-mail: monitoring_vkt@mail.ru
http://tatar-congress.org/ru/tugan-zhir/
http://tugan-zhir.org
Татар төбәк тарихы буенча кварталлык журнал
Татар һәм рус телләрендә

**Адрес издания:**
г. Казань, ул. Карла Маркса, 38/5
e-mail: monitoring_vkt@mail.ru
http://tatar-congress.org/ru/tugan-zhir/
http://tugan-zhir.org
Ежеквартальный журнал по татарскому краеведению
На татарском и русском языках

ISSN 2618-9623

**Туган җир:** Төбәк тарихы буенча журнал [Родной край: Краеведческий журнал]. Махсус сан [специальный выпуск], II. Казан: Бөтендөнья татар конгрессы. 2022.

## Эчтәлек

***Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары***

Дастаннардан этник үзенчәлекне саклауга. ...8

*Д.М. Исхаков.*
Халкыбызның эпик әсәрләрендә милли тарих. ...10

***Төбәк тарихы буенча фәнни мәкаләләр***

*Ф.А. Асадуллин.*
Степан Кучка Мәскәүгә нигез салучы буларак: Россиянең төрки һәм славян халыкларының үзара мәдәни багланышлар проблемасын актуальләштерү мәсьәләсе. ...171

*Р.Ф. Гатауллин, А.Г. Атаева.*
Әлмәт-Октябрьск агломерациясе *(ахыры)*. ...179

*Ә.К. Булатова, А.Ә. Бәдртдинова.*
Милли ризыкларда халык менталитеты чагылышы. ...188

***Фәнни-популяр язмаларда төбәк тарихы***

*К.С. Садыков.*
Себернең Тукуз авылында XX гасырның беренче чиреге. ...192

*Р.Р. Минһаҗ.*
Татар халык мәкальләрендә урталыкны эзләү. ...203

***Татар рухы***

*Ә.А. Зәбиров.*
Пәйгамбәребез хәдисләрендәге хакыйкать. ...207

***Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар***

Хроника. ...214

***Милли ашлар, сәламәтлекне саклау юллары***

*Ә.К. Булатова, А.Ә. Бәдртдинова.*
Азнакай төбәгенең үзенчәлекле ризыклары. ...230

*Н.И. Сәйдәшев.*
Иммунитетны ныгытабыз. ...232

## ***Юбилярлар турында сүз***

Безнең дустыбызның олы юбилее. .......................................................237

*Л.С. Хәмидуллина.*
Юбилей уңаеннан. ..............................................................................239

## ***Хушлашу***

*Ф.Ә. Бәйрәмова.*
Авыл елъязмачысы вафат. ...................................................................243

## ***2022 елда журналда басылган язмалар исемлеге***

## ***Авторлар буенча белешмә***

## Содержание

***Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения***

От дастанов к сохранению этнической идентичности. ............................8

*Д.М. Исхаков.*
Национальная история в эпических произведениях нашего народа. ....10

***Научные публикации по краеведению***

*Ф.А. Асадуллин.*
Степан Кучка как основатель Москвы: к вопросу об актуализации проблемы кросс-культурных связей тюркских и славянских народов России. ..........................................................................................171

*Р.Ф. Гатауллин, А.Г. Атаева.*
Альметьевско-Октябрьская агломерация *(окончание)*. .........................179

*А.К. Булатова, А.А. Бедртдинова.*
Отражение менталитета народа в национальных блюдах. ..................188

***Краеведение в научно-популярных публикациях***

*К.С. Садыков.*
Первая четверть XX века в сибирском селе Тукуз. ...............................192

*Р.Р. Мингазов.*
В поисках серединности в татарских народных пословицах. .............203

***Татарский дух***

*А.А. Забиров.*
Истина в хадисах пророка. ....................................................................207

***Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики***

Хроника. ..................................................................................................214

***Национальная кухня, пути сохранения здоровья***

*А.К. Булатова, А.А. Бедртдинова.*
Уникальные блюда Азнакаевского региона. .........................................230

*Н.И. Сайдашев.*
Укрепляем иммунитет. ...........................................................................232

### ***Слово о юбилярах***

Большой юбилей нашего друга. ............................................................237

*Л.С. Хамидуллина.*
В связи с юбилеем. ......................................................................................239

### ***Некрологи***

*Ф.А. Байрамова.*
Умер летописец села. ...................................................................................243

### ***Список материалов, опубликованных в журнале в 2022 году***

### ***Сведения об авторах***

**Милли һәм төбәк тарихын өйрәнүнең фәнни-методологик яклары**

**Научно-методологические аспекты изучения национальной истории и краеведения**

## ОТ ДАСТАНОВ К СОХРАНЕНИЮ ЭТНИЧЕСКОЙ ИДЕНТИЧНОСТИ

Специальный номер журнала (он является вторым таким номером. Первый был издан в 2020 г.) на этот раз посвящен татарским эпическим произведениям – дастанам, историческим легендам и преданиям, о которых в нём публикуется самостоятельное монографическое исследование. Выбор такого варианта для настоящего номера журнала «Туган җир. Родной край» объясняется тем, что в современном татарском обществе этому уникальному этнокультурному наследию наших предков уделяется явно недостаточное внимание. Речь идет не об академических исследованиях – их вполне достаточно – а о применении эпических произведений в деле сохранения и развития этнической идентичности нашего народа, требующих особых методов работы с этими уникальными источниками для доведения их содержания до широких масс, в том числе и до подрастающего поколения. То, что в этом направлении мы сильно не дорабатываем, вскрылось в ходе Международной конференции «Эпическая константа в современной культуре: проблемы сохранения и популяризации национальных эпосов» (Казань, 04.08.2022), прошедшей в рамках Года культурного наследия народов России и II Международного этно-fasion фестиваля «Стиль жизни – культурный код», когда его участники со стороны Татарстана воочию увидели, как на фоне примеров Казахстана, Кыргызстана, Азербайджана и даже Башкортостана, продемонстрировавших много удачных примеров использования дастанов в деле воспитания молодежи, наша республика не смогла представить сколько-нибудь положительные примеры подобного рода. И одна из главных причин такого положения заключается в недостаточной разработанности проблем, связанных с раскрытием исторических реалий, зашифрованных в эпических произведениях, созданных нашими предками. Выяснилось, что без такой предварительной научной работы трудно и даже вообще невозможно вести речь об использовании содержащихся в этих уникальных по богатству содержания источниках дан-

ных, способствующих формированию этнической идентичности всех поколений наших сородичей.

Кроме сказанного следует иметь в виду, что фольклорные произведения, в числе их и дастаны, являются носителями подлинного, не искаженного посторонними воздействиями, народного этнического сознания, ибо они были сформулированы самим народом или близкими к народу мыслителями. Поэтому они и заслуживают особого внимания.

При подготовке к изданию в данном номере журнала монографического труда Д.М. Исхакова, посвященного дастанам, историческим легендами и преданиям, были использованы ранее публиковавшиеся на его страницах отдельные статьи автора, которые были переработаны с целью создания целостного восприятия эпических произведений татарского народа как особого источника, содержащего весьма важные исторические знания, позволяющие упрочить идентичность наших сородичей на основе этих аналитических материалов.

*Редакция*



***Дамир Исхаков***

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭПИК ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МИЛЛИ ТАРИХ



*Ата-бабалар авазы.* Алибек Койлакаев.

**Бөтендөнья татар конгрессы**

**«Туган җир. Родной край» журналы**

***Д.М. Исхаков***

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЭПИК ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МИЛЛИ ТАРИХ

***(«Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй», «Чура батыр» дастаннарына һәм тарихи риваятьләргә анализ)***



*Казтуган һәм Любек.* Алибек Койлакаев.

**Казан – 2022**

УДК 93/94
ББК 63.3 (2 Рос=Тат)
И 91

«Туган җир. Родной край» журналы китапханәсе
«Бөек Татар иле∾Magna Tataria» сериясе

**Фәнни мөхәррире**
тарих фәннәре кандидаты З.Ә. Тычинских
**Рецензенты**
филология фәннәре докторы И.Г. Закирова

Исхаков Д.М.

И 91 Халкыбызның эпик әсәрләрендә милли тарих («Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй», «Чура батыр» дастаннарына һәм тарихи риваятьләргә анализ): монография. – Казан: ООО «Грумант», 2022. – 160 б.

ISBN 978-5-6047882-2-6

Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән бу хезмәт татар дастаннарын һәм алар белән бәйле риваять-легендаларны тарихи этнология кысаларында өйрәнү өлкәсендә милли историографиядә беренче тәҗрибә булып тора. Әсәрдә халкыбызның дүрт танылган дастаны («Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй», «Чура батыр») һәм алар белән бәйле легендар мәгълүмат анализлана. Нәтиҗә буларак милли тарихыбызның моңарчы тиешенчә өйрәнелеп бетмәгән яклары ачыкланып, шул нигездә татар җәмгыятенең XIII–XVI-нчы гасырлар арасындагы яшәешенең күп кенә якларына карата яңа карашлар формалаштырыла. Фәнни яктан әһәмиятле булган бу китап галимнәр өчен генә түгел, киң даирә укучылар өчен дә файдалы булачак.

©Д.М. Исхаков, текст
© Койлакаев Алибек, рәсемнәр

ISBN 978-5-6047882-2-6

## Эчтәлек

**Кереш**

**I-нче бүлек. «Ак Күбәк» дастаны һәм аның тирән тарихи тамырлары**

§ 1. Дастанны өйрәнү, аның эчтәлеге һәм төп геройлары.

§ 2. «Ак Күбәк» дастанының тарихи эчтәлеге һәм аңа анализ.

§ 3. Ике кабилә эзләреннән.

§ 4. Кыпчак дөньясындагы татарлар: тарихи дөреслекне торгызу юлында.

**II-нче бүлек. «Түләк һәм Сусылу» дастанында, Иске Казанга караган чыганакларда татар тарихы**

§ 1. Дастанның төп сюжеты һәм Түләкнең кемлеге мәсьәләсе.

§ 2. Түләкнең социаль статусы.

§ 3. Дастанда һәм тарихи риваятьләрдә, елъязмаларда Болгардан Иске Казанга күченү мәсьәләсе.

**III-нче бүлек. «Идегәй» дастанының серләре**

§ 1. Дастанга кереш.

§ 2. Нәрсә ул, «ал тәхет»?

§ 3. «Дәүләт кошы» турында.

§ 4. «Туктамышның дәвере»: затлы татарлар мәсьәләсе.

§ 5. Алтын Урда, Ак Урда һәм Бүз Урда.

**IV-нче бүлек. «Чура батыр» дастаны һәм «киләчәк буыннарны кисәтү»**

§ 1. «Чура батыр» дастанының кыскача эчтәлеге.

§ 2. Кем ул Чора (Шора) ~ Чура батыр?

§ 3. Чура Нарыков – «волостель», «воевода», «большой князь».

§ 3. Чура батырның үлеме һәм киләчәк буыннарны кисәтү.

§ 5. «Чура батыр» дастанының ачыкланмый калган яклары.

**Йомгак**

**Әдәбият**

## Кереш

Милли тарихыбызның төрки-татарларда сакланган эпик әсәрләрдә – дастаннарда чагылышын өйрәнү проблемасы гуманитар фән өчен яңа тема түгел. Ул турыда гомумтөрки кысада эшләгән галимнәр дә [Орлов: 1945; Мелетинский: 1963; Жирмунский: 1962; 1974; Райхл: 2008], Татарстан фольклорчылары [Урманче: 1999; 2005; Мухаметзянова: 2014] да яздылар. Беренче чиратта фольклорчылар тарафыннан башкарылган бу хезмәтләрдә, безнең уебызча, уртак бер җитешсезлек бар – төрки-татар эпослары эчендә сакланган тарихи мәгълүматларга гуманитар фәннең фольклор белеме тармагында хезмәт куючы галимнәр, шактый беръяклы карап, аларны күбрәк төрле фольклор сюжетларын аңлату өчен генә кулландылар. Дөрес, аерым очракларда башкарылган тикшерүләрдә киңрәк карашлар да очрый, мәсәлән, В.М. Жирмунский хезмәтләрендә. Әмма, барыбер фольклорчылар дастаннарда чагылган тарихи информациягә ярдәмчел материал итеп кенә карап килделәр һәм киләләр. Фольклор гыйлеме белән шөгыльләнгән галимнәрнең фәнни методикалары да тарихчыларныкыннан аерыла, шуңа күрә алар тарих фәне өчен әһәмиятле булган дастаннар эчендәге информацияне еш кына читтә калдыралар. Шуның өстенә, аларга күп очракта тарихчыларның яңа документаль табышлары һәм концептуаль ачышлары таныш түгел, ә алар исә халкыбызның эпик әсәрләрендәге тарихка бәйле мәгълүматка башка төрлерәк, яңача карарга мөмкинлек бирәләр.

Чынлыкта исә эпик әсәрләргә тарих фәне күзлегеннән караганда, аларда булган, әмма элек игътибардан читтә калып килгән, гуманитар өлкә өчен әһәмиятле фактик материалларны абайларга мөмкин. Шушы шактый четерекле тикшеренүгә алынуыбызның беренче сәбәбе нәкъ менә төрки-татарларның дастаннарындагы тарихи яктан кызыклы, әмма моңарчы фольклорчылар тарафыннан анализланмаган мәсьәләләрне күтәрү теләге булды.

Тарихчы-этнолог буларак башкарылган һәм сезнең каршыгызда яткан хезмәтнең барлыкка килүенең тагы бер сәбәбе бар. Ул – милли тарихыбызның чыганаклар нигезен киңәйтергә омтылу. Эш менә нәрсәдә: татар халкының тарихына кагылган документаль чыганакларның күпчелеге башка халыклар тарафыннан язылган ядкарьләр һәм без үзебезнең милли тарихыбызга берникадәр дәрәҗәдә читләр карашларыннан чыгып бәя бирергә мәҗбүрбез. Билгеле, чыганакларга фәнни тәнкыйть ясап күрсәтелгән фундаменталь кимчелектән күпмедер дәрәҗәдә котылу мөмкин, ләкин тарихчыларыбыз каршында барыбер халкыбыз үзе тудырган тарихи мәгълүматның күләмен арттыру проблемасы тора. Ә мондый информация – кайбер очракларда ул уникаль характерда да булырга мөм-

кин – дастаннар эчендә сакланган, аларны аннан эзләп табып, «чүпләп» ала белү генә кирәк. Шулай итеп, хезмәтебезнең икенче бер бурычы – татар халкы тарихын тулыландыру өчен кирәк булган чыганаклар компендиумын дастаннарда булган мәгълүмат нигезендә киңәйтү. Бу мөмкин, ләкин аның өчен фәндә моңарчы кулланылмаган (шул исәптән, яңа методологик нигез булмау сәбәпле дә) яисә аз кулланылган ысулларны эшкә җигү кирәк. Ул турыда әле алда аерым рәвештә әйтелер. Хәзер исә башка бер мәсьәләгә тукталып китик.

Күп кенә тарихчылар, традицион язма чыганаклар белән эш итәргә күнеккәнлектән, фольклор әсәрләрен аерым төр тарихи чыганак итеп куллану мөмкинлеген инкарь итәләр. Әмма, бу караш, чынлыкта, ялгыш, чөнки башка бер төркем галимнәрнең, күбрәк Көнбатыш тарихчыларының хезмәтләрендә, аларны анализлап кызыклы нәтиҗәләр ясау тәҗрибәсе билгеле (мисал өчен инглиз телендә басылган һәм татар тарихы белән бәйле америка тарихчысы Девин Де Виз монографиясен күрсәтергә була: [De Weese, Devin: 1994]). Ләкин эпик әсәрләр, риваять / легендалар тарихи чыганакка әйләндерелгәнче шактый эш башкарырга кирәк. Шул өлкәдә иң әһәмиятлесе – аларның төрле версияләрен чагыштырып өйрәнү. Иң элек конкрет халык эчендә язып алынган вариантларны, аннан соң төрле тугандаш халыклар арасында таралган милли версияләрне барлап чыгу кирәк. Шушы күп көч таләп иткән фәнни-текстологик эшләрне алып бару аркылы гына без эпик әсәрләрнең беренчел (аутентик) текстларын торгыза алабыз. Моннан башка эпик әсәрләргә читтән килеп кергән, еш кына аларны язып алган галимнәр тарафыннан текстларны «яхшырту» теләге белән өстәлгән өлешләрне эзләп табу да таләп ителә. Бәхеткә каршы, күпчелек очракта күрсәтелгән методик эш инде фольклорчылар тарафыннан башкарылган. Әмма, кайбер очракларда ул юнәлештә эшләнгән фәнни-аналитик хезмәт җитәрлек булмаска мөмкин, шунлыктан, берникадәр дәрәҗәдә шул специфик өлкәгә дә керергә туры килә.

Татар фольклорын тарихи чыганак итеп куллану мөмкинлеген исбат итү өчен безнең тарафтан дүрт эпик әсәр сайлап алынды: «Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй» һәм «Чура батыр» дастаннары. Алар төрле дәверләргә карыйлар һәм жанр ягыннан да аерылалар. «Түләк һәм Сусылу» дастаны, калган өчесеннән аермалы буларак, «героик-мәхәббәт» яки «мәхәббәт» (романтик) дастаннары төркеменә кертелә торган эпик әсәр (башка төрки халыкларда да андый дастаннар бар, мәсәлән, бу уңайдан үзбәкләрдә яшәп килгән «Ширин һәм Шакар» дастанын атарга була [Жирмунский, Зарифов: 1947. С. 132–143]). Аның барлыкка килү вакыты XIV-нче йөзнең икенче яртысы булса кирәк. Ләкин, «Түләк һәм Сусылу»

дастаны борынгырак эпик әсәрләрнең һәм сюжетларның бер өлешен дә үзенә «сеңдергән» дип уйлыйбыз, чөнки аның эчендә вакыт-вакыт көнчыгыш кыпчаклар (төгәл исемнәре – кимак / йәмәкләр, (алар турында карый аласыз: [Исхаков: 2018-в]) белән бәйле булган монголлар Идел буен яулап алу алдыннан (1230-нчы еллар) яшәгән шәхесләр һәм этник төркемнәр дә күренеп китәләр (карагыз: [Исхаков: 2011; 2018-в]). Шуңа күрә дә кайбер татар фольклорына багышланган теоретик хезмәтләрдә бу дастанны «архаик» характердагы героик дастаннар рәтендә карыйлар [Урманчеев: 1984. С. 69].

«Ак Күбәк» дастаны төп сюжет үзенчәлекләре буенча, һичшиксез, героик дастаннар рәтендә каралырга тиеш, чөнки аның төп геройлары «алыплар» буларак билгеләнәләр, сугыш хәрәкәтләре алып баралар, яхшы коралланган һәм нык характерлы шәхесләр итеп тасвирланалар. Эчтәлек үзенчәлекләре ягыннан бу дастан монголлар дәверенә кадәрге Дәште-Кыпчак далаларында яшәгән кыпчаклар белән бәйләнеп каралырга тиеш. Шунлыктан, «Ак Күбәк» эпосының барлыкка килү вакытын XIII гасырга карый дип уйларга кирәк [Исхаков: 2021]. Иртә формалашканга күрә, дастанда архаик элементлар да сакланган (угыз эпосы герое «Салыр Казанны» искә алу, Ак Күбәкнең ана карынында ук сөйләшә башлавы, эпоста 40 кыз турында хәбәр бирүләр һ.б.). Дөрес, моннан чыгып кына без «Ак Күбәк» эпосын архаик дастаннар рәтендә карый алмыйбыз, чөнки башка төп үзенчәлекләр буенча, югарыда әйтелгәнчә, ул героик дастаннар белән бергә санала ала.

«Идегәй» дастаны, фольклорчыларның уртак фикерләре буенча [Жирмунский: 1974. С. 374, 374 һ.б. битләр; Урманче: 1999. С. 187–89; Эдиге: 2016. С. 9–10], XV-нче йөзнең беренче яртысында яисә бераз соңрак дәвердә формалашкан. «Чура-батыр» дастаны исә аннан бер гасырдан соң барлыкка килгән, дип уйланыла (карагыз: [Ибраһимова: 2002. 140 б.; Урманче: 2005. 273 б.]) Бу соңгы ике эпик әсәр дә «героик дастаннар» рәтенә кертелә ала [Жирмунский: 1962. С. 201; Эдиге: 2016. С. 17; Ибраһимова: 2002. 58 б.]. Әмма бернәрсәне онытырга ярамый – алар арасында булган гасырга якын дәвер эчендә төрки-татар дөньясында инде зур үзгәрешләр барлыкка килә. Шуңа күрә дә «Идегәй» эпосында әле кайбер архаик элементлар күренсә, «Чура-батыр» дастанында андый үзенчәлекләр юк диярлек (казакъларда булган дастан версияләрендә генә алар бераз сакланган). Димәк, бу ике эпик әсәр бер үк типтагы дастаннар исәбендә йөрсә дә, алар стадиаль үсеш ягыннан төрле баскычта торалар (ул проблема турында тулырак карый аласыз: [Мелетинский: 1963. С. 365; Жирмунский: 1962. С. 332]). Әйтелгән үзенчәлекләрне искә алырга туры килә, чөнки төрле чорларга караган эпосларда чагылыш тапкан тарихи информация

бер үк дәрәҗәдә тулы була алмый, шуңа күрә дә теоретик хезмәтләрдә тарихилык буенча төрле дәвер дастаннары бер-берсеннән аерылалар, дип карала [Жирмунский: 1962. С. 232].

Әйтелгән эпик әсәрләрне анализлаганда тарихи легенда / риваятьләр һәм шәҗәрәләр дә кулланылды. Алар турында тулырак итеп китапның теге яки бу дастанга багышланган өлешләреннән белергә була. Ул материаллар инде шактый вакыт өйрәнелә (карагыз: [Шпилевский: 2012; Атласи: 1992; Татар халык иҗаты: 1987; Ахметзянов: 1991; Исхаков: 1998; 2013-б]), ләкин, татар гуманитар фәнендә алар әле систематик рәвештә тикшерелмәгән килеш калып килә. Шуңа күрә дә шушы үзенчәлекле чыганакларны фәнни әйләнешкә кертү аркылы, без аларның тарихи потенциалын да күрсәтергә омтылдык. Ә бу исә алга таба мондый төр чыганакларны тарихи хезмәтләр язганда кулланып булганлыгын өстәмә рәвештә нигезләргә мөмкинлек тудыра, аларның милли-мәгълүмати кырны киңәйтә алганлыгын дәлилли.

# I-нче бүлек

# «Ак Күбәк» дастаны һәм аның тирән тарихи тамырлары



*Толпар.* Алибек Койлакаев.

## § 1. Дастанны өйрәнү, аның эчтәлеге һәм төп геройлары

«Ак Күбәк» дастаны В.В. Радлов тарафыннан себер татарларының *тобол* һәм *бараба* төркемнәрендә язып алынган [Образцы: 1872. Ч.IV. С.45–48]. Башкачарак версияләрдә ул хакасларда (элекке атамалары «абакан татарлары» булган *сагай* төркемендә) [Образцы: 1907. Ч.IX. С.392–393] һәм алтайлыларда (*алтай кеже / алтай кеше*) да булган [Образцы: 1866. Ч.I. С.204–212]. Шушы исемдәге тагы бер әсәр («әкият» дип билгеләнгән) П.А. Фалёв тарафыннан ногайларда табылган [Фалёв: 1918]. Әмма эчтәлеге буенча ул эпик әсәргә охшамаган һәм, гомумән, исеменнән тыш («Ак Кобек – Кара Кобек») безне кызыксындырган дастан белән аның бернинди уртаклыгы да юк ахрысы. Бүгенге көнгә безгә «Ак Күбәк» дастаны В.В. Радлов бастырган текстлардан тыш, алдагы галимнең материалларын файдаланган Н.Ф. Катанов нәшер иткән вариантларны [Образцы: 1907. С.392–393], аның себер татарларында язып алынган версияләренең хәзерге татар әдәби телендәге һәм русча тәрҗемәләрдәге [Ак Кӳбӓк: 2014. Б.403–413; С.423–433] текстларын кулланырга мөмкин.

Дастан галимнәр тарафыннан шактый тулы өйрәнелгән [Потанин: 1893; Урманчеев: 1977; 1984; 2002; Әхмәтова: 1978; Закирова: 2009; 2011]. Әмма эчтәлегендәге тарихи мәгълүматларны билгеләү юнәлеше буенча бу дастан аз тикшерелгән. Дөрес, үз вакытында ул яссылыкта башта Г.Н. Потанин [Потанин: 1893], аннан соң, аның йогынтысында, П.А. Фалёв бераз язганнар иде. Хәзерге вакытта исә әйтелгән юнәлештә башкарылган хезмәтләр рәтендә казакъ тарихчысы А.К. Кушкумбаев мәкаләсен [Кушкумбаев: 2018] һәм Д.М. Исхаков [Исхаков: 2021] язмасын гына атарга була.

Шул ук вакытта, «Ак Күбәк» эпосында яшеренгән тарихи эчтәлекне ачу бик кирәк, чөнки аның аркылы безгә шушы дастан барлыкка килгән дөньяның этномәдәни тамырларын табу гына түгел, ә кайбер Көньяк Себердә һәм Алтай төбәгендә монголлар күтәрелү алдыннан яшәгән көнчыгыш кыпчаклар һәм алар белән бәйле башка төрки, шулай ук төрки булмаган төркемнәр турында яңа фикерләр әйтү мөмкинлеге дә туа.

Үз вакытында Г.Н. Потанин, күренекле тюрколог В.В. Радлов язып алган «Ак Күбәк» дастаны вариантларында чагылган вакыйгаларның гарәп тарихчылары ан-Нувайри (1279–1333) һәм Ибн Халдун (1333–1406) хезмәтләрендәге тарихи эчтәлекле легендар текстлар белән бәйлелеген, күрсәткән иде. Тикшерелә торган эпосның төп сюжетларының ничек итеп көнчыгыш җирләреннән гарәпләргә килеп җитүе турында уйланып, ул мондый нәтиҗә ясый: «...бу әкиятләр Көньяк Россиядәге кыпчакларда яшәп, аларны мисырлы <башта> шунда ишеткән. Ә аннан инде ул сюжетлар җиңел генә кыпчаклардан башка күрше кабиләләргә күчә алганнар»

[Потанин: 1893. С. 123]. П.А. Фалёв та шундыйрак фикер әйтә [Фалёв: 1918. С. 196]. Алга таба «Ак Күбәк» дастанын өйрәнүчеләрдә моның ише фикерләр гомуми бер карашка әйләнеп китте, әмма «Көньяк Россия» һәм Мисыр арасында нинди озын юл булуын истә тотсак, бу эпик әсәрнең кыпчакларны тыңлап торган мисырлы аркылы җиңел генә гарәпләргә барып җитүен инде расланган факт дип түгел, ә бер гипотеза буларак кына карарга кирәк.

Билгеле, «Ак Күбәк» дастанындагы сюжетларның XIII–XIV йөз башлары гарәп тарихчыларына барып ирешү сәбәпләрен конкрет ачып салу кирәк. Казакъ тарихчысы А.К. Кушкумбаев, мәсәлән, ан-Нувайри һәм Ибн Халдун әсәрләренең тарихи контекстын өйрәнгәндә берникадәр әһәмиятле күзәтүләр ясаса да, әлеге мәсьәләгә тулы рәвештә җавап бирмәде [Кушкумбаев: 2018. С. 80–81]. Шул ук вакытта, элекке язмабызда без ул юнәлештә фикерләр туплаган идек [Исхаков: 2021].

Башта безгә А.К. Кушкумбаев башкарган анализга тукатлып китү кирәк. Казакъларда билгеле Кобланды-батыр шәҗәрәсен тикшергәндә – ә ул *кара-кыпчак* (казакъча – *кара-кыпшак*) ыруыннан булган – тарихчы күрсәткәнчә, анда Аккобік дип билгеләнгән буын барлыгы күренә. Шушы шәхес белән бәйле рәвештә А.К. Кушкумбаев, югарыда күрсәтелгән П.А. Фалёв хезмәтенә дә таянып, Ак Күбәккә бәйле тарихи материалларны барлап чыгып, шушы эпик геройның («алыпның») алтайлыларда, бараба татарларында һәм ногайларда язып алынган дастан вариантларында да булганлыгын әйтә [Кушкумбаев: 2018]. Шул ук вакытта, аның төп фикерен – бу дастанның монголларга кадәрге кыпчак дөньясына караганлыгын – кабул итеп, кулланылган тарихи материалларын һәм аларның интерпретациясен дөрес дип тапсак та, безнең фикеребез буенча, А.К. Кушкумбаев анализыннан төшеп калган аерым, ләкин әһәмиятле, яклар да бар. Безнең бурычыбыз, нәкъ менә шушы кыпчакларның иртәрәк дәвер тарихы һәм ул тарихның Ак Күбәк белән бәйле өлешләрен яңадан тикшереп, ул турында анык кына фикерләр әйтү булыр. Дөрес, тарихи мәгълүматлар чикләнгән булу сәбәпле, Ак Күбәк дастанын тикшергәндә безгә дә Г.Н. Потанин, П.А. Фалёв һәм А.К. Кушкумбаев кулланган тарихи чыганакларга таянырга туры киләчәк. Әмма алардан аермалы буларак, без эпик материалларны, бигрәк тә татарларда язып алынган «Ак Күбәк» дастанындагы өлешләрне, актив кулланачакбыз. Мондый ысул исә эпосны тикшергәндә яңа мөмкинлекләр ача.

Башта «Ак Күбәк» дастанының кыскача гына эчтәлегенә тукталып китү кирәк булыр.

Эпоста әйтелгәнчә, бер шәһәрдә Ак Бытык бинең улы туа, аңа «Ак Күбәк» дигән исем бирелә (бу исем турында карагыз: [Фалёв: 2018]).

Би угълының могҗизалы сыйфатлары туганчы ук күренә: ул анасы карынында ятканда ук сөйләшә башлый, ә тугач, кечкенәдән үк бик көчле була, үсеп җиткәнче үк кешеләрне үзенең туена чакырып йөри һәм шул вакытта Кидан исемле ханга юлыга. Ханга Ак Күбәк охшамый, шунлыктан ул үзенең угълы – Мангуш солтанга аны үтерергә куша. Мангуш аны үтерергә җиңелерәк булыр дип ауга чакыра. Солтан хәйлә белән хәрәкәт итә – Ак Күбәктән бер-бер артлы башта атын (*ур кулак, ат*), аннан этен һәм кошын үзенә бирүне таләп итә. Әмма дастан герое аларны бирүдән баш тарта, ә солтан, эш барып чыкмагач, аның кылычын һәм быргысын тартып алырга тырыша, ләкин бусы да тормышка ашмый. Шулай тарткалашып, алар бер тау янына килеп җитәләр, шунда Мангуш дастан героена мондый тәкъдим ясый: кем беренче булып тауны әйләнеп чыкса, шул соңга калучының башын чабып өзәргә хаклы булачак. Ләкин хәйләкәр Ак Күбәк үзенең сеңлесенә 40 кыз белән мәҗлес ясап, шунда Мангушны тоткарларга кирәклеген әйтә һәм тегесе исереп йоклап ятканда, ул анда килеп керә дә, төрле гореф-гадәтләрне тотып, аның башын кисеп, өенә кайтып китә. Шул вакытта Кидан хан угълының ни хәлдә икәнен белергә дип бер илче җибәрә, ә аның үлгәнлеген («*Манар тауда йорт тапканлыгын*») ишеткәч, гаскәр белән Ак Күбәккә каршы юнәлә. Хан гаскәрендә легендар «Салыр Казан» (угызларның эпик герое!) һәм безгә билгесез «Буйдар алып» та булалар. Ханның үзен дә дастан «алып» дип билгели. Салыр Казан Ак Күбәкне үтерергә тырышып карый, ләкин төрле хәйләләр белән би угълы аның үзен үтереп, башын кисеп алып, хан гаскәренә бәреп керә, шул вакытта Кидан хан аңа сөңгесен кадый. Яраланган Ак Күбәк өенә кайтып китә, анда үзенең туганыннан аны кабергә күмеп куюны сорый, җомга көненә кадәр тимәскә куша. Ләкин тегесе аны билгеләнгән көннән иртәрәк уята, шул сәбәпле Ак Күбәк яңадан кабергә кереп ята да, үлә. Аның үлеменнән соң Кидан хан дастан героеның туганы белән орыша, әмма аннан соң алар тынычланалар һәм дошманлыкны онытарлар.

Эпик әсәрнең төп сюжеты менә шундый. Билгеле, бу бик катлаулы эчтәлекле дастан түгел. Шулай булса да, дастанда әһәмиятле мәгълүмат яшеренгән, әмма аны тиз генә чамалап булмый. Шунлыктан, безгә башта эпоста хәрәкәт итүче шәхесләргә игътибар итү кирәк.

Беренче чиратта безне Кидан (төрки формалары Кидән / Китән / Котән булырга мөмкин) хан, Ак Бытык бинең угълы Ак Күбәк һәм хан угълы Мангуш (төркичә исеме – Мәнкош / Манкош булыр) солтан исемнәре кызыксындырырга тиеш, чөнки нәкъ шул исемнәр гарәп елъязмачыларында да бар. Угызларның «Дәдә Коркыт китабы» әсәрендәге Салыр Казанны әлегә читтә калдырып торыйк (гарәп елъязмаларында аның исеме

юк). Гарәп чыганакларында һәм дастанда бер үк шәхесләр турында сүз барганлыгында безнең икеләнүләр юк, аның шулай икәнлеген исбат итү өчен елъязмаларга мөрәҗәгать итик.

## § 2. «Ак Күбәк» дастанының тарихи эчтәлеге һәм аңа анализ

«Ак-Күбәк» дастанының эчтәлеге белән төп сюжетлар буенча туры килүче хәбәрне бирүче ан-Нувайри, Аккубуль (Ак Күбәк исеменең чагылышы) дигән шәхеснең Котан хан тарафыннан җиңелүе турында язгач, мондый вакыйганы тасвирлый. Ансар (Унсар) атлы Аккубульның туганы Душиханга (ягъни, Җучига) үзләренең дошманнары булган *дурут* кабиләсе вәкилләренә һөҗүм итүләрен үтенеп килә, ә алар җиңелгәч, чыганакта мондый нәтиҗә ясала: «... <Души / Җучи> ... аларның күпчелеген үтерде һәм әсирлеккә алды. Шул вакытта сәүдәгәрләр аларны <әсирләрне> төрле шәһәрләргә һәм җирләргә китерделәр» [История Казахстана: 2005. Т. I. С. 65]. Кайбер үзгәрешләр белән бу хәбәр Ибн Халдунда да бар. Иң кызыгы, андагы хәбәр менә мондый бик үзенчәлекле өлеш белән тәмамлана: «...барлык санап кителгән кабиләләр (алар турында алга таба әйтеләчәк – Д.И.) – бер тамырдан түгел һәм Мисырдагы төркиләр – кыпчаклардан» [Шунда ук]. Аңлашыла – әйтелгән тарихи чыганакларда сүз мәмлүкләр турында бара һәм бу ан-Нувайрины куәтләүче соңрак чорда яшәгән гарәп тарихчысы ал-Айни (1361–1451) язмасыннан бик ачык күренә: «...Әсирлеккә төшкәннәр (алар арасында кыпчаклар да – Д.И.) ...Сүрия һәм Мисыр җирләренә җибәрелделәр. Нәкъ алардан мәмлүкләр барлыкка килделәр...» [Шунда ук: С. 350].

Нәтиҗәдә, мондый эшче гипотеза барлыка килә: «Ак Күбәк» дастанында булган сюжетлар гарәп елъзмаларына әсирлеккә эләгеп, гарәп биләмәләренә, беренче чиратта, Мисырга җибәрелгән кыпчак мәмлүкләре хатирәләре аркылы килеп кергәннәр булыр. Ләкин, аларда сакланган легендар хатирәләр кайчан дастанга әверелгәнен чамалау өчен һәм алардагы мәгълүматларда нинди тарихи яктан дөрес информация булганлыгын билгеләү өчен, безгә гарәп елъязмаларындагы хәбәрләрне «Ак Күбәк» дастанының, беренче чиратта, аның татар вариантларындагыларын, чагыштырып өйрәнү кирәк.

Гарәп энциклопедисты ан-Нувайри 30 томлык «*Нихайт ал-араб фи фунун ал-адаб*» (башкача атамасы – «*Мунтаха ал-араб фи‘илм ал адаб*») исемле 725 х.е. (1324/1325) кадәр җиткерелгән хезмәтеннән башлыйк. Андагы «Төрки эшләр турында» дип аталган бүлектә мондый мәгълүмат бирелә: 616 х.е. (1219/1220) булган походтан «Көнбатыш татарлары» ягъни, татар-монголлар, үз юлбашчылары янына әйләнеп кайтканда элек ул поход вакытында качкан «төркиләр» (беренче чиратта кыпчаклар – Д.И.), 626 х.е. (1228/1229) үзләренең «Төньяк җирләрдәге урыннарына» кы-

елдылар. Ахрысы, соңгы очракта Субәдәй-бахадур җитәкчелегендәге монголларның икенче походы турында сүз бара, ә ул һөҗүм, билгеле булганча, кыпчак җирләренә, бигрәк тә көнбатыш кыпчакларга, аз йогынты ясаган. Менә шушы хәбәрне биргәндә, ан-Нувайри күрсәтелгән «төркиләрнең», ягъни, кыпчакларның, кабилә составлары турында мәгълүмат китерә, анда сүз 11 кабилә турында бара: 1) Токсоба, 2) Йета, 3) Бурджоглы, 4) Бурлы (Илбарлы / Елбарылы), 5) Кангуолы (Кангароглы), 6) Анджоглы, 7) Дурут, 8) Карабороглы (яисә, Кулабаоглы / Колабаогли), 9) Джузнан (Джортан / Чертан), 10) Карабирикли, 11) Котян [Шунда ук. С. 63–61]. Алга таба бу автор безнең өчен бик әһәмиятле булган хәбәр китерә: «... [Бер заман] мондый вакыйга булды – Котян угълы булган Мангуш исемле дурут кабиләсеннән булган кеше ауга чыккан һәм анда аны токсоба кабиләсеннән булган Аккубуль атлы кеше очраткан, а аларның кабиләләре арасында борынгыдан барган үзара көндәшлек күзәтелгән, нәтиҗәдә, ул <Мангушны> әсирлеккә алган һәм үтергән. Мангушның әтисенә һәм аның кешеләренә бу турыда хәбәр барып ирешмәгән, алар Джангар (Джалангар) атлы кешене тикшерү өчен җибәргәннәр. Ул кайтып аның үтерелүе турында хәбәр иткән. Шуннан соң <Мангушның> атасы үзенең кабиләсен һәм кешеләрен җыеп Аккубульга каршы киткән. [Тегесе] ... үз кабиләсе вәкилләрен җыеп, сугышка әзерләнгән ... Алар сугышканнар ..., җиңү дурут кабиләсе ягында булган. Аккубуль үзе яраланган, аның гаскәрләре таралган. Шул чакта ул (Аккубуль) үзенең Ансар (Унсар) исемле туганын Душиханга җибәргән, ә аны исә Укедийа ... Төньяк илләренә юллаган булган. <Аккубуль> аңа <ягъни, Душиханга> үзенең халкына кыпчакларның дурут кабиләсе ягыннан нәрсә эшләнгәнлеге турында зарланган һәм әйткән: әгәр дә <Душихан> алар өстенә барса, анда <дурут кабиләсеннән> башка берәүне дә очратмаячак, – дип. Шунна соң <Душихан> алар өстенә гаскәр белән килгән, һөҗүм иткән ...» [Шунда ук. С. 65]. Кайбер үзенчәлекләр белән бу хәбәр Ибн Халдунда (1406 елны үлгән), аның «*Китаб ал-‘ибар ва диван ал-мубтада’ ва-л хабар фи аййам ал ‘араб ва-л‘аджам ва л‘аджам ва-л-барбар*» исемле хезмәтендә дә бар. Аның хәбәрендә Котян угълы Мангуш «Китмир угълы Мангуш» дип, ә аның көндәше – Акакийак, Джамгур-Джалланнар, Ансар-Аксар буларак аталалар [Шунда ук. С. 66]. Бу элекке текстларны күчерү вакытында ясалган ялгышлар булса кирәк. Ә аның тагы бер игътибарга лаек хәбәре мондый: «... дурут кабиләсе кыпчаклардан, ә токсоба <кабиләсе> – татарлардан» [Шунда ук. С. 65].

Элегрәк чыккан хезмәтләрдә (карагыз: [Шунда ук. С. 64] инде ан-Нувайри һәм Ибн Халдунда китерелгән кабилә исемнәренең Дәште-Кыпчакта яшәгән көнбатыш кыпчакларга караганлылыгы турында язылган

иде. Бу шулай булырга охшый. Ләкин безне күбрәк гарәп чыганаклары белән «Ак Күбәк» дастанының эчтәлегендәге уртаклыклар кызыксындыра. Алар шактый.

Беренчедән, дошманлашкан затлы кыпчакларның исемнәренең туры килүе: Мангуш ~ Манкош б. Котян (Китән) һәм Ак Күбәк (Ак Кубул) / Ак Кийак). Икенчедән, Котянның илчесенең исеме дә якын формада бирелә – гарәп чыганакларында Джангар / Джалангар (төрки формасы Чамгар / Чалангар булыр), ә дастанда – Чылак. Өчечедән, эпоста исеме аталмаган Ак Күбәкнең туганы (энесе, я абыйсы) күренә, ул Ак Күбәк үлгәч Котян хан белән сугыша. Ан-Нувайри буенча да Ак Күбәкнең Ансар / Унсар исемле туганы булганлыгы билгеләнә. Дөрес, анда ул Котян белән сугышмый, ә Җучига зар белән килә, аның гаскәрен дурут кабиләсе өстенә юнәлтә һәм аларның җиңелүенә ирешә. Бишенчедән, эпик һәм тарихи Ак Күбәк каты яраланалар. Алтынчыдан, Мангуш һәм Ак Күбәк беренче мәртәбә ау вакытында очрашалар.

Охшашлыклар җитәрлек булсалар да, елъязмаларда «Ак Күбәк» дастаны белән чагыштырганда анда чагылыш тапмаган мәгълүматлар да бар: Котян ханның һәм аның угълы Мангушның дурут кабиләсеннән, ә Ак Күбәкнең – токсоба кабиләсеннән булганлыгы турында һәм ул кабиләләрнең төрле этник тамырлардан икәнлеген күрсәтү буенча (дурут кабиләсе – кыпчаклардан, токсоба кабиләсе – татарлардан).

Безнең фикеребезчә, гарәп елъязмаларында китерелгән информация кыпчак мәмлүкләре аркылы эләккән һәм ул дәвердә алар арасында кабиләләргә бүленү әле әһәмиятле булган. Әмма, бу информация аерым тикшерүне сорый, чөнки ул кыпчакларның көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләргә бүленеп, аларның этник тамырларының, бердәм кыпчак дөньясына карасалар да, бер үк булмаганлыгы турында сөйли. Без әле ул мәсьәләгә әйләнеп кайтырбыз, ләкин аңарчы Котян (Кидан) ханның, аның угълы Мангуш солтанның һәм аларның көндәше булган Ак Күбәк бинең тарихи прототипларын эзләп табу кирәк.

Эпик һәм елъязмалардагы Кидан / Котян хан шактый ышанычлы рәвештә көнбатыш кыпчаклар арасында билгеле булган, монгол яулары Көнчыгыш Европага һөҗүм алып барганда үзенең 40 меңлек урдасы белән 1237-нче елны Венгриягә күчеп киткән, Котян хан белән тәңгәлләштерелә ала [Плетнева: 2010. С. 125]. Аның Галицки биләмәсе кнзе Мстислав Мстиславовичның (1228-нче елны үлгән) каенатасы булганлыгы да билгеле. Соңгысы аны Галицки Русенә каршы котырта (1226-нчы ел), аннан соң аны 1228-нче елны Киев кнзе Владимир үз мәнфәгатьләрендә куллана, ә 1235-нче елны Котян хан тагы Галицки Русена һөҗүм ясый [Шунда ук. С. 181]. Бу мәгълүматлардан күренгәнчә, аның

урдасы борыңгы рус кенәзлекләре җирләренә якын төбәктә яшәгән. Кенәз Мстислав белән туганлашып өлгергән (ул вакытта мондый элемтәләр нык таралган булган) Котян ханның биләмәсенең үзәген дурут (төркичә «дүрт» булыр төгәл атамасы) кабиләсе тәшкил иткән дип уйларга урын бар. Алар көнбатыш рус җирләренә якын урында хәрәкәт итеп, 1230-нчы еллардагы монголлар походы вакытында гомумән Венгриягә күчеп китү сәбәпле, без бу төркем кыпчакларны көнбатыш кыпчак (куман / половцы) берләшмәләре эчендә карый алабыз.

Шунысын да билгеләп үтик: венгр короле Бела IV (1206–1270) варисы Стефан чукынган, Елизавета исеме алган, Котян ханның кызына өйләнә, ә хан үзе кабиләдәшләре белән Венгрия корольлегендә «dominus Cumanorum» / «Куманнар хөкемдары» дигән титул астында берникадәр вакыт тыныч кына яши. Ләкин ахырда Котян хан кыпчаклары аксөяк венгрлар белән конфликтка кереп, 1241-нче елны баш күтәреп, Болгариягә күчеп китәләр, ә хан үзе фетнә вакытында үтерелә. Ләкин, 1246-нчы елны монголлар ягыннан куркыныч көчәю шартларында бу кыпчакларны кире Венгрия корольлегенә чакыралар һәм алар шунда утырып калып акрынлап христианлашалар һәм ассимиляция кичереп, шактый вакыттан соң, венгрлар составына кереп китәләр [Horváth: 1989. PP. 48–50].

Котян ханның угълы Мангуш (Манкош) турында башка тарихи мәгълүматлар табып булмады. Ләкин, Мангуш (Манкош) исеме, кыпчак мирасы буларак, Алтын Урда татарларында һәм аларның варисларында XIV-нче гасырда һәм соңрак та билгеле. Мәсәлән, шушы исемдәге Үзбәк ханның илчесе, 1314/1315, аннан 1320, 1321/1322, 1323/1324-нче елларда Мәмлүк Мисырында «тынычлык» һәм «гаилә кору» буенча сөйләшүләрдә катнаша [История Казахстана: 2005. Т. I. С. 243, 246, 310, 315, 362, 364, 380]. Бәлки ул сөйләшүләргә аерым рәвештә нәкъ менә кыпчаклардан булган шәхес җибәрелгәндер. Шулай ук, 1624–1626-нчы елларда Рус дәүләтенең Алатыр өязендә Мангушев фамилияле татар кенәзләре билгеле (алдагы елларда аларга нисбәтле рәвештә Мангушево атлы авыл да барлыкка килә). Бу шәхесләрнең нәсел җебе Мангуш кенәзгә тоташа булыр [Акчурин, Ишеев, Абдиев: 2021. С. 217–218]. Алтын Урда татарларыннан булган этник компонент зур роль уйнаган мишәрләрдә мондый исем саклану очраклы түгел. Аннан соң, Мангуш атамасы бер зур гына торак пункты исеме буларак көньяк-көнчыгыш Украинада да бар. Ә менә башкортларда сакланган кыпчак ыруының шәҗәрәсендә Мунаш би билгеле [Башкирские: 2016. С. 138–139]. Бу исем дә «Монкаш / Манкош» исеменнән барлыкка килгән булырга мөмкин (башкорт телендә «к/г» авазлары сулышлы «һ» белән алмаштырыла алу сәбәпле).

Ак Күбәк турында – ә ул би / бий титулы белән кабилә юлбашчылары рәтендә карала ала – без фәкать тик эпик материаллардан гына беләбез. Шулай да, А.К. Кушкумбаев игътибар иткән «Аккобiк алып» исеменең кара-кыпшак ыруы шәҗәрәсендә Кобланды-батырның бабалары арасында күренүе очраклы булмас. Ә Кобяк / Кубяк (моннан – Күбәк) исеме исә кыпчак дөньясында XII-нче гасырда билгеле: 1170-нче елларда Днепр елгасы аккан төбәктә яшәгән кыпчаклар төркеменең (аларны «Лукомор кыпчаклары» буларак билгелиләр) ханы буларак рус елъязмаларында Кобяк Карлыевич атала [Плетнева: 2010. С. 159, 161, 188]. Соңга таба бу исем татарларда (казан һәм себер татарларында) антропоним һәм топоним буларак хәзерге көнгә кадәр саклана.

Гарәп елъязмаларында сакланган мәгълүматларны аңлау өчен иң авыр булганы Ибн Халдунда китерелгән дурут һәм токсоба кабиләләренең ике этник тамырдан икәнлеге турындагы информация. Шул ук вакытта, инде әйтелгәнчә, бу тарихчы Мисыр җирләрендәге төркиләрнең кыпчаклардан булуларына аерым басым ясый [История Казахстана: 2005. Т. I. С. 66]. Чынлыкта ул кыпчаклардан булган мәмлүкләр белән «татарлар» – ә бу атаманы гарәпләр катлаулы этник составлы Алтын Урда татарларына карата кулланганнар – арасындагы аерманы күрсәтергә тырышкан. Әмма, токсоба кабиләсе аркылы мондый аермалыкны билгеләү өчен бер киртә бар: башкортларда сакланган тарихи традиция буенча, алардагы кыпчак ыруының ураны «Туксаба!» буларак яңгыраган [Башкирские: 2016. С. 146]. Шулай ук, тарихи әчтәлекле «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәрендә (XVII-нче йөз ахыры) Чыңгызханның кабилә юлбашчыларына кабилә билгеләре (агач, кош, уран, тамга) өләшүенә багышланган бүлектә, Кыпчак бигә – ә ул исем чыганакта кыпчак кабиләсен билгеләүче эпоним буларак бирелә – «Тук Саба» дигән уран эләгә [Мирастан: 2011. Б. 52]. Күренә ки, әйтелгән ике чагыштырмача соң чорга караган чыганакта токсоба кабиләсенең кыпчакларга тоташтырылуы чагыла. Чынлап та, рус елъязмаларыннан Токсобичи дигән төркемнең (урданың) кыпчакларга (половецларга) караганлыгы күренә [Плетнева: 2010. С. 109]. С.А. Плетнева фикере буенча, бу төркем кыпчаклар Дон һәм Донец елгалары арасындагы далаларда яшәп, 1147 һәм 1152-нче еллардагы рус кенәзләренең үзара ызгышларында катнашканнар [Шунда ук. С. 109] Ягъни, нәтиҗәдә алар көнбатыш кыпчакларының (половецлар, куманнар) бер кисәге булып чыгалар. Һәлбүки, Токсобичларның Иделнең уң ягында күренүләре (югарыда әйтелгәнчә, ике тапкыр гына) әле токсоба кабиләсенең башка кисәкләре бүтән төбәктә яшәмәгән дигән сүз түгел, шул ук кабилә көнчыгыш кыпчаклары арасында да булган булырга мөмкин. Әмма, бу мәсьәләне аерым тикшермичә торып ул турыда анык кына фикер әйтеп булмый.

Нәкъ менә шул юнәлештә фикерләү буенча безгә «Ак Күбәк» дастанына яңадан әйләнеп кайту кирәк. Дөресрәге, ул эпик әсәрнең вариантларының ни өчен Көнбатыш Себер һәм Алтай төбәгендә табылуын аңлатырга кирәк. Ул турыда уйлаганда, безгә башкортлардагы кыпчак кабиләсенең «Тук Саба» дигән ураны булуын да, казакъларның кара-кыпшак (кыпчак) ыруы шәҗәрәсендә токсоба кабиләсе белән бәйле Аккобiк исеме чагылуын да истә тотарга кирәк, чөнки барлык бу очракларда без борыңгы Дәште-Кыпчакның көнчыгыш зонасы белән эш итәбез.

Башта безгә, «Ак Күбәк» дастанының себер татарларында һәм алтайлыларда (алтай-кижи), шулай ук хакасларда (сагайлыларда) язып алынганлыгын истә тотып, аның шушы төбәктә таралу сәбәпләрен барлап чыгарга кирәк. Бер сәбәпне озак эзлисе түгел, ул өстә генә ята – төрле галимнәрнең фикере буенча, Себер ханлыгы җимерелгәч, аерым себер татарларының төркемнәре («Күчем ханның халкы») көнчыгыш тарафларга күчеп китеп, Алтай төбәгенә үтеп кергәннәр һәм шунда алтайлылар белән хакаслар арасында калганнар [Потапов: 1969. С. 89–90; Алтайцы: 2014. С. 57]. Хәтта, алтайлы теленгит ыруы эчендә кёбёк төркеме дә булган [Алтайцы: 2014. С. 57]. Димәк, алтайда электән яшәгән этник төркемнәргә бу дастан күчеп килүчеләр аркылы эләккән булырга мөмкин. Ләкин, «Ак Күбәк» дастанының монда таралуының башка сәбәпләрен дә атарга кирәк. Бу очракта алтайлыларның төп ырулары (сөякләре) арасындагы алтай-кижи тармагында кыпчак ыруы (оймагы) булуын искәртик. Ул ыру әһәмиятле оймаклар арасында саналган һәм алардан укту-зайсан дип аталган аксөякләр чыккан [Потапов: 1969. С. 23–24; Алтайцы: 2014. С. 57–58]. Кайбер очракта галимнәр алтайлылар арасында булган кыпчак сөяген Шибанидлар дәүләте һәм Нугай Урдасы белән бәйләргә тырышсалар да (мәсәлән, карагыз: [Алтайцы: 2014 С. 57]), чынлыкта эш башкачарак торган булса кирәк. Мәсәлән, А.П. Потапов күрсәткәнчә, теленгитларда (ә кыпчак сөяге һәм аның белән бәйле башка төркемнәр шулар эченә кергәннәр) аларның борынгы бабаларының «Коңграй-Сагай» далаларыннан килүләре турында легендалар булган, ә качы-хакас («качы татарлары») төркемендә аларның бабаларының кайчандыр «Соко / Сакы» атамалы җирдә Иртыш бассейнында яшәүләре турында сөйләнеп, куманды һәм качы сөякләренең гомуми бабаларының исеме «Куман / Кубан» дип билгеләнгән [Потапов: 1969. С. 32, 37–38, 59]. Ягъни, монда куманнар-кыпчаклар килеп чыга. Шунлыктан, А.П. Потаповның алтайлыларда, бигрәк тә, көньяк алтайлыларда, язып алынган эпик мирасның бер өлешен Җучи Олысы чорына һәм кыпчак дәверенә кайтарып калдыруы юкка гына түгел. Дөрес, бу галим күрсәтелгән ике чорны бер-берсеннән төгәл генә аермый [Шунда ук: С. 47].

Чынлыкта, монголлардан элегрәк булган кыпчакларның тарихи мирасларын Алтын Урда татарларыныкыннан (Шибанидларны да кертеп) аерып алу бик кыен, моның төп сәбәбе соңгыларының этногенезында кыпчакларның зур роль уйнауларында. Шушы кыенлыкларны күрсәтү өчен берничә мисал китерик. Аның беренчесе Н.Ф. Катанов табып бастырган суфый даирәләренә кагылган бер кульязма белән бәйле. Бу себер татарларында табылган кульязма «О религиозных воинах учеников шейха Багаутдина против инородцев Западной Сибири» дип атала (шартлы исемен нәшер иткәндә Н.Ф. Катанов куйган дип уйлыйбыз). Күп катламлы булган шушы чыганак, «изге Бохарадан» мөселман шәехләренең дин тарату өчен Иртыш елгасы буена килүләрен тасвирлаганда, анда яшәгән «төркиләрнең» этник составын мондый рәвештә бирә: «Хотан халкы», «Нугай халкы» һәм «Кара-кыпчак халкы». Аларга тагы ике төркем өстәлә – «Тархан (*Тарган*) хан баш күтәрүчеләре» һәм «Остяк халкы». Нәкъ менә беренче өч төркем «татарлар» буларак аталалар [Катанов: 1905. С. 20–22]. Монда безгә «хотан» һәм «кара-кыпчак» этнонимнарына игътибар итәргә кирәк. Бу ике этнонимның беренчесе «кидань» (кара кытай) атамасын чагылдыра булса кирәк, чөнки кульязмада Кытай да искә алына, ә икенче этноним исә кыпчак дөньясына ишарә ясап, көнчыгыш (төркиләрдә «кара» – көнчыгыш юнәлешен белдергән) кыпчакларын истә тота. Инде искә алынган казакъ шәҗәрәсе дә – ә анда, инде әйтелгәнчә, башында «Аккобік алып» торган кыпшак кабиләсенең кара-кыпшак ыруы күренә – шул турыда ук сөйли дип уйлыйбыз. Димәк, Дәште-Кыпчакта XII-нче гасырда булган «Ак Кумания» һәм «Кара Кумания» бүленешләрен истә тотсак – монда «ак» һәм «кара» төсләр көнбатыш һәм көнчыгышны аңлаталар – себер татарларында, казакъларда һәм башкортларда [Кузеев: 1974. С. 177] булган «кара кыпчак» кабиләсе (ыруы) кыпчак дөньясының көнчыгыш (кара) өлешен билгеләгән дип уйлыйбыз. Шушы фикерне куәтләп тагы бер чыганакны китерә алабыз – сүз Ахсикенти б. Нурмахәммәднең «Мәҗмү-ат ут-таварих» (XV ахыры – XVI йөз башы әсәре) хезмәте турында бара. Ул чыганакта Җучи Олысында Туктамыш хан (1312–1342) хөкем иткән дәвердән кайбер уникаль мәгълүматлар китерелә. Әйтик, анда күп тапкыр искә алынган атаклы Манасның «Каркара кыпчаклары» башында торганлыгы турында әйтелә [Сайф ад-дин: 1996. С. 43–47, 71; Ахинжанов: 1989. С. 158]. Ә «Каркара» атамасы астында билгеле төбәк турында фәнни әдәбиятта төрле фикерләр булса да (карагыз: [Ахинжанов: 1989. С. 158–159]), үз вакытында казакъ тарихчысы С.М. Ахинжановның бу кыпчакларның Иртыш елгасыннан көньякта, Балхаш күленә кадәр сузылган, Каркаралы, Чингистау һәм Тарбагатай тауларын үз эченә алган төбәк белән бәйләп карау кирәклеге

турындагы фикерен истә тотарга кирәк [Шунда ук]. Шул исәптән, гарәп тарихчысы Әл-Идриси (1100–1165) күзәтүе буенча, кимаклар (йәмәкләр) (ә алар инде нәкъ менә көнчыгыш кыпчакларның үзләре) кайбер сыйфатлары буенча кыргызларга охшаш булганнар [Шунда ук. С. 159], димәк алар көнчыгыш тарафта яшәгәннәр. Бу рәттән, кыргызларның (алар эчендәге ичкилек төркемендә) ыру-кабилә составында найман һәм телес кабиләләре белән бергә кыпчак кланы булуын да әйтеп үтик [Кыргызы: 2016. С. 92, 270–271]. Ә чынлыкта алдагы ике кабилә Алтай төбәге белән бәйле булуы сәбәпле, мондагы кыпчаклар да элекке «Каркара кыпчаклары» варислары буларак, көнчыгыш кыпчаклары рәтенә кертелергә тиешләр. Димәк, алар «кара кыпчаклардан» булып, казакъларда яшәп килгән кара-кыпшак ыруына бәйле шәҗәрәдә Аккобік алыпның исеме күренүен без очраклы хәл дип карый алмыйбыз.

**§ 3. Ике кабилә эзләреннән**

Каршыбызда көнчыгыш (кара) кыпчаклар пәйда булу сәбәпле, алга таба игътибарыбызны алда күрсәтелгән гарәп елъязмаларындагы дурут (*дүрт*) һәм токсоба этнонимнарына юнәлтик, чөнки алар шушы кабиләләрнең юлбашчыларының исемнәре аркылы, кабилә (ыру) атамалары күренмәсә дә, «Ак Күбәк» дастанында да урын алганнар.

***Дүрт ~ Дурут***. Тикшерүне «хан» кабиләсе булган *дурут* (бу – гарәпчә язылышы) этнонимыннан башлыйк. Безнең фикеребезчә, монда рус чыганакларында билгеле булган – 1185-нче елны елъязмаларда «Терьтеровичи» буларак искә алынган – терьтер (-ер – «ир» дигән төшенчә булыр) атамасы – затлы кыпчак кабиләсе күз алдында тотыла. Шул елны алар руслар белән зур бәрелештә катнашканнар [Плетнева: 2010. С. 163]. Әйтелгән этнонимның тамыры – терьт булып, ул төркичә *дүрт* төшенчәсен чагылдыра булса кирәк. Шунлыктан, *Терьтеровичи* атамасын түбәндәгечә таркатырга мөмкин – терьт / терьтер + оба. Ягъни, «дүрт кабиләсе кешеләре» (оба / овичи – борынгы рус телендәге патронимик (туганлыкны) күрсәткән термин буларак, яисә, монголларда билгеле *oboğ~obox* (ыру, кан туганнар) төшенчәсен чагылдыра ала [Владимирцов: 2002. С. 341]). Әмма, татарлардагы (мәсәлән, нократ татарларында, ә алар – кыпчаклардан) «*бече / печи*» (мәгънәсе – туганнар берләшмәсе, патронимия) терминын да онытырга ярамый (ул татар телендә билгеле «бичә» – хатынны белдергән төшенчә белән дә бәйле [Исхаков: 1978]). Шунлыктан бу мәсьәлә катлаулырак булып чыга. Рус чыганакларында тагы ике – *Каепечи* һәм *Токсобачи* (соңгысы тикшереләчәк) формалары да билгеле булу сәбәпле, төрки-татар теленнән булган бече / печи дигән сүз белән бәйле аңлатма отышлырак күренә.

Әгәр дә без *дүрт* (*дурут*) этнонимына мөрәҗәгать итсәк, шунда ук Рәшид ад-Дин хезмәтендә санап кителгән алты татар кабиләсенең берсенең исеме искә төшә. Фарсы тарихчысы «борыңгыдан дөньяда билгеле булган» татар кабиләләре турында (ә алар әле шуның өстенә «күптармаклы» да булганнар) сөйләгәндә, татарларның «билгеле һәм данлыклы», һәрберсенең үз гаскәрләре һәм хөкемдарлары булган алты кабиләнең исемнәрен санап китә: *тутукулйут* (монда төп атама – *тутукул* – Д.И.), *алчы*-татар, *чаган*-татар, *куин*-татар, *терат*- һәм *баркут*-татар [Рашид ад-Дин: 2001. Т. I. С. 101–109]. Исемлектәге *терат* этнонимы, һичшиксез, инде безгә таныш булган кыпчак кабиләсе атамасы дүрт / дурут төшенчәсенә туры килә. Мондый тәңгәллек (әле кытай чыганакларындагы цифрлар белән бирелгән – сигез, тугыз, утыз һ.б. этнонимнарның нәкъ төркиләр өчен хас икәнлеген дә истә тотсак) очраклы булмас. Ни өченме? Ә менә ни өчен.

Беренчедән, Рәшид ад-Дин исемлегендәге татар кабиләләренең кайберләре Алтын Урдада да билгеле – ул *алчи* (*алчын*) һәм баркут (*баргут / буркыт*) кланнары һәм алар Дәште-Кыпчакның көнчыгыш төбәкләрендә саналалар. Әйтик, алчын кабиләсе Әстерхан ханлыгында төп кланнар рәтенә кергән [Исхаков: 2009. С. 24], аннан казакълар арасында калган. Буркытлар исә башта Алтай төбәгендә яшәп, аннан соң Урал буйларында һәм Көнбатыш Себердә яшәгәннәр. Элегрәк «Себер князьләре» атамасы астында танылган Тайбугидлар, безнең фикеребезчә, буркытлардан булганнар [Исхаков: 2009]. Ә менә монгол яулары заманнарыннан, ягъни, XIII гасырдан, Алтайда билгеле *меркит* (*мекрит*) кабиләсе дә шушы ук этнонимны чагылдыра ала, чөнки төрки телләрдә б // м алмашы күзәтелә. Димәк, дүрт кабиләсенең борыңгы тарихын өйрәнгәндә без «татар» һәм «кыпчак» атамаларын йөрткән төркемнәрнең үзара катлаулы бәйләнешләре мәсьәләсенә килеп керәбез. Ләкин, ул өлкәгә күчкәнче, безгә башта токсоба этнонимына тукталып китү кирәк.

***Токсоба (Туксоба / Тукс ~ тугыз + оба)***. Гарәп чыганакларында булган бу этноним tokus + aba / токсоба [Kirzioglu: 1992. S. 91; Кушкумбаев: 2018. С. 9] формасында бирелеп, рус чыганакларында, инде әйтелгәнчә, *Токсобичи* буларак бирелә [Плетнева: 1990. С. 97–98]. Аның тамыры *токс ~ тукс*, ягъни *тугыз* булып, ахыргы формант монгол телендәге oboğ сүзеннән яисә төрки бече/печи терминыннан ясалган дип уйлыйбыз. Тикшерүчеләр инде безгә кадәр үк бу этнонимны «тугыз» саны буларак карарга тәкъдим иткәннәр иде [История Казахстана: 2005. Т. I. С. 64] һәм без ул фикергә кушылабыз. Чынлап та, төрки дөньяда урта гасырның башлангыч чорларыннан ук «тугыз татар», «токыз огуз» исемле этнонимнар билгеле. Шунлыктан, кыпчаклар арасында мондый атамадагы кабилә булу шаккатырырлык түгел. Чынлыкта ул этноним төркиләр яшә-

гән төбәкләрдә, шул исәптән, татарларда да, электән үк билгеле. Мисаллар китерик ул турыда.

Әйтик, «алтай кижи» һәм тубалар составында Алтайда «*тогус*» ыруы билгеле [Потапов: 1969. С. 23, 84]. Алтай тикшерүчеләре бу төркемне Себер ханлыгы егылгач Алтай төбәгенә күчеп киткән «татарлар» белән бәйләп карыйлар [Алтайцы: 2014. С. 57]. Чыннан да, мондый нәтиҗә ясау өчен кайбер нигезләр бар. Мәсәлән, Төмән өлкәсендәге Вагай районында XVIII-нче гасырдан себер татарларының *Токуз* (Тогус~Тукуз) атамалы авылы билгеле, ә XVI–XVII-нче гасырларда анда халкы күп санлы булмаса да, шул ук исемдәге «волость», ягъни, ыру нигездәге берләшмә дә, билгеле [Миллер: 1999. С. 285, 352, 468]. «Тогуз волосте» XVII-нче гасыр башында Иж елгасы буенда хәзерге төньяк-көнчыгыш Татарстанда да күренә [Исхаков: 1985], ә аның борынгы этник элемтәләре төрки-угорлар белән бәйле булсалар да (аларның Иж елгасы буйларында яшәгәннәре «Еней волосте» – угорлардан булган ыру кешеләре – белән элемтәдә булганнар, бу төркемнең борынгы тамырларын Себер зонасыннан (андагы «иштәкләр» арасыннан) эзләргә кирәк һәм аларны кыпчаклар белән дә бәйләп карау мөмкин (ул турыда тулырак карагыз [Сәетов: 2018; Исхаков: 2018-г]. Өстәп тагы шуны да әйтеп үтик: берникадәр дәрәҗәдә саклык күрсәтеп, 1184-нче елны Идел Болгарстаны җирләрендә рус елъязмаларында күренгән «Тухчин» шәһәрчеген дә шушы ук этноним белән бәйләп карау мөмкин (*тухч~тукс+ин* ахры; *ин* тагы бер топонимда – Саксин атамсында да бар). Гомүмән алганда, токсоба этнонимының төп мәгънәсе «тугыз ырулы / тугыз ыруы (кабиләсе) кешеләре» дигәнгә кайтып кала.

Шушы рәвешле фикер йөрткәндә, тарихи-этнологик мәгълүматлар Ибн Халдун тарафыннан дурут (дурт) кабиләсен «кыпчаклардан», ә токсоба (туксаба) кабиләсен «татарлардан» дип карауга каршы килә кебек. Чынлыкта бит дүрт кланы борынгы татарлардан, соңыннан гына кыпчаклар арасына кереп киткән төркемнәрдән, ә токсоба кабиләсе, үз вакытында борынгы төркиләр арасында булып, аннан соң кыпчакларның бер кисәген тәшкил иткәннәрдән түгелме соң? Шушы рәвештә фикер йөрткәндә, кыпчаклардан үрчегән мәмлүкләрнең тарихи хатирәсенә таянган, XIV–XV-нче гасырлар арасында яшәгән Ибн Халдунның тикшерә торган сүзләре ни турында сөйли соң чынлыкта?

Монда ике аңлатма мөмкин. *Беренчесе*. Алтын Урда дәверендә дәүләт эчендә токсоба кабиләсе яисә аның гомүми рәвештә инде «кыпчакка» әйләнеп «туксаба» уранын саклаган төркеме, исән-имин булып, Мәмлүк Мисыры белән Алтын Урда арасында барган элемтәләр булу сәбәпле, Ибн Халдун (һәм башка гарәпләр тарафыннан да) ягыннан «татар» дип бәяләнергә мөмкиннәр, чөнки гарәпләр һәм мәмлүкләр өчен алтын-ур-

далылыар «татарлар» булганнар. Мондый аңлатманың бер мөмкин булган сәбәбе, ан-Нувайри язганча, токсоба кабиләсенең дүрт кабиләсе тарафыннан җиңелүеннән соң алалрның Җучига барып баш орулары, (монголларның федератларына әйләнүләре), белән бәйле була ала. Нәкъ менә шушы ситуациядә токсоба кабиләсе теге яки бу дәрәҗәдә үзенең бөтенлеген саклап калып монголлар каршысында «кыпчак» атамасын алып, яшәп калган булырга тиешләр. Дастан эчтәлегеннән чыгып караганда, Котян хан җитәкчелегендә булган дүрт кабиләсе белән чагыштырганда токсоба кабиләсе көнчыгыш төбәктәрәк яшәгән дип уйларга урын бар. Башка мәгълүматлардан тыш бу турыда казакълар составында кара-кыпшак ыруының һәм башкортларда шул исемдәге ыру өлешенең, шулай ук алтайлылар эчендәге кыпчак сөягенең булуы да сөйли.

## § 4. Кыпчак дөньясындагы татарлар: тарихи дөреслекне торгызу юлында

Әмма, китерелгән гипотеза шактый нигезле булса да, Ибн Халдун әсәрендәге тикшерелә торган мәгълүматка тагы бер аңлатма биреп була. Аның нигезен XI-нче гасырда кинәттән көчәйгән кыпчаклар эчендә бер-береннән аерылган этногенетик тамырлары булган төркемнәр яшәп, шуларның берсенең монголларга кадәрге борынгы татарларга барып тоташу мөмкинлеге. Бу этногенетик «җепләр» вәкилләре бәлки башка төбәкләрдә дә яшәгәннәрдер – кыпчакларның үзләреннән (половец, куманнардан) булган төркемнәр Дәште-Кыпчакның көнбатышын (Ак Кумания), ә Кимак каһанлыгыннан чыккан, Кара Куманияда яшәгән төрле төрки төркемнәр – алар арасында татарлар әһәмиятле роль уйнаганнар – Иртыш елгасы бассейнына якын җирләрдә тупланган көнчыгыш кыпчакларын (кимак-татарларны) тәшкил иткәннәр булса кирәк.

Чынлыкта, күтәрелгән мәсьәләне тикшергәндә, без әле хәзер дә дискуссион булып кала бирүче зур фәнни проблемага барып төртеләбез – ул кыпчакларда (половецлар / куманнарда) «монгол / татар-монгол» этник тамырлы һәм төрки тамырлы кланнарның, аларның элиталарының булуы мөмкинлеге (ул турыда карагыз: [Исхаков: 2018-в]). Әгәр дә фәнни әдәбиятта булган бу турыдагы карашларны гомүмиләштерсәң (алдагы хезмәттән ул турыда күбрәк мәгълүмат ала аласыз), аларны түбәндәгечә тасвирлап була.

Иртыш елгасының югары агымы төбәгендә урнашкан Кимак каһанлыгы (IX-нчы гасыр ахыры – XI-нче гасырның беренче дистәләре) эченнән соңыннан кыпчаклар чыга. Ә күренекле тюрколог П. Голден фикере буенча ул дәүләтне оештыруда татар кабиләләре «төп рольне» уйнаганнар [Golden: 1980; 1986: 2001]. Гардизиның XI-нче гасыр уртасында

язылган «*Зайн ал-ахбар*» исемле хезмәтендә (андагы мәгълүмат иртәрәк чордагы этносәяси ситуацияне чагылдыра дип уйланыла [Кумеков: 1972. С. 113–114]) мондый бик тә кызылы хәбәр сакланган: бер «татарларның хөкемдарлары» саналган Шад атлы (бу исем булмас, шушы термин белән борынгы төрки дәүләтләрдә каһаннарның ир яктан булган якын туганнарын атаганнар) шәхес «олуг елга» (Иртыш күз алдында тотыла) буена кача һәм шунда яши башлый. Аның янына акрынлап тагы җиде «туганы» (исемнәре: *Имак, Ими, Татар, Байандур, Кыпчак, Лнкиказ һәм Аҗляд*) килеп урнаша. Чынлыкта бу «исемнәр» эпонимнар һәм алар Үзәк Азиядә һәм күрше төбәкләрдә яхшы билгеле булган кабилә атамаларын чагылдыралар. Әйтик, Ими – уйгурларның бер өлешен, Имак-кимак (йәмәк) этнонимының варианты, соңгы ике этнонимнан тыш (лнкиказ һәм аджляд) калган исемнәр дә төрки (кайбер очракта монгол) дөньясында бик билгеле. Әмма безне бу очракта Кимак каһанлыгында «хөкем итүче ыру» ролен үтәгән татарлар кызыксындыралар, чөнки элитар кабилә буларак алар Дәште-Кыпчакның көнчыгышында алга таба да гел күренәләр. Мәсәлән, атаклы тарихчы Джуджаниның «*Табакат-и Насыйри*» (1259/1260) дип аталган хезмәтендә Хәрәзм-шах Мөхәммәд IIнең 1218/1219-нчы елны кыпчакларга каршы ясаган походы турында мондый мәгълүмат бар: «...615 х.е. ул (ягъни Хәрәзм-шах Мөхәммәд II б. Текеш – Д.И.) Юсуф Татарлының угълы булган Кадыр-хан артыннан барып, Төркестанга керде, ...шулкадәр ерак китеп, Уйгур [lghur] ...<һәм> Төньяк полюска барып җитте ...» [Jouzjani: 1970. Vol. I. P. 267]. Бу хәбәр фәнни әдәбиятта инде тикшерелде (күзәтүне карагыз [Исхаков: 2020. № 2. С. 52–68] һәм нәтиҗәдә монда сүзнең көнчыгыш кыпчаклар турында барганын чамалый алабыз; ул төбәк инде алга таба «Каркара кыпчаклары» дип билгеләнәсе төркемнәр яшәгән төбәкне күз алдында тотып, нәкъ шул җирләрдә Кимак каһанлыгының этник варисары яшәгәннәр дип уйлый алабыз. Бу хәбәрдә Кадыр-ханның атасын башта «Татарлы», аннан соң «Йәмәкле» дип атау [Jouzjani: 1970. Vol. II. PP. 1096–1097] һич тә очраклы түгел. Нәкъ шушы төбәктә төрле кабиләләр арасында күптәнге элемтәләр булып (Гардизи язмасын карагыз!), бу җирләрне тасвирлаган төрле чыганакларда «татар», «йемек / кимак», «кыпчак», хәтта «уйгур» атамалары да бер-берсе белән бәйле һәм үзара алмашына торган төшенчәләр буларак кулланыла. Менә шундый, татарларга мөнәсәбәтлелек, югарыда күрсәтелгән төркемнәргә генә түгел, башка, инде күрсәтелгән, кабилә төркемнәре өчен дә хас булган. Әйтик, шул ук Джуджани, найманнарны да «татар» дип атый [Jouzjani: 1970. Vol. I. P. 264]. Ибн ал-Асирда без шул ук хәлне күрәбез [Ибн ал-Асир: 2006. С. 336, 339]. Дөрес, соңгы тарихчы монголларны татарлар белән бутап күрсәтә, ләкин Джуджани өчен мондый

күренеш хас түгел – ул төркиләрне монголлардан бик төгәл аера. Бердәнбер, Джуджани «татар» төшенчәсен, аларның электән килгән «хөкемдарлык» статусын истә тотып, киң мәгънәдә, гомумән төркиләрне белдерүче, төшенчә буларак куллана алган. Чынлап та, «секиз огузлар», ягъни уйгурлар варисы булган найманнар, һичшиксез, төрки тамырлы төркем; алар монголлар (киданьнар, кара кытайлар) йогынтысына беркадәр бирелсәләр дә, төркилекләрен саклаганнар дип уйлыйбыз. Шуны да истән чыгармыйк – «*Худуд ал-ʻАлам*» (982/983) дип танылган аноним чыганакта татарлар үзләре дә «тогуз – огузлар», ягъни, борынгы уйгурлар эчендәге бер кабилә буларак билгеләнәләр [Худуд ал-алам: 1979. С. 40] һәм бу фактка инде тикшерүчеләр элек тә игътибар иткәннәр иде [Кумеков: 1972. С. 42; Кызласов: 1975. С. 170–177]. Шул турыда ук югарыда китерелгән Гардизидагы татарлар белән уйгурларның Кимак каһанлыгында бергә яшәгәннәре турындагы хәбәр дә сөйли.

Әгәр дә без татарларның Кимак каһанлыгындагы әһәмиятле ролен, аларның башка күрше дәүләтләрдә дә (мәсәлән, Найман ханлыгында) яшәгәнлеген, кыпчакларның татарлар белән бәйле кимаклар арасыннан (кыпчаклар үзләре исә башта кимакларның көнбатыш өлеше генә булганнар [Кумеков: 1972. С. 42]) чыгуларын истә тотсак, XI-нче гасырдан көчәйгән кыпчакларның этник тарихларында татар компоненты күренекле урын тоткан дип уйларга тулы мөмкинлек бар. Нәкъ шул турыда үз вакытында татар милләтеннән булган ватандашыбыз, танылган тюрколог, Ә.Н. Нәҗип язып чыккан иде. Ул мәмлүк Бейбарс заманында Мисырга 1262-нче елны затлы алтын-урдалылар килүе турындагы эпизодны тикшергәндә, мондый фикер әйтә: «...<Бу> татар әмирләре кыпчак далаларының җирле халкы булып, татарлар дип исәпләнгән кабиләләр Дәште-Кыпчакта монголлар килгәнче үк яши иделәр» [Наджип: 1989. С. 86] Мондый нәтиҗә белән килешергә туры килә, ләкин бер искәрмә кирәк – кыпчакларның этник (һәм кабилә) составлары катлаулы булу сәбәпле, татар этник компонентын беренче чиратта көнчыгыш кыпчаклар эчендә эзләргә кирәк, чөнки нәкъ менә аларның формалашуында татарга мөнәсәбәтле кимаклар, алар белән бәйле канглы һәм кайбер башка төркемнәр төп рольне уйнаганнар. «Ак күбәк» дастанын тикшергәндә без ул турыда онытмаска тиешбез.

* * *

Инде йомгак ясарга да вакыт җитте. Шуны әйтә алабыз – Иртыш буйларында һәм Алтай төбәгендә яшәгән көнчыгыш (кара) кыпчаклар себер татарлары, башкортлар һәм казакъларның этногенезында әһәмиятле урын тотып, үз эчләренә «татар» этник компонентын да алганнар. Билгеле, бу урта гасыр «татарлары» турында бәхәсләр әле бетмәгән һәм исто-

риографияда Чыңгызхан сугышлар алып барган борынгы татарларны – ә алар көнчыгыш Халха җирләрен биләп, Кытай белән нык мөнәсәбәтләрдә булганнар – монгол телле этник бердәмлекнең бер өлеше буларак карау таралган. Мондый караш фәнни-популяр әдәбиятта да бар. Әйтик, анда без шундыйрак фикер дә укый алабыз: имеш, татарлар «монгол телендә сөйләшкән төркиләрдән чыккан көнчыгыш халкы буларак карала ала»! [Хоанг: 1997. С. 121]. Ләкин бит мондый күренеш күзәтелсен өчен татарларга көчле ассимиляция аркылы узу кирәк, ә менә ул турыда чыганакларда берни дә юк. Шунлыктан, фәнни әдәбиятта булган тагы бер карашны – татарларның баштан ук төрки булганлыгы турындагы фикерне – алга чыгарырга кирәк.

Бу катлаулы проблеманы тикшергәннән соң [Исхаков: 2018-в; Исхаков: 2020. №№ 1, 2], без төгәл бер фикергә килдек – борынгы татарлар төрки генә түгел, ә кыпчаклар, төгәлрәге, аларның кимаклар белән бәйле көнчыгыш (кара-кыпчаклар) өлеше белән, тыгыз бәйлелектә булганнар. Моны раслаучы тагы бер факт китерик: борынгы төрки чордан ук билгеле булган «хэла» (ала-ат, «пегие лошади», кытайча – «бомо») төркеме, Тан эпохасындагы кытай чыганакларында «элочжи / гэлочжи» буларак искә алына, әмма бу атама рус ельязмаларында кыпчаклар (половецлар) составында Улашевичлар (Алашевичлар) буларак та билгеле [Зуев: 1962]. Күренә ки, монголлар сугыш алып барган татарлар арасында шул ук төркем *алчи / алчын* буларак искә алына! Шунлыктан, монгол яулап алулары вакытында кимак-канглы төркемнәренең этник варислары 1230–1240-нчы елларда урыннарыннан кубарылгач, әсирлеккә эләккәч, ахыр чиктә мәмлүкләргә әйләнеп алар Мисырга да килеп җиткән булырга мөмкиннәр.

Югарыда ясалган анализдан күренгәнчә, Котян ханның һәм аның угълы Мангушның үз кабиләсенең (дүрт / терьт кабиләсенең) кыпчак буларак, ә Ак Күбәк бийның кланын – токсоба кабиләсен, «татар» дип билгеләү шактый шартлы, әмма, бөтенләй ук нигезсез түгел, чөнки XI-нче гасырда көчәйгән кыпчаклардан төрле этногенетик тамырлы төркемнәр булганлыгы чыганакларда ачык күренә. Ә менә гарәп елъязмалары битләренә эләккән «Ак Күбәк» дастанының иң тулы килеш себер татарларында саклануы аларның этногенезында күп тамырлы көнчыгыш кыпчакларының әһәмиятле роль уйнаганлыгы турында сөйли. Шунлыктан, алга таба ул этник компонентның Иртыш буйларындагы һәм Төньяк Алтай төбәкләрендәге урта гасыр чорындагы тарихын әле ныклап өйрәнәсе бар. Ул вакытта татар халкының этногенезы да башкачарак күзалланган.

## II-нче бүлек

## «Түләк һәм Сусылу» дастанында, Иске Казанга караган чыганакларда татар тарихы



*Тарихи графика.* Алибек Койлакаев.

## § 1. Дастанның төп сюжеты һәм Түләкнең кемлеге мәсьәләсе

Татарлар һәм башкортлар арасында таралган «Түләк һәм Сусылу» дастаны XIX-нчы йөздән башлап фәнни әйләнешкә кергән һәм фольклор әсәре буларак шактый өйрәнелгән (тулырак карагыз: [Фахрутдинова: 2011]). Бу дастанның шушы ике халык арасында, башка кыпчак телле халыкларда ул эпос билгесез, таралганлыгы турында әйткән вакытта, без искәртеп китәргә тиешбез – аның иң борынгы һәм тулы версиясе язма рәвештә (кульязмасы XVI-нчы йөзгә карый) татарларда гына сакланган (әсәрнең текстын һәм аның турында аналитик мәгълүматны түбәндәге хезмәттән укый аласыз – [Госманов: 1994. 225–300 бб.]). Башкортларда исә ул кыскарак формаларда халык авыз иҗаты әсәре буларак телдә генә яшәп килгән. Бу очракта дастанны язып алу, аның язма һәм телдә сакланган төрле версияләрен җыйнау һәм аларны фольклор әсәре буларак өйрәнү тарихы безнең бурычка керми. Ул турыда кирәкле мәгълүматны күрсәтелгән М.М. Госманов һәм А.Р. Фархетдинова (Фахрутдинова) хезмәтләреннән алып була. Без исә, инде әйтелгәнчә, дастаннан милли тарихыбызга караган информацияне табып, аны тарих фәне кысаларында тикшерергә тиешбез.

Алга таба фикерләү өчен, башта «Түләк һәм Сусылу» дастанының төп сюжет линиясе турында әйтеп китү кирәк.

Түләк атлы шәхес (ул затлы нәселдән булып, аның кемлеген алга таба ачыкларбыз), үзенең иптәшләре (яисә «туганнары») белән конфликтка кереп, Җайык суы җирлегеннән шактый ерак булган төбәккә качып барганда, күл янында су пәрие Чачдар ханның кызы булган Сусылу белән таныша һәм, ахыр чиктә, аның белән кавышып, су астында яши башлый. Ләкин анда берникадәр вакыт торгач, ватанын сагынып, Чачдар хан рөхсәте белән эпик могҗиза аркылы, сихри бүләкләр алып, Сусылу белән бергә туган иленә кайтарыла. Ул кайтыр алдыннан андагы хан үлү һәм Түләкне халык солтан дип уйлау сәбәпле, аны хан итеп сайлап куялар. Түләк шунда бер дәвер хан булып тора һәм ул үлгәч, бу җирдә ике ел аның улы Габдулла ханлык итә. Дастан болай бетә: «...Түләкнең угылы дөнйадин үткәннән соң, Балкан тау, алтын тәхет, пулат сарай, бал дәрйасы, дүрт тарафдин акган су дәрйәсы, бергә килгән халкы, милке – барчасы бер кичәдә гаиб булып, юк булды. Һәм адәм кайда киткәнен белмәделәр» [Госманов: 1994. 261–262 бб.]. Кем соң ул – дастанның төп герое булган Түләк (тагы бер исеме – Заятүләк)? Бер карашка гади генә булган шушы сорауга җавап бирү, чынлыкта, җиңел түгел, чөнки сүз эпик шәхес турында бара һәм аның кемлеге мәсьәләсе дастанда тиз генә ачып салынмый, дөресрәге, ул яшерелгән. Бер яктан, Түләк үзенең әтисе дип Мирказый бине атый (исеменең язылыш ва-

риантлары: Мыркас / Миркас / Миркасык / Сары-Мыркас), ләкин, икенче яктан, аның атасы дип, легендар Бачман хан да күрсәтелә [Исхаков: 2011. 119 б.]. Әмма, дастанның төрле вариантларын ныклап өйрәнү нигезендә әйтә алабыз: чынлыкта Бачман мөстәкыйль фигура, Түләкнең атасы түгел, ниндидер башка бер ханның атасы булган. Шуңа күрә, кайбер очракта ул эпоста Түләкнең «атасы» дип аталса да, мантыйкка каршы килеп, Түләкнең атасы буларак шул ук вакытта Мирказый би (бай) дә атала. Бу каршылыктан чыгу өчен дастанның иң борынгы язма версиясендәге (XVI-нчы йөз) мондый сүзләргә игътибар итик: «...Бачман хан дигән бер хан угылы ирде... Алтмыш йегет хезмәтче-нүкәре бар иде... Алтмыш беренчесе Миркасык би угылы Түләк атлы иде. Түләкне хан үз катына алды. Түләк бер йалгыз угыл иде» [Госманов: 1994. 237 б.]. Димәк, Түләк хан янына алынган, яисә аңа хезмәткә килгән бер би, ягъни кенәз баласы булып чыга.

Эш әле моның белән генә бетми, чөнки башкортлар арасында сакланган дастан версияләрендә Түләкнең атасы булып тагы берничә шәхес күрсәтелә: Албыр йолкыш, Миңнехуҗа карт, Сәмәр хан [Исхаков: 2011. 119 б.]. Бу очракта телдә сакланган дастан вариантларында сюжетлар нык кыскартылган булу белән бергә, аларны сөйләп бирүчеләр эпик әсәргә үзләреннән өстәмәләр дә керткән булырга мөмкиннәр. Хәлбуки, югарыда китерелгән исемнәрне тиз генә алып атарга ярамый, чөнки аларның кайберәүләрендә тирән мәгънә бар, ул турыда әле сүз булыр.

Гомумән алганда, «Түләк һәм Сусылу» дастанында вакыт үтү белән бәйле кайбер үзгәрешләр күзәтелә дип уйларга урын бар, бигрәк тә аның Бачман хан белән бәйле борынгы өлеше турында туа мондый фикер. Аның нәкъ шул өлеше, ахрысы, дастанда үзгәртелеп һәм кыскартылып бирелә. Чынлыкта Бачман хан (солтан) – бөтенләй башка дәвер кешесе (XIII-нче гасыр) һәм көнчыгыш кыпчаклар (кимак/йәмәкләр) белән бәйле булган. Нәкъ менә аның шәхси кабиләсенең исеме «албыр / ольбер» булган (карагыз: [Исхаков: 2018]). Башкортлар арасында язып алынган «Түләк һәм Сусылу» дастаны вариантларында күренгән Түләкнең атасы – «Албыр йолкыш»ның исеме, ахрысы, шушы борынгы этноним белән бәйле. Ә бу исә Түләк белән Бачман солтан (хан) арасында ниндидер безгә әлегә ачык булмаган бәйлелек булганлыгына бер ишарә.

Ничек кенә булмасын, дастаннан без түбәндәге шәҗәрәне китереп чыгара алабыз: Түләк ← Мирказый би ← [?]. Ләкин бу шәҗәрәнең тагы бер әһәмиятле өлеше Түләктән соң килгән буын – ул Түләк үлгәннән соң ике ел ханлык иткән аның Габдулла исемле улы. Димәк, безнең каршыбызда

чынлыкта өч буынлы мондый шәҗәрә пәйда була: Габулла (хан) ← Түләк (хан) ← Мирказый би ← [?].

Ә менә бу шәҗәрә инде чынлап та кызыклы. Ни өченме? Ә менә ни өчен: «Дәфтәре Чыңгыз-намә» (XVII-нче йөз ахыры) дип аталган Идел буе татарларында билгеле булган тарихи чыганакта Габдулла хан исемле шәхес Болгар шәһәрендә Аксак-Тимер заманында хөкем итүче буларак билгеле. Шулай ук ул чыганакта ханның 120 «олуг биге» арасында дүртесе «асыл шаһзадәләр» дип аталып (аларның аналары хан кызлары булган булса кирәк), берсенең исеме «Миркаши бик» дип бирелә [Мирастан: 2011. 60 б.]. Күренә ки, соңгы исем Түләкнең атасының исеменә якын – Миркаши / Мыркас / Мирказый.

Үз чиратында, Түләкнең исеме тарихи чыганаклардан билгеле төмән бәге (монголча – нойон) булган Мамай тарафыннан 1380-нче елны хан итеп тәхеткә утыртылган Тулукбек (башкача – Тюляк) исеме белән тәңгәл. Шулай ук Мамай Урдасында Абдаллах исемле шәхеснең хан булганлыгы да билгеле (алар турында тулырак карагыз [Исхаков: 2013-б]). Без бу фактларга игътибар итәргә тиешбез, чөнки «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дән күренгәнчә, легендар Габдулла ханның «уллары» саналган Алтын бәк (Алтынбәк) һәм Галим (Алим) бәк, Болгар / Казан вилайәтендә Олуг-Мөхәммәд ханга кадәр хөкем итүчеләр булганнар (бу турыда аерым рәвештә безнең хезмәттән карый аласыз: [Исхаков: 2013]). Дөрес, эпик Габдулла һәм Түләкнең хан булулары белән тарихи Абдаллах һәм Тулукбек (Тюляк) атлы шәхесләрнең тәхеттә утыру тәртипләре туры килми: Мамай Урдасында Абдаллах, аның сугылган акчаларыннан күренгәнчә, Тулукбектан алдарак, 1361/62–1369/70-нче еллар арасында хан тәхетен биләгән. Әмма, безнең фикеребезчә, эпик әсәрдә мондый рәвешле урыннар алышыну мөмкин. Шуның өстенә, югарыда китерелгән исемнәрнең бер үк кешеләр белән бәйле булганлыгын исбатлаучы башка мәгълүматлар да бар. Алар арасында иң әһәмиятлесе Үтәмеш-хаҗиның фәнни әйләнешкә күптән түгел кертелгән «Кара таварих» әсәрендәге мондый юллар: «[Мөхәммәд хан, ягъни Олуг-Мөхәммәд – Д. И.] ...барган белән барыб Казан вилайетин хәйлә берлә Албай Алтун байдин алыб, анда хан булды...» [Утемиш-хаджи: 2017. С. 155]. Бу информацияне бераз башкача бирүче һәм тулыландыручы икенче чыганак – Габделгаффар Кырыминың «Умдәт әл-әхбәр» әсәре. Анда Олуг-Мөхәммәд турында сөйләнгәндә әйтелә: «...ул дахи Казан семтине баруб нәселе Шибандан олан Алтунай солтандан хәйле берлә Казанны олуб...» [Кырыми: 2014. С. 112]. Күренә ки, Үтәмеш-хаҗидагы «Албай» һәм «Алтун бай» – икесе ике шәхес булганнар. Аның беренчесе – татар чыганакларында билгеле булган Али / Гали бий (бәк) (Ал-

бай→Али / Гали бий) булса кирәк. Ул аерым рус чыганакларында да «Либей», «Али-Баба» буларак күренә. Икенчесе исә Шибан нәселеннән булган Алтынай (Алтынбай) исемле солтан булып чыга. Димәк, «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәрендәге Габдулла ханның «уллары» буларак күрсәтелгән Алтын бәк һәм Галим бәк – икесе ике шәхес кенә түгел, ә ике статустагы кеше – Алтынай (Алтынбай→Алтынай) ул солтан, хан угълы, бу очракта Габдулла хан нәселеннән, ә Галим (Алим, Али) – бәк, ягъни, кенәз титуллы кеше, һәм ул башка нәселдән булырга тиеш кебек. Ә кем нәселеннән соң бу соңгы шәхес?

Шушы сорауга җавап бирү өчен безгә күп кенә эзләнүләр үткәрү кирәк булыр, әмма ул эзләнүләр вакытында бер әйберне истән чыгармыйк – кайбер рус елъязмаларында ул шәхес «казанский вотчич» дип исемләнә [ПСРЛ: 1859. Т. 8: С. 114]. Димәк, бу очракта Али / Гали / Галим бәкнең «Казан кенәзе», нәселдән-нәселгә Казан / Болгар вилайәтендә утыручы аның хөкемдары икәнлеге билгеләнә. Әмма, бу биләмәдә ул үзе генә утырмый – монда аннан башка Шибан нәселеннән чыккан солтан да булганлыгы ачыла. Моның шулай икәнлеген раслаучы факт 1429-нчы елга карый. Рус елъязмаларында нәкъ менә шушы ел астында татарларның Галич һәм Кострома шәһәрләренә һөҗүме, аларның рус гаскәрләре тарафыннан эзәрлекләнүләре турында әйтелгәч, мондый җөмлә китерелә: «*... полон отняша, а царевича и князя Али-Бабы не догониша*» [ПСРЛ: 1963. Т. 28. С. 98]. Тарихчылар инде бу татарларның Казан (Болгар) вилайәтеннән икәнлекләре турында язганнар иде [Горский: 2000. С. 142; Бахтин: 2008. С. 124–125]. Шуңа өстәп әйтергә кирәк – гаскәрдәге «царевич», ягъни солтан – Алтынай булса, Али-Баба (дөресрәге – Али би/бий булса кирәк) бу очракта Гали / Галим / Алим бәк булып чыга. Чынлыкта, бу ике шәхес тә Иван IV-нең ногай морзасы Урус белән хәбәрләшүендә дә күренә (1576-нчы ел). Анда түбәндәге гыйбарә бар: «*...и Алибаев, и Алтын б[ае]в [юрт] Болгарской*» [Посольская: 2003. С. 47]. Документка игътибар иткән мәскәүле тарихчы В. В. Трепавлов күрсәткәнчә, бу очракта без Казан ханлыгының «бер өлешенең», анда беренче хөкемдарлар булып утыручыларының исемнәре аркылы атау белән очрашабыз. Шулай ук, ул, күрсәтелгән ике «эпонимны» легендар Габдулла ханның «уллары» белән бәйләп карарга тәкъдим итте [Посольская: 2003. С. 82].

Димәк, берникадәр дәрәҗәдә югарыда аталган шәхесләр аркылы без Болгар / Казан җирлегенә килеп керәбез. Һәм бу җирлек дастанда чынлыкта бер дә юкка гына барлыкка килми, чөнки «Түләк һәм Сусылу» әсәре дә безгә мондый нәтиҗә ясау өчен өстәмә дәлилләр бирә, ләкин алар өстә генә ятмыйлар. Хәзер башта аларны барлап үтик.

Күзгә ташланган беренче мәгълүмат – 1374-нче елны кайбер рус елъязмаларында Болгар шәһәреннән ерак түгел «Моркваши» топонимы күрсәтелү [ПСРЛ: 2006. Т. 15. С. 106]. Бу топоним «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә искә алынган, элегрәк аталган Миркаши бәк исеменә генә түгел, ә «Түләк һәм Сусылу» дастаныныда чагылыш тапкан Мирказый / Миркасык / Мыркас исеменә дә бик якын. «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә, инде әйтелгәнчә, Миркаши бәк 4 шаһзадәнең берсе буларак атала һәм ул Габдулла хан хөкем иткән, үзәге Болгар шәһәрендә булган, биләмәдә яшәгән булып күренә. Шулай итеп, монда Алтын Урданың Болгар вилайәте күз алдында тотыла булып чыга.

Шуның өстенә, башкортларда сакланган «Түләк һәм Сусылу» дастанының кайбер вариантларында ике агай-эне искә алына һәм алар анда, ахрысы, Түләкнең (Заятүләкнең) «абыйлары» буларак аталалар. Бу ике шәхеснең берсенең исеме – Алтын бай, икенчесенең – Етем (Ете) бай [Исхаков: 2011. 123 б.]. Беренче исем Болгарда хөкем иткән хан белән булган бәйлелеген ачып бирмичә генә Үтәмеш-хаҗида һәм Габделгаффар Кырымида Болгар/Казан биләмәсендә торган итеп күрсәтелгән Алтун бай/Алтунай солтанның исеме белән туры килә. Бу уңайдан, кайбер татар шәҗәрәләрендә искә алынган бер шәхескә дә игътибар итәргә кирәк. Чөнки ул шәҗәрәдәге шәхес «шәһри Болгар» белән бәйле рәвештә атала һәм, иң әһәмиятлесе, шушы шәҗәрәнең кайбер версияләрендә аларның беренче буыны итеп «Кырымнан чыккан» Габдулла хан күрсәтелә [Әхмәтҗанов: 1995. 35 б.]. Бу сюжет әле алга таба аерым рәвештә анализланыр, ләкин инде әйтелгәне дә Түләкне һәм Габдулланы Болгар / Казан биләмәсе белән бәйләп карарга мөмкинлек бирә. Безгә хәзер Түләкнең һәм аның улы саналган Габдулланың нәселе турында тулырак тикшерү уздырырга кирәк. Бу юлы ул нәселнең кабилә/ыруын ачу таләп ителә, чөнки урта гасыр төркиләре өчен ул күрсәткеч бик әһәмиятле булган. Чынлыкта, дастанда һәм кайбер башка чыганакларда сакланган информация безгә мондый мөмкинлекне бирә.

Беренче «эз»гә Түләкнең «кошы» аркылы төшеп була. Дастаннан күренгәнчә, урта гасырларда ау өчен кулланылган кошлар рәтеннән Түләкнең ике төр кошы булганлыгы турында әйтелә: бер версиядә ул – «ак шоңкар», икенчесендә «ак йапалак» дип билгеләнә. Бу мәсьәләне тикшергәндә шул ачыкланды: Түләкнең чын кошы шоңкар / ак шоңкар булып, дастанда аның икенче кошы – ябалак / йапалак (ә ул кош күбрәк башкортларда язып алынган телдә яшәгән эпос вариантларында гына күренә), аның абыйларының бер кош баласын «ул ак ябалак баласы», дип энеләренә яшертен рәвештә китереп кую нәтиҗәсендә генә дастанда бар-

лыкка килә. Чынлыкта исә, үскәч, ул барыбер ак шоңкар баласы булып чыга [Исхаков: 2011. 120 б.]. Дастанда бу кош ау кошы буларак тасвирланса да, аның башка бер ягын да чамаларга була.

Билгеле булганча, иске төрки-монгол традициясе буенча төрле кошлар кабилә-ыру атрибутлары рәтенә кергәннәр һәм *онгон / сүлде* – кабилә рухы – буларак, әһәмиятле идеологик роль уйнаганнар (алар үлгән кешеләрнең рухларын күккә күтәргәннәр, дип уйланганлыктан). Моның шулай икәнлеген түбәндәге дастанда китерелгән урын да раслый: Түләк, Сусылу белән бергә, «олуг шәһәр» янына күчерелгәндә, андагы Балкан тау өстендә ак шоңкар очып йөргәнлеге турында әйтелеп, аны бу эпик әсәр «*миңезлик кош*» дип исемли [Госманов: 1994. 258 б.; Исхаков: 2011. 120 б.]. Безнең фикер буенча, ул сүзнең мәгънәсе – «шушы кошка (шоңкарга) охшаган», дигәнне аңлатып, аның ак шоңкар икәнлегенә ишарә ясый. Шуның өстенә, бу онгон (сүлде) ролен башкарган ак шоңкарның дастаннан тагы бер функциясе дә күренә – татарларда диалекталь сүз буларак йөргән «меңге» төшенчәсе «акча, тәңкә» мәгънәсендә дә кулланылган [Татар теленең: 2009. 477 б.]. Алай булса, ак шоңкарның акчага да мөнәсәбәте булганлыгы ачыла. Шул уңайдан, хәтергә Үзбәк һәм Җанибәк ханнар дәверендә Алтын Урда акчаларында ике башлы кош рәсеме булуы искә төшә. Нинди кош булган соң ул?

«Дәфтәре Чыңгыз-намә»дән һәм кайбер монгол чыганакларыннан күренгәнчә, шоңкар, төгәлрәге, ак шоңкар, кыйат кабиләсенең кошы, сүлде / онгоны булган. Ә бу кабилә Чыңгызхан нәселенең шәхси кабиләсе булганлыктан (ул нәсел кыйат кабиләсенең бурджигин ыруыннан иде), шул ук кош Чыңгызыйлар нәселенең кошы да булып чыга. Һәм без өйрәнгән монгол чыганакларында («Яшерен тарих», «Алтан Тобчи») ул факт ачык чагыла – ак шоңкар аларда кыйат кабиләсенең саклаучысы, рухы буларак күрсәтелә [Исхаков: 2011. С. 121]. Дөрес, «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә Чыңгызханның кошы «*ике баш[лы] кара кош*», дип атала [Ivanics, Usmanov: 2002. P. 59]. Моның үз сәбәпләре бар һәм без аларны башка бер эшебездә тикшердек [Исхаков: 2007-б]. Бу очракта шуны гына әйтеп үтик: символик кошның ике башлы булуы һәм исеме үзгәрүе Чыңгызхан нәселенең «Алтын урук» буларак башка кабиләләр өстеннән күтәрелүе белән бәйле булса кирәк. Ләкин, безгә барыбер нәтиҗә итеп әйтергә мөмкинлек бар: борынгы заманнарда ак шоңкар кыйат кабиләсенең кошы булган. Ә ул кабилә исә Алтын Урда дәүләтендә дә аерым бер социаль берәмлек – кабилә буларак яшәгән һәм, һичшиксез, анда югары урын тоткан [Исхаков, Измайлов: 2007. С. 150–151].

Шулай итеп, Түләкнең һәм аның нәселенең кыйат кабиләсе белән бәйлелеге килеп чыга. Чыңгызхан нәселеннән турыдан-туры чыкмаса-

лар да, Түләкнең нәселе Бөек Монгол империясенә нигез салучының үз кабиләсеннән чыгучылар арасында икәнлеге ачыла. Бәлки, Чыңгызхан белән аларның борынгы туганлыгы да булгандыр, ләкин моны әлегә белеп булмый.

Менә шушы гипотезаны ныгыту өчен, тагы бер дәлил китереп була. Әйтик, «Фи бейан-тарих» исемле татар чыганагында Алтын-бәкнең тамгасы аталышы (*әвернә*) һәм рәсеме буенча (×) «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә искә алынучы кыйат кабиләсеннән булган Буданжар бәкнеке белән туры килә [Мустакимов: 2008. С. 155–156]. Әгәр дә без ул кабилә билгеләрен гомумән Габдулла хан нәселенеке, дип карасак, әйтелгән фикерне раслаучы тагы бер чыганакны күрсәтеп була. Инде алда язылганча, «шәһри Болгардан» чыккан «Олыс бие, Чыңгызхан биләреннән» булган шәхеснең шәҗәрәсе, кайбер вариантларында, «Кырымнан чыккан Габдулла ханнан» башланып кына калмый, ике кабилә билгесе аркылы – тамгасы һәм агачы (*карагай*) буенча, кыйат кабиләсенекенә туры килә. Дөрес, кошы туры килми – ул шәҗәрәдә «күчәгән» дип атала. Бу очракта, бәлки, шәҗәрәгә хатын ягы кабиләсенең атрибутлары килеп кергәндер. Ләкин безгә «Фи бейан-тарих»та әйтелгән мондый юлларга игътибар итәргә кирәк: «*...Алтын бик, Галим бик оругларындын Кырымда һәм бар ирмеш. Ул сәбәбдин һәр заман хан кирәк булса, Кырымдын хан алырлар ирмеш Казанга*» [Мустакимов: 2008. С. 155].

## § 2. Түләкнең социаль статусы

Әмма, Түләкнең реаль социаль статусы һәм аның кыйат кабиләсе белән бәйлелеге буенча дастанда кайбер каршылыклар бар. Чыннан да, Алтын Урда дәверендә тәхетне Чыңгызыйлар гына били алганнар. Аларның бабалары үз вакытында кыйат кабиләсеннән чыккан булсалар да, бу һәм башка кабиләләрдән «Алтын урук» буларак инде күптән аерылу сәбәпле, кабилә аксөякләре, мәсәлән, кыйат кабиләсенең бәкләре (нойоннары), берничек тә Чыңгызыйлар белән социаль яктан тигез була алмаганнар. Шуңа күрә дә дастандагы Түләкнең социаль статусы мәсьәләсенә кире кайтып, аны яңадан тикшерергә кирәк, чөнки ул мәсьәлә буенча бу эпик әсәрдәге эчке каршылыкларны аңлату таләп ителә.

Чынлап та, бер яктан, инде әйтелгәнчә, дастанда Түләкнең атасы Мирказыйның титулы би / бий дип күрсәтелә. Билгеле, Түләк, бий угълы буларак, үзе дә шул статуста булырга тиеш. Әмма, эпоста әйтелгәнчә, ул туган иленә («*олуг шәһәргә*») кайткач, аны «солтан угълы» буларак каршы алалар һәм тәхеткә хан итеп күтәрәләр. Шуның өстенә, дастанда

Түләкнең Бачман ханга бәйлелеге турында да сөйләнә, хәлбуки, тотрыклы рәвештә булмаса да. Дөрес, өч ел ханлык иткәч, аның кем икәнлеге, чын йөзе ачыла һәм бий нәселеннән икәнлеге дә беленә, чөнки аның кемлеге турындагы сорауга, Түләк үзе дә дастанда түбәндәгечә җавап бирә: «*Мәнем атым Түләк торыр. Атам аты Миркас би... Мән сезнең үз нәселеңездән, мән йәнә үз угылызмән*» [Госманов: 1994. 261 б.].

Шундый ук күренеш телдә сакланган һәм башкортларда таралган дастан версияләрендә дә күзәтелә. Бер очракта аларда Түләкнең атасы «хан» дип билгеләнә, ул үзе «хан угълы» яисә «шах» дип атала. Икенче очракта аның затлы нәселдән булуы инкарь ителеп, атасы «йолкыш», «карт» дип кенә атала [Исхаков: 2011. С. 121–122]. Ләкин, дастанның бөтен вариантларын да карап чыккач, шул ачыла: ахрысы, эпоста Бачман хан дип исемләнгән элекке бер төрки йортның хөкемдарының титулы, Түләкнең атасы булган Мирказый бинең титулы белән буташтырыла булса кирәк. Инде әйтелгәнчә, мондый үзгәрешне борынгы кулъязма рәвешендә сакланган «Түләк һәм Сусылу» дастаны текстыннан да күреп була – анда Түләк башта «Бачман ханның угълы» дип игълан ителә, аннан соң ул «Мирказый бий» (төгәлрәк – «би» булган булса кирәк – Д. И.) угълы Түләк ирде», дип атала, аның ялгыз бала буларак ханга хезмәткә (яисә тәрбиягә) алынуы турында әйтелә [Исхаков: 2011. С. 119]. Кызык кына нәтиҗә килеп чыга: Түләк, би нәселеннән, ягъни, кенәз статуслы кеше гаиләсеннән булса да, шактый үзенчәлекле шартларда – элекке хан үлгәч, хан урынына варис эзләгәндә, аны танымау сәбәпле, солтан дип уйлап, «олуг шәһәрдә» тәхеткә хан итеп күтәрелә, алай гына да түгел, ул бу тәхетне, аның чын йөзе ачылгач та, улына калдыра ала.

Мондый буталчыклылык булу сәбәпле, Түләкнең социаль яктан кем булганлыгын аңлау өчен, безгә «Түләк һәм Сусылу» дастанындагы тагы бер сюжет линиясен карап үтү кирәк булыр.

Инде күргәнебезчә, ханлыкка Түләктән соң Габдулла күтәрелә. Аның атасыннан калган могҗизаи әйберләре арасында «алтын тәхет» тә була. Ул тәхет эпоста түбәндәгечә барлыкка килә: Түләк, Чачдар хан биләмәсендәге Сусылуның сараенда яшәгәндә, туган җирен сагынып Тәңрегә мөрәҗәгать иткәч, сарай каршында кинәттән генә алтын тәхет пәйда була. Менә аның тасвирламасы: «*...алтын тәхет сарайның алдында корылмыш, сәкез кырыны, дүрт тарафыны тимер берлә коршаган [бер таг]тәхетдин йукары калкып сайә (ышык – Д. И.) кылып торыр. Ул тагны алтын берлә коршаган, башыны ак мәрвәр (энҗе) берлә йапкан. Туртйаны агач үскән...*» [Госманов: 1994. 250 б.]. Тәхетне күреп, аның өстенә менеп утырган Түләк, болай ди:

*Алтын тәхет урнаткан,*
*Көмешдин айак йараткан,*
*Тәхет – бәхет түрәткән...* [Шунда ук].

Менә шушы «алтын тәхет» – ә ул гади тәхет кенә булмаган, без моны алга таба аңларбыз – Түләк Тәңрегә үзен һәм Сусылуны туган иленә күчерүне сорап мөрәҗәгать иткәч (исегезгә төшерәм, бу су асты патшасы Чачдар хан биләмәсендә яшәгәндә була), алар белән бергә «олуг шәһәр» янына ул басып торган Балкан тау белән бергә күчерелә. Билгеле булганча, шундый исемдәге тау Башкортостанда, Дәүләкән районында урнашкан «Асылы күл» дип аталган зур күл янында хәзер дә бар. Легендар мәгълүматлар буенча, Түләк һәм Сусылу шул тауның өстендә күмелгән булганнар һәм анда кайчандыр Түләк исеме язылган кабер ташы да булган [Башкорт халык иҗаты: 1998. 184 б.]. Түләк, Чачдар ханның су астындагы биләмәсенә килгәч, үзенең «җире һәм суы» турындагы сорауга, әйтә: «Туган җирем – Балкантау, эчкән суым – Дим. Башка күп җирсу Дим белән Балканга буйсынган», – дип. Чынлыкта исә Түләк ханлык иткән урын монда гына түгел, ә башка җирдә дә була.

Дастаннан күренгәнчә, озак вакыттан соң Түләк «атам йорты» дип исемләнгән «олуг шәһәрле» биләмәгә кире кайткач – нәкъ ул кайтуга анда элекке падишах / хан үлгән була һәм бөтен халык, олуг биләр, вәзирләр, бөекләр (әкәбирлар), инде алда күрсәтелгәнчә, аны «солтан улы», – дип танып, ханлыкка күтәрәләр. Бу вакытта ул биләмәдә Түләкнең атасы да, анасы да әле исән була, ләкин аның атасы Миркас би, хатынына тегесе бу хан булып күтәрелгән шәхес «*гаиб булган* (югалган – Д.И.) *угылымызга охшар*», – дип әйтүенә карамастан, аның мөмкин түгеллеген искәртеп: «*Әй, хатын, гаиб булган угылымызга мондагъ ханлык кайда булыр?*», – дип белдерә [Госманов: 1994. 260 б.]. Шулай булуга да карамастан, Түләк хан булып шушы биләмәдә өч ел утыра һәм еш кына Балкан тауга чыгып, алтын тәхетенә менә дә, халыкны җыеп, думбрада уйнап, бөтен кешене дә сыйлап, күңел ачып хөкем итә.

Бер сорау туа: ни өчен монда «алтын тәхет» дип исемләнгән корылма күренә һәм аның Түләкнең ата-анасы яшәгән биләмәгә ни катнашы булган? Ул сорауга җавап эзләгәндә без тагы да бу биләмәнең Болгар вилайәте булырга мөмкин икәнлеген чамалый алабыз. Моның өчен безгә яңадан «Фи бейан-и тарих» исемле тарихи чыганакка мөрәҗәгать итәргә кирәк булыр. Бу чыганакта Габдулла хан «улларының», инде безгә таныш булган Алтынбәк һәм Галим бәкнең, Болгардан Иске Казанга күчүен тасвирлаган эпизодта (ул турыда кайбер башка чыганакларда да искә алына), мондый җөмлә әйтелә: «*...Алтын тәхетдин чыкып, Иске Казанга кил-*

*деләр. Алтын тәхет, дип шәһре Богарны әйтер ирмеш*» [Мустакимов: 2008. С. 155].

Шулай итеп, «алтын тәхет» торган «олуг шәһәр» Болгар вилайәте белән бәйле булып чыга. Ә «олуг шәһәр» термины үзе монголлар яулап алу алдыннан рус елъязмаларында «Великий город» дип исемләнүче Биләр шәһәре атамасына да туры килә (би – «бөек», «олуг» мәгънәсенә ия булган, дип уйлыйбыз). Ягъни дастанда сүз монголларга кадәрге Идел Болгарстаны һәм Алтын Урданың Болгар вилайәте турында бара, дигән нәтиҗә ясау мөмкин.

Мондый вакыйгалар агымы Алтын Урдада ханны тәхеткә утырту принципларына каршы килә түгелме соң? Әйе, каршы килә, чөнки анда тәхетне Чыңгызхан нәселеннән булучылар гына били алган. Менә шушы дастанның эчтәлегеннән килеп чыккан каршылыкның бер чишелеше булырга тиеш. Һәм ул чыннан да бар, әмма бу табышмакны чишкәнче безгә эпик геройларның – Түләк һәм аның улы Габдулланың, тарихи элгәрләре булган Мамай Урдасында хан итеп күтәрелгән Тулукбек һәм Абдаллахның ханлыкка килүләренең кайбер үзенчәлекләрен барлап чыгарга кирәк (ул турыда бөтен нечкәлекләре белән безнең элегрәк басылган хезмәтләрдән карарга мөмкин [Исхаков: 2009-д; 2013-б]).

Билгеле булганча, Мамай төмән башлыгы һәм кыйат кабиләсенең бәге булу белән бергә (аның төп биләмәсе – Кырым) Алтын Урдада «бөек чуалышлар» заманы килер алдыннан хан тәхетендә утырган Бирдебәкнең (1357–1359) кияүе дә булган (элекке монгол традициясе буенча, ул «гурген» дип исемләнгән һәм бу аңа югары статус биргән). Менә шушы Бирдебәк хан 1357-нче елны властька килер алдыннан үзенең 12 ир туганын үтертә (алар барысы да Үзбәк хан нәселеннән булганнар). Шуңа күрә дә Бирдебәктән соң кыска гына вакытта Алтын Урда тәхетендә утырган Кульна (Кульпа) һәм Нәврүз исемле шәхесләрнең төгәл шәҗәрәләре билгеле түгел. Тагы бер шул дәвердә тәхеттә утырып алган хан – Килдебәк турында да чыганакларда каршылыклы фикерләр әйтелә, аны хәтта «ялган Килдебәк» дип тә атыйлар (бусы аның мәрхүм Җәнибәк ханның улы булган икән, дигән фикергә каршы әйтелә).

Менә шушы билгесез нәселдән булган шәхесләр Сарай тәхетендә утырып алганнан соң, Алтын Урдада хөкем итү өчен үзара зур низаглар башлангач, Мамай, үзенең гурген статусыннан файдаланып, үз биләмәсендә (вакыт-вакыт ул Сарай шәһәренә дә керә) Абдаллахны 1361/62-нче елны тәхеткә күтәрә. Аны кайбер гарәп чыганакларында Үзбәк хан нәселеннән булган, дип тә күрсәтәләр, әмма моның өчен чыганакларда бернинди конкрет дәлил дә юк. Ул анда хан булып 1369/70-нче

елга кадәр утыра. Аннан соң Мамай Урдасында 1370-нче елны Мамат солтан (Мөһәммәд-Бүләк) хан була (тәхеттә 1375/76-нчы елга кадәр утыра). Ә инде 1377-нче елның мартыннан 1380-нче елга кадәр Мамай Урдасында хан тәхетен безгә таныш Тулукбек (Тюляк) били. Шуны да әйтеп китәргә кирәк – 1370–1377-нче еллар арасында (бәлки, башка елларда да, ләкин ул турыда төгәл информация юк) Болгар вилайәте дә Мамай биләмәсенә карый. Безгә бу фактларны истә тотарга кирәк.

Алга таба тагы бер әһәмиятле нюанс: 1380-нче елны Тулукбек үзенең ярлыгында Мамайны үзенең «агасы» дип таный [Исхаков: 2013-б. С. 43]. Ә бит Мамай, затлы нәселдән чыккан шәхес булса да, Чыңгызый түгел, кыйат кабиләсенең бәге генә. Әгәр дә без Тулукбек (Тюляк) белән эпик Түләкне тәңгәлләштерсәк, каршыбызда берничә буын кыйат кабиләсеннән чыккан һәм бәкләр нәселеннән булсалар да, таралып барган Алтын Урданың бер кисәге булган Мамай Урдасы тәхетендә утырган шәхесләр килеп чыга. Иң кызыгы шунда – ул «тәхет урыны» чынлыкта кайсыдыр вакытларда Болгарда булган, дип уйларга да урын бар. Дөрес, күчмә тормышта яшәүче татарлар чынлыкта Урда кайда була, шунда күчеп йөргәннәр, ә сарай әһелләре, бигрәк тә Сарай шәһәре Мамайның көндәшләре кулына күчкәндә, Болгар шәһәрендә яшәгән булырга да мөмкиннәр.

Билгеле, Түләкне һәм Габдулланы «бөек шәһәр» тәхетенә утырту гадәттән тыш шартларда башкарылган: Бирдебәктән соң Чыңгызыйларны күпләп үтерү нәтиҗәсендә турыдан-туры бу затлы нәселдән булган шәхесләр «дефицитка» әйләнгән, ахрысы. Чынлап та, алга таба – Туктамыш хан дәвереннән – сарай тәхетендә Чыңгызхан нәселеннән булган башка тармак вәкилләре утыра башлый.

Менә хәзер инде әйтелгәннәрдән чыгып безгә яңадан «Түләк һәм Сусылу» дастанына кире әйләнеп кайтып, аның эченә яшерелгән милли тарихыбызның моңарчы билгеле булмаган якларын торгызуны башкарып чыгу мөмкинлеге туа.

Беренче сорау: Нәрсә соң ул дастанда күренеп киткән «алтын тәхет»? Мәсьәләне аерым рәвештә өйрәнү шуны күрсәтте – ул Чыңгызхан заманыннан, бәлки, аңа кадәрге дәвердән үк килүче, власть символы. Алтын Урдада андый тәхет булган, әмма «алтын» дип билгеләнүе чыганакларда сакланмаган. Ләкин, Ибн Баттута язмаларыннан «алтын чатыр» эчендә торган алтынланган көмеш белән капланган тәхет булганлыгы билгеле. Гарәп сәяхәтчесе, аның аякларының көмештән ясалганлыгын күрсәтеп, өске ягының кыйммәтле ташлар белән бизәлгәнлеген әйтә [Золотая Орда: 2003. Т. 1. С. 132–133]. Үз чиратында, шундый ук алтын чатыр һәм алтын белән капланган тәхет Бөек Монгол империясендә дә булган [Исхаков:

2014. С. 185–186]. Әгәр дә Ибн Баттута язмасындагы тәхет тасвирламасын дастандагы тасвирлау белән чагыштырсаң (аяклары көмеш, тәхетнең – тагның өске ягы мәрвәр / энҗедән), аларның тәңгәллегенә шаккатасың! Ахрысы, «Түләк белән Сусылу» дастаны авторы (авторлары) ул тәхетне күргән булганнар.

Икенче бер әһәмиятле элемент: «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә «Болгарда», ә чынлыкта, таркала башлаган Алтын Урданың Мамай контроле астындагы бер өлешендә, ханлык иткән Габдулла янында, дүрт «олуг бәк/шахзадә» булганлыгы турында әйтелә [Мирастан: 2011. 60 б.]. Ә «Түләк белән Сусылу» дастаныннан күренгәнчә, Түләк янында да «олуг биләр» була, халык аны тәхеткә күтәрүдә катнашса да, ул мәсьәләне хәл иткәндә башта «шәһәрнең олуглары» җыелып сөйләшәләр, аннан соң гына Түләкнең сарае янына «олуг вәзирләр һәм әкябирләр» барып, аның белән күрешәләр һәм нәкъ шулар аңа тәхет тәкъдим итәләр дә [Госманов: 1994. 260 б.]. Чынлыкта соңгы очракта Алтын Урда тәхетенә традицион йола буенча хан күтәрү тасвирлана. Аның механизмы ачылып бетмәсә дә – тәхеткә бу дәүләттә ханны 4 карачы бәк күтәргән – дастан да чынлыкта шул турыда ук сөйли. Аны дастандагы түбәндәге юллар да раслый: шәһәрнең «бөекләре» әйтүе буенча, «ханнарыннан угыл-кыз калмау» сәбәпле, карар кылына – әгәр дә «*таңдагы көн төш вакытына тигрү һәркем килсә, ханлыкга күтәргәймез тидек... [,] имде сәне (Түләкне – Д. И.) тәхеткә күтәрәле*», – дип әйтелә бу эпик әсәрдә [Госманов: 1994. 258 б.]. Монда «тәхеткә күтәрү» дигән сүзләр нәкъ традицион гадәт турында сөйли – Алтын Урдада ханны чынлап та 4 карачы бәк ак киезгә утыртып, аны дүрт кырыннан тотып тәхеткә менгергәннәр (бу турыда карагыз: [Исхаков: 2011. С. 124.]).

Ә инде дастанда сөйләнгән Түләкнең «алтын тәхеткә» утырып халыкка бәйрәмнәр оештыруы – аның чын хөкемдар булганлыгын раслый торган тагы бер әһәмиятле күрсәткеч. Тагы бер игътибарга лаек күренеш: Түләктән соң ике ел хан булып утырган Габдулла «*дөнйадан үткәч*», аның алтын тәхете юкка чыга, бу исә ул хөкемдар булган дәүләтнең таркала башлаганлыгына бер ишарә.

Тагы бер тарихи деталь: Түләк, «олуг шәһәр» белән бәйле рәвештә ханлыкка күтәрелсә дә, кайвакытта Балкан тауга чыгып, барча халык белән бергә анда күңел ача [Госманов: 1998. 260 б.]. Бу табигатькә чыгып, җырлап-биеп, ашап-эчүләр, корбан чалулар күчмә тормыш элементлары булса кирәк. Ягъни, Түләкнең халкы, малы әле җәйләүгә чыга торган булган. Алтын Урданың XIV-нче йөзнең икенче яртысы – XV-нче йөзнең башларындагы яшәеш формаларын мондый рәвештә тасвирлау дөреслеккә туры килә.

Иң ахырдан әйтеләсе нәрсә шул: Болгар вилайәте җирлегендә хөкемдар булып торган кыйат кабиләсе вәкилләре (аларның хәзер, ким дигәндә, өч буыны чамалана: Мирказый бий → Түләк хан → Габдулла хан) турында аерым сөйләшү кирәк. Чөнки Габдулла белән бәйле легендар Алтынай (Алтынбай) солтан һәм Галим бәк (соңгысы – «Казан вотчичы» буларак), инде әйтелгәнчә, икесе ике шәхес булып, бәлки, турыдан-туры үзара туган булмаганнардыр, ләкин алар арасында әле моңарчы ачылмаган бер бәйлелек бар. Аның төбенә төшү өчен сакланып калган тарихи риваятьләрне һәм язма чыганакларны анализлау кирәк. Бу эш язмабызның алдагы өлешендә башкарылыр.

**§ 3. Дастанда һәм тарихи риваятьләрдә, елъязмаларда Болгардан Иске Казанга күченү мәсьәләсе**

«Түләк һәм Сусылу» дастанында вакыйгалар Габдулла б. Түләкнең үлеме белән тәмамлана, ә бу эпик әсәрдә күрсәтелгән кыска гына вакытта (ике ел) ханлык итеп алган шәхеснең ничек үлүе турында без тикшерә торган эпик әсәр бер сүз дә әйтми. Әмма, Аксак-Тимернең Алтын Урда җирләренә һөҗүме вакытында (ә алар ике мәртәбә – 1391, 1395–1396-нчы елларда булган) Болгарда хөкемдар булып утырган Габдулла хан турында татарларда күп санлы риваять / легендалар сакланган, аларның бер өлеше язма чыганакларга да (мәсәлән, «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәренә) үтеп кергән, хәлбуки, алар систематик рәвештә һәм тулысынча өйрәнелмәгәннәр (бу өлкәгә караган төп аналитик хезмәтләр берничә генә: [Шпилевский: 2012; Атласи: 1992; Фахрутдинов: 1984. С. 153–166; Мустакимов: 2008; 2009-б; Исхаков: 2013-б]).

Инде аңлашылгандыр, өйрәнелә торган дастанның ахырында гына пәйда булучы Габдулла хан Болгар вилайәте белән Казан ханлыгын тоташтыручы әһәмиятле сәяси фигура булып тора, әмма дастаннан тарихка күчкәндә, ул шәхес буенча без шактый каршылыкларга очрыйбыз.

Аларның бер өлеше инде каралды, ләкин игътибардан читтә калганнары да бар. Мәсәлән, мондый проблема: тарихи Абдаллах Мамай Урдасында 1361/62–1369/70-нче еллар арасында хөкем итсә (аның исеменнән сугылган тәңкәләр шул даталарны бирәләр), ул ничек итеп Болгар вилайәтенең сәяси үзәге булган Болгар шәһәрендә Аксак-Тимер дәверендә дә, ягъни өч дистә елдан соң, тәхеттә утырган? Аның дастан буенча ике ел гына тәхет биләүен тарихи мәгълүматлар белән ничек килештерергә? Гомумән, ул «алтын тәхеттә» хан буларак утырганмы, әллә аның чынбарлыктагы статусы башка төрлерәк булганмы? Шуның өстенә, инде әйтелгәнчә, дастанда күрсәтелгән Габдулла б. Түләк атасыннан соң хөкем итсә, тарихи Түләк Мамай Урдасында Абдаллахтан соң тәхет били

һәм тәхеттә утыру буенча алар арасында 15–16 еллык ара бар (Түләк, яки Түләкбәк, 1377–1380-нче елларда хан була (тулырак карагыз: [Исхаков: 2013-б]). Алай гына да түгел, Абдаллахтан соң Мамай Урдасында, ким дигәндә, тагы бер шәхес – Мөхәммәд-Бүләк (1369/70 – 1376/1377-нче елларда) хан булып ала [Исхаков: 2013-б. С. 38].

Куелган сорауларга җавап табу җиңел түгел, чөнки Алтын Урданың бер кисәге булган Болгар вилайәтенең безне кызыксындырган XIV-нче йөзнең икенче яртысы – XV-нче йөз башлары чоры буенча тарихи мәгълүматлар бик аз. Шулай да алар бөтенләй юк дип әйтеп булмый һәм безгә элегрәк чыккан кайбер эшләребездә аларга анализ ясарга туры килде (карагыз: [Исхаков: 1999; 2000-а; 2000-б; 2005; 2006; 2009-б; в; г; 2010-а; 2010-б]). Югарыда бирелгән сорауларга җавап эзләгәндә ул хезмәтләрдә китерелгән күзәтүләрне һәм нәтиҗәләрне дә куллана алырбыз.

Иң беренче мәсьәлә – Болгар вилайәтенең Алтын Урда эчендәге урыны һәм шуңа бәйле рәвештә аның белән идарә итү үзенчәлекләре турында. Билгеле булганча, элекке Болгар дәүләтенең Җучи Олысына кушылганнан соңгы дәвердәге бу җирләрнең ничек идарә ителүе мәсьәләсе буенча 1370-нче елларга кадәр тарихи чыганакларда ачык кына мәгълүматлар күренми (булганнарын тикшерүне карагыз: [Фахрутдинов: 1984]). Әмма, без өйрәнә торган чор буенча рус чыганакларында (күбесенчә, елъязмаларда) әйтелгән өлкәгә караган әһәмиятле информация бар (аларны үз вакытында Һ. Атласи да бераз тикшергән иде [Атласи: 1993]). Алга таба без аларга тукталырбыз, чөнки Түләк һәм Габдулланың, бигрәк тә, Габдулладан соң килгән Казан (Болгар) вилайәте белән бәйле инде безгә таныш фигураларның (Алтынбәк, Галим бәк), Болгар вилайәтендә нинди сәяси функциягә ия булганнарын шуннан башка бөтен тулылыгы белән аңлап бетереп булмый.

Инде Болгар вилайәтендә 1370-нче һәм 1376-нчы елларда булган сәяси вакыйгалар турында язганда ук рус елъязмалары «Болгар кнәзе» һәм аның белән бергә Болгар шәһәрендә утырган «солтан» титуллы шәхесләр булганлыгын күрсәтәләр. Аннан соң да 1398/1399, 1408, 1410–1411, 1429-нчы елларга караган һәм шул ук биләмә белән бәйле вакыйгалардан күренә – монда чынлап та «князь»/бәк, би титуллы идарәчеләр белән бергә царевич/«солтан» титуллы, ягъни Чыңгызыйлар нәселеннән булган шәхесләр дә утырганнар. Алай гына да түгел, 1429-нчы елны безгә таныш булган «князь Али Баба» белән бергә хәрәкәт иткән «царевич» (димәк, «солтан») дип билгеләнгән шәхес Шибан нәселеннән булган, дип уйларга урын бар. Шулай ук, 1428/1429-нчы елга караган мәгълүмат нигезендә Болгар вилайәтенең турыдан-туры Шибанид Абул-Хайр

ханга (күчмә үзбәкләр дәүләтенең ханы, бу берләшмәнең сәяси үзәге башта Чимги-Тура шәһәрендә була) буйсынганлыгы билгеле (тулырак карагыз: [Исхаков: 2013-б]). Менә нәкъ шушы урында яңадан искә төшерик – Абдулгаффар Кырыми үзенең «Умдәт ул-әхбар» исемле хезмәтендә Олуг-Мөхәммәд ханның Казанга килеп аны «хәйлә белән» алуын тасвирлаганда, шушы ук эпизод турында элегрәк язган (XVI-нчы йөз) Үтәмеш-хаҗидан аермалы буларак, аның бу шәһәрне «нәселе Шибаннан булган Алтынай солтаннан» алуы турында әйтә [Кырыми: 2014. Кн. 1. С. 126 б.; Кырыми: 2018. Кн. 2. С. 84]. Исегезгә төшерәм, Үтәмеш-хаҗи хезмәтендә дә бу вакыйгада Казан ягыннан ике шәхес катнаша кебек, чөнки анда сөйләнгәнчә, Олуг-Мөхәммәд хан «Казан вилайетин... Албай (ягъни, Али / Гали бәй – Д. И.) [һәм] Алтун байдин» (бусы, һичшиксез, Алтынай солтан – Д. И.) ала [Утемиш-хаджи: 2017. С. 80, 155]. Бу хәбәрләр тагы бер тапкыр Болгар / Казан вилайәтендә Шибанидлар утырганлыгын раслыйлар. Аларга нык игътибар итәргә кирәк, чөнки Шибанидлар белән бәйле рәвештә без бу биләмәдәге кыйат кабиләсенең эзләренә дә төшә алабыз.

Шибанидларның Болгар вилайәтендә утыруларының озын тарихы бар һәм ул тарихның кайбер кисәкләрен төрле чыганаклар аркылы торгызып була. Әйтик, татар тарихчысы Х. Әмирхановның «Таварих-е Булгарийа» (1883) дип аталган хезмәтендә танылган төрек галиме, тарихчы Кятиб Чәләбиның «Җиһан-намә» дип исемләнгән хезмәтеннән мондый өзек китерелә «...Искә алынган халык (сүз болгарлар турында бара – Д. И.) Шәйбан б. Жучи б. Чыңгыз һәм Кишилу хан тарафыннан идарә ителгәннәр» [Амирханов: 2010. С. 39]. Монда аталган «Кишилу хан» исеме тарихта билгеле түгел, ул бераз бозылган исем булса кирәк. Ләкин ул һәм Шибан Болгар вилайәте белән бәйле рәвештә тагы бер чыганакта искә алына. Сүз Казанда яшәгән галим А. Кавелин (XIX-нчы йөз) мәкаләсе турында бара. А. Кавелин Болгар шәһәрчелеген өйрәнеп йөргәндә, Аксак-Тимер турында бер дастан язып ала (яисә кулында булган текстын китерә), ә анда мондый юллар булган: «Абдаллах-хан, владевший городом Болгаром», [происходил] «от поколения хана Джужи, сыновей его Байярки (Берке булса кирәк – Д. И.), Шибана (димәк, Шибан да искә алына – Д. И.) и Кашела ханов». Өстәп, анда әйтелә: «Шабан һәм Кашела-хан болгар халкы белән абыйлары Боярки-ханнан соң» идарә иткәннәр, дип [Кавелин: 1847. С. 57]. Бу урынны анализлаганда истә тотыйк: Берке (1209–1266) – Җучиның өченче улы, ә Шибан – бишенчесе. Димәк, ул Беркедән яшьрәк булган. Шулай булгач, дастан тарихи яктан дөрес мәгълүмат бирә. Күренә ки, Шибан тарихи чыганакларда берничә мәртәбә Болгар вилайәтенең «халкы» белән мөнәсәбәтле рәвештә чагыла. Бу юкка гына түгел.

Чынлап та, Монгол империясе гаскәрләренең «көнбатыш походлары» вакытында (1230–1240-нчы еллар) Болгар дәүләтен яулап алу турында сөйләнгәндә (1236-нчы елның көзе), ул вакыйгада катнашучылар арасында Җучи да, монголлар гаскәрендә әһәмиятле урын тоткан Бурулдай баһадир да искә алыналар. Соңгысы исә темник булган һәм кыйат кабиләсенең 10 меңлек гаскәрен җитәкләгән [Исхаков: 2009-в. С. 25]. Әгәр дә без Абдулгаффар Кырымида булган бер хәбәргә игътибар итсәк – ул Бурулдай бәкне (нойонны) Шибанның аталыгы дип күрсәтә [Кырыми: 2014. Кн. 1. С. 63 б.] – кыйатлар иң баштан ук бу шәхес белән «береккән» булып, аның биләмәсенә караган булырга тиешләр. Ягъни, әгәр дә Шибанның Болгар дәүләте җирләрен биләүе дөрес булса, аның белән бәйле кыйатлар да янында калган булырга мөмкиннәр. Димәк, Шибанидлар Болгар вилайәтендә XIII-нче гасырдан ук үзләренә буйсынган кабиләләр белән калганнар, дип уйлый алабыз. Алар кулында бу өлкә тулысынча булганмы – бусы билгесез. Без анализлаган чыганаклар (карагыз: [Исхаков: 2013-б]) Шибанидларга күбрәк элекке Болгар дәүләтенең көнчыгыш төбәкләре (Биләр шәһәрен дә кертеп) буйсынган, дигән нәтиҗәгә китерә. Биләр шәһәренең аларга караганлыгы турында сөйләнгәндә истән чыгармыйк: «Түләк һәм Сусылу» дастанында да аның герое үзенең туган җиренең сәяси үзәген «олуг шәһәр» дип атый, ә ул исем астында, инде әйтелгәнчә, Биләр шәһәре күз алдында тотылырга мөмкин. Ни өчен Шибанның үзеннән башлап Шибанидлар анда калганнар, ә Болгарда түгел? Чөнки Болгар дәүләтенең элекке башкаласы шунда булган, ә Алтын Урда вакытында билгеле Болгар шәһәре соңрак дәвердә генә зур шәһәргә үсеп җитеп, яңа сәяси үзәккә әйләнгән.

Югарыда ясалган нәтиҗәләр беркадәр гипотетик булсалар да – ә шуңа охшаган фикерләр, ләкин бүтән хронологик рамкаларда (XIV-нче йөзнең ахырлары) башка галимнәр тарафыннан да әйтелгән иде [Мустакимов: 2009]) – аларга нигезләнеп Габдулла ханның сәяси варислары булган Алтынбәк (Алтынай) һәм Галим бәк турында моңарчы төгәл итеп язылмаган мәсьәләләр буенча фикерләрне дә әйтә алабыз (тулырак итеп бу шәхесләр турындагы элекке историографик тупланмаларны карый аласыз: [Фахрутдинов: 1984; Мустакимов: 2009-а]). Моның өчен тагы татарларда сакланган тарихи риваятьләргә мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк.

Бу үзенчәлекле чыганаклар XIX-нчы йөздән башлап күп тапкырлар басылсалар да (еш кына рус теленә тәрҗемә ителеп), безне кызыксындырган мәсьәләләр буенча моңарчы аларны комплекслы тикшерү үткәрелмәде (историографияне карый аласыз: [Фахрутдинов: 1984]). Шунлыктан, алга таба фикер йөртү өчен башта темага караган рива-

ять / легендаларның барлык версияләрен дә барлап чыгып, алар эчендә сакланган тарихи «ядрәне», ягъни, чыганаклар өчен хас булган уртак (инвариант) бер мәгълүмати нигезне җыйнау кирәк. Моның өчен беренче чиратта «Татар халык иҗаты» сериясендә басылган «Риваятьләр һәм легендалар» томындагы Габдулла ханның үзенә һәм аның варисларына караган мәгълүматларга мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк. Ләкин алар белән генә чикләнергә ярамый, чөнки тикшерелә торган темага караган кайбер әһәмиятле легендар мәгълүмат күрсәтелгән хезмәткә кертелмәгән, яисә андый материалны басмага хәзерләү дәверендә тарихи риваятьләрнең төрле версияләрен «гомумиләштергәндә» аларның эчтәлегендә булган, әмма фольклор белгечләрен кызыксындырмаган, информация төшереп калдырылган. Хәзер исә безгә андый урыннарны яңадан торгызырга кирәк. Ни өчен бу эшнең башкарылырга тиешлеген түбәндә яхшырак төшенерсез, дип уйлыйм.

Анализны «Янмый торган кыз» турындагы дастаннан башлап җибәрсәк, дөрес булыр. Әмма ул дастанга тотынганчы, бер искәрмә ясарга кирәк. Казан галиме А. Кавелин күрсәтеп үткәнчә, аның кулында шушы эпик әсәрнең И. Хәлфин тарафыннан эшләнгән рус теленә тәрҗемәсе булып, ул аның кыскартылган өлешен генә бирә (карагыз: [Кавелин: 1847. С. 55, 58]). Кызганычка каршы, дастанның (А. Кавелин аны «повесть», «татарская легенда» дип атый) оригиналы сакланмаган һәм аның татар телендә басылган версиясе [Татар халык иҗаты: 1987. 35–36 бб.] рус телендә нәшер ителгән вариантның кире татарчага тәрҗемәсе генә, әле шуның өстенә ул кыскартылып та бирелгән һәм андагы кайбер сюжетлар төшереп калдырылган (карагыз: [Шунда ук.]. Шуңа күрә дә А. Кавелин хезмәтендә бастырылган дастаннан (ул аның тулы исемен мондый рәвештә бирә – «О несгораемой прекрасной болгарской царевне и двух ея братьях, воспитанных в лесу») төп өзекне китерик: «...у хана (Абдаллах хан турында бара сүз – Д. И.) было три сына: два сказанных [выше] (Галым-бек һәм Алтун-бек исемнәре атала – Д. И.) и третий Шеуне-бек (младший). Дети эти воспитывались вместе в одной школе с детьми Тамерлана, но по покорении им города Болгара, двое были скрыты, а последнего Тамерлан взял к себе с его сестрою в Самарканд, где находился при нем, а по смерти его при дворе сына, в числе служителей...» [Кавелин: 1847. С. 58]. Бу урыннан башка әйтелгән автор шул ук дастаннан тагы ике өзек китерә: 1) «...Одна из дочерей хана (Абдаллах күз алдында тотыла – Д. И.) спаслась ... обернутою в белую одежду муллы Хисаметдина (почитавшегося тогда за святого), гробница которого стояла под одною палатою на ханском кладбище, близ минарета (Болгарда – Д. И.)… 2) Тамерлан … взял ее и брата с собою. По смерти Тамерлана они нахо-

дились в услужении у его сына (алга таба Шеуне бәкнең хан сараенда ясаган ялгышы һәм ханның аны үтерергә теләгәнлеге турында сөйләнә) ... <шул вакытта> ... их учитель упросил хана и Шеуне-бек был прощен… Впоследствии Шеуне-бек пришел с сестрою в болгарский город Кошан … работал там учителем…, узнав, что братья основали новый город Казань, где и царствуют, отправился к ним на житье. Сестра … [вышла] замуж за братина полководца Мулла-Хозятаз[а] и Софин-харака [который] и был вместе с Алтун-беком основателем Казани, где и умер. Могилу в Эски-Казани легенда называет могилою этого муллы, почитаемого за святого, а могилу сестры [Алтун-бека и Галым-бека] … [указывают] [в] русской деревне Айши … По истечении … времени Шеуне-бек удалился из Казани в Болгар, где и был с радостью принят народом и сделался ханом под именем Шадибека. Здесь заканчивается предание» [Кавелин: 1847. С. 58–59].

Шулай итеп, И. Хәлфин тарафыннан А. Кавелинга русчага тәрҗемә итеп бирелгән бу дастанда инде безгә таныш булган һәм кайбер яңа шәхесләр дә пәйда булалар. Абдаллах хан, аның өч «улы» – Галим (Галым) бәк, Алтун бәк һәм кече туганнары Шеуне бәк, шулай ук исеме аталмаган аларның бер кыз туганы. Чынлыкта, соңгысының исемен дә торгызып була, чөнки югарыда әйтелгән «болгар царевна»сының кабере халыкта «Гайшә бикә кабере» дип билгеле, ул күмелгән җиргә якын авыл исә кайбер татар чыганакларында «Гайшә бикә авылы», дип билгеле [Фахрутдинов: 1984. С. 155]. Димәк, Аксак-Тимер кулына Шеуне бәк һәм аның кыз туганы Гайшә (Айшә) бикә – «болгар ханбикәсе (царевна)» – эләгәләр һәм дастан буенча Аксак-Тимер дәүләтенең башкаласы булган Сәмәркандка алып кителәләр. Ул биләмәдән алар Аксак-Тимер үлгәч, аның варисы (исеме аталмый) кул астында күпмедер яшәгәч кенә, туган якларына кайтарылып җибәреләләр. Кайткач, алар башта «Кошан» атлы «Болгар шәһәрендә» яшәп алалар, аннан абыйлары хөкем иткән «яңа шәһәргә», ягъни, Иске Казанга, киләләр. Шунда Гайшә бикә Алтын бәк белән бергә Иске Казанга нигез салучы «воевода» (батыр?) дип аталган «мулла Хозятаз» (аның исеменә өстәп язылган «и Софин-харака» дигән сүзтезмәсенең мәгънәсе аңлашылмый) исемле шәхескә кияүгә чыгып, икесе дә үлгәннән соң шул тирәдә күмеләләр (Мулла Хозятаз – Иске Казанда, Гайшә бикә – аннан ерак булмаган Рус Айшәсе авылы янында). Ә Шеуне бәк берникадәр вакыттан соң Казаннан Болгарга китеп, анда «хан» булган дип әйтелә.

Бу дастандагы мәгълүмат күп кенә башка татар чыганакларында кабатланса да, аның бер өлеше уникаль: әйтик, Шеуне бәк һәм Гайшә бикәнең Сәмәркандка алып кителүе һәм аннан кире әйләнеп кайтула-

ры, аларның бер дәвердә Кошан шәһәрендә яшәүе, Шеуне бәкнең Иске Казаннан Болгарга китеп, анда хөкем итүе (хан буларак!) турындагы хәбәрләр.

Тарихи риваятьләрдәге кабатланучы мәгълүматларда да моңарчы күзгә ташланмаган аерым детальләр бар. Мәсәлән, «Иске Казан шәһәренең корылуы» турындагы риваятьтә Аксак-Тимернең Болгарны алып, анда «Болгар иленең ханы» Габдулланы үтергәнлеге турында сөйләнеп, шушы ханның хатыны – «ханбикә» белән ике «сабый баласы – шаһзадәләр» калганлыгы турында әйтелә дә, аннан соң аларны коткару өчен «Болгар шәһәренең олылары» тарафыннан «ханбикә һәм ханзадәләрне» Бүләр шәһәренә озатулары турында сөйләнә. Аксак-Тимер Болгарда күп вәхшилекләр эшләп Бүләр шәһәре янына килгәч, ханбикә үзенең Алтынбик һәм Галимбик атлы ике улын алып, басып алучы каршына чыгып, аңа баш иеп башка җиргә китеп торырга рөхсәт сорый, шуннан Аксак-Тимер аңа мондый рөхсәтне бирә һәм «берничә аксөяк вә асыл затлар ... ханбикә белән бергә ... кала коралар», бу кала Иске Казан була. Легендада сөйләнгәнчә, монда беренче хан булып Алтынбик тора, ул «илле елдан артык» ханлык итә. Аннан соң аның «кардәше» Галимбик хан булып, ул «утыз елдан артык» ханлык итә монда. Алтынбик турында мондый сүзләр әйтелә: «...Иске Казан каласында мәсҗедләр, мәдрәсәләр эшләткән, зурзур бакчалар ясаткан, читтән бик күп укымышлы кешеләр чакырткан, балалар укытыр өчен мәктәпләр салдырган... Ул Болгар дәүләте атасы чагындагы шикелле зур бер дәүләт булуы өчен дә тырышкан... Болгар шәһәрендә янмый калган Хәлиф җәмигы шәрифне һәм олы мәдрәсәне төзәттереп, имам, мөдәррисләр чакыртып, яңадан тергезгән...». Галибик (Галим бәк) турында бу риваятьтә тагы түбәндәге юллар бар: «...Болгарга, атасына зиярәткә барган чагында, вафат булган...» [Татар халык иҗаты: 1987. 45–47 бб.].

Сөйләнгән очракта иң кызыгы – Алтын бик белән Галимбикнең аналары белән бергә Иске Казанга турыдан-туры түгел, ә Бүләр шәһәре аркылы килүләре. Риваятьнең икенче бер әһәмиятле ягы – Алтын бикнең Иске Казанда зур мәдәни һәм төзү эшләре алып баруы, Болгар шәһәрен дә онытмыйча, аны да төзекләндерергә тырышуы. Ниһаять, легендада бу шәхестән соң «ханлык» иткән Галим бикнең Болгар белән элемтәсен күрсәтергә тырышу да чагыла (аның Болгардагы атасы каберенә зиярәт кылырга юнәлүе аркылы).

Башка бер, «Яңа Казан каласы корылуы» турындагы риваятьтә, Иске Казанда хан булган Галимбәк искә алына һәм бу шәһәр урынының аңа да ошамаганлыгы турында әйтелеп, яңа шәһәр кору өчен башка урын эзләргә «үзенең олыларыннан ике кеше белән улын һәм йөз чирүне» җибәрүе

турында сөйләнә. Ул урын (хәзерге Казан җирләре) табылгач, риваятьтә әйтелә: «...Шуннан соң Галимбик Болгар шәһәрендәге Хәлифә мәчетен гыйбадәт кылырлык хәлгә китерәчәген нәзер итеп әйткән», – дип [Шунда ук. 52–53 бб.]. Күренә ки, монда Болгардагы мәчетне торгызу эше башка шәхес – Галимбик белән бәйләнелә. Ләкин бу очракта безнең тикшерүнең үзәгендә булырга тиешле мәсьәлә башка – шушы һәм бүтән риваятьләрдә [Шунда ук. 50–51, 55–56 бб.] Иске Казаннан Яңа Казанга күчену Алтын бәк белән түгел, ә Галим (Гали) бәк / би шәхесенә бәйле рәвештә тасвирлана. Шуның өстенә, башка бер риваятьтә шушы күченүне оештыручы хөкемдар «Кырым ханы», дип тә билгеләнә [Шунда ук. 48 б.].

Безне кызыксындырган шәхесләр һәм вакыйгалар буенча булган риваятьләрне карап чыкканнан соң, алар белән бәйле язма чыганакларга да мөрәҗәгать итү кирәк дип табылды. Бу чыганакларны инде алда карый башласак та, ул эш әле төгәлләнмәгән, чөнки язма чыганаклар төрле дәверләргә карыйлар һәм аларның жанрлары да бер-берсеннән аерыла. Шулар арасында төп урынны алып торганнары «елъязмалар» дип аталып йөртелә (алар турында тулырак карый аласыз: [Рахим: 2004]). Әмма, язма чыганаклар арасында башка төрлеләре дә бар. Мәсәлән, инде безгә таныш булган «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәре [Усманов: 1972]. Шулай ук бу рәттә «Тәрҗемәи Ферхенг-намә», «Беан Дастан уд-тарих», «Тәварих уд-даваир» әсәрләрен дә атарга була (алар башлап Н.Н. Кафтанников тарафыннан табылып (яисә тупланып), фәнни әйләнешкә А. Кавелин тарафыннан кертелгәннәр [Кавелин: 1847. С. 57–59; Фахрутдинов: 1984. С. 154]).

Санап кителгән чыганаклар бер-берсе белән үзара катлаулы бәйләнештә торалар, ләкин ул бәйләнешләрнең тарихы тулысынча өйрәнелмәгән, шунлыктан кайсы әсәрнең башкалары өчен нигез булганлыгы әлегә ачыкланып бетмәгән. Нәтиҗәдә бер үк чыганак турында әдәбиятта каршылыклы фикерләр очратырга мөмкин. Әйтик, «Тәрҗемәи Ферхенг-намә» (башка версияләренең исемнәре – «Джада-и джанг», «Хикәйәт») әсәрен М.А. Госманов «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәре белән бәйләп карарга тәкъдим иткән булса [Усманов: 1972. С. 125], аның укучысы И.А. Мөстәкыймов, киресенчә, ул чыганакның соңгысы өчен башлангыч булырга мөмкин икәнлеген билгеләп үтте [Мустакимов: 2008. С. 145]. Үз вакытында Г. Рәхим дә «Фи бейан-и тарих» дигән бер кульъязма бастырган иде, әмма, чынлыкта ул текст та югарыда аталган «Тәрҗемәи Ферхенг-намә» әсәренә барып тоташа, дип уйларга урын бар [Мустакимов: 2008. С. 144]. Димәк, санап кителгән язма чыганакларны – ә алар барысы да диярлек теге яки бу дәрәҗәдә елъязмалар дип билгеләнгән чыганаклар белән дә тоташалар – аерым рәвештә дә, комплексны итеп тә өйрәнергә кирәк булачак. Шуны искәртик: ул язма чыганаклар әллә ни борынгы ту-

гелләр, аларның искеләре («Дәфтәре Чыңгыз-намә» һәм «Ферхенг-намә») XVII-нче йөз ахры – XVIII-нче йөзгә карыйлар [Усманов: 1972; Мустакимов: 2008].

Шулай да, бу төр чыганакларга кереп киткәнче, «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәрен тикшергән М.А. Госманов әйткән бер фикерне искә төшерик: «...[Бу әсәр] күбрәк формалары ягыннан бер-берсеннән аерылып торучы повесть-дастаннарны үз эченә алган җыентыкка охшаган» [Усманов: 1972. С. 125]. Мәсьәлә мондый рәвештә куелгач, тикшереләсе язма чыганаклар белән тарихи ривятьләр, дастаннар арасында үтеп булмаслык чикләр юк булып чыга, алай гына да түгел, беренчеләренең нигезен халык авыз иҗаты әсәрләре тәшкил итә ала. Әмма, чынлыкта бу төр чыганакларның кайсысы беренчел икәнлеген практикада билгеләү бик авыр, чөнки мантыйк буенча риваять/легендалар һәм дастаннар язма чыганаклардан өлкәнрәк булырга тиеш булсалар да, аларның кайберләре башта язма чыганакларда булып, шулар аркылы халык арасында таралган булырга да мөмкиннәр. Дөрес, дастаннарга мондый нәтиҗә азрак кагыла – алар күпчелек очракта иске заман ядкярләре буларак саналырга тиешләр һәм без шул исәпкә «Янмый торган кыз», «Фасыл фи бәйани Аксак Тимер» / «Аксак Тимер нәселе», «Фаслы фи бәяны дастаныт-тарих» / «Тарих турындагы» (соңгы икесе – «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәре эчендә) дастаннарын да кертә алабыз.

Җыеп кына әйткәндә, мондый нәтиҗә килеп чыга: безне кызыксындарган язма чыганакларны өйрәнгәндә алар белән аваздаш халык авыз иҗаты әсәрләрен (риваять / легендаларны, дастаннарны) гел истә тотарга кирәк. Менә шушы методологик нигезгә таянып, алда әйтелгән язма чыганакларны тикшерә башлыйбыз.

Беренче буларак, безне ике чыганак – «Ферхенг-намә» һәм «Хикәйәт» (соңгысы «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәренең «Фаслы фи бәяны дастаныт-тарих» белән дә бәйле [Мустакимов: 2008. С. 145]) кызыксындыра.

## 1. «Фи бейан-и тарих» («Ферхенг-намә» әсәренең варианты»)

«Фи бәйаны тарих. Тарих алты йөз туксан өчтә ирде, сыгыр йылында ирде, Мир Тимер ләшкәре берлә шәһре Балгарны капсады. Йите йылгача халка кылып йаттылар. Йәнә тарих йите йөз йылда ирде, зөлхиҗҗә айының йегермесендә шәһре Болгарны алды. Йөз йегерме түрт олуг бәллү бикләр вар[и]де, вә көллесе һәлак булдылар, һәр кайусының хатынлары кә-әмсалил-лөәлөил-мәкнүн ирде, барчасын Мир Тимер әсир кылды. Ул бикләр эчендә түрт олуг бикләр вар иде, асылы шаһзадәләр ирде. Беренең аты Икъбал бик, беренең аты Кол Гали бик, йәнә бере Хәваши бик, йәнә бере Каши [Миркаши – Д.И.] бик д[и]рләр ирде. Шәһәр вәйран булды, күп халайык һәлак булды. Габдулла хан үзе вафат булды. Ханның

ике угланын урман төбенә алып кичерделәр. Бере тукыз йәшендә, вә бере йите йәшендә ирде. Беренең аты Алтын бик, вә берсенең аты Галим бик ирде. Йахшы асрадылар. Алтын бикне ун түрт йәшендә тахытка кичерделәр. Казан дәрйасы өстендә кальга абадан кылдылар, йөз дә түрт йыл анда тордылар. Андын күчтеләр, Казан сувы тамагында шәһәрне төзделәр, йөз илле сигез йыл анда булдылар... Алтын бик дигән ирмеш, тамгалары мондаг ирмеш ×, әвернә тамгасы дирләр ирмеш. Алтын тәхетдин чыкып, Иске Казанга килделәр. Алтын тәхет дип шәһре Болгарны әйтер ирмеш. Мир Тимер килеп, шәһре Болгарны бөлдереп алып киткәндин соң, калган халкы берлә бу Алтын бик шәһре Казанда йорт тотыптыр. Ул Казанда йорт булганда Алтын бик [,] Галим бик дигән ирмеш. Галим бик Казанны йаратмай Тубыл Турага китептер, анда барып йорт тотыптыр. Иске Тубыл Тураны ул йасатыптыр. Йәнә Алтын бик Йаңа Казанга килептер. Андын соң Мәхмүд хан, йукарыда мәзкүрдер. Алтын бик, Галим бик оругларындын Кырымда һәм бар ирмеш. Ул сәбәбдин һәр заман хан кирәк булса, Кырымдын хан алырлар ирмеш Казанга. Тәммәт».

*Алынды: [Мустакимов: 2008. С. 155].*

**2. Хикәйәт (фарсы теленнән русчага тәрҗемә)**

«Одним словом, когда жители Старого Булгара избавились от резни, [учиненной] хазрат Аксак-Тимуром, оставшиеся из них собрались. Вначале Черная Идиль протекала близ Старого Булгара. Когда прошло великое побоище (мокатāле[1]), увидели, что Черная Идиль отошла [от города] на расстояние трех миль на запад. Поэтому они (жители Старого Булгара. – И.М.) сочли нецелесообразным восстанавливать [город]. Посоветовавшись, они построили новый город (кал'а) в стороне летнего заката [солнца][2], близ [реки] Черная Идиль (Идил-и сийāх[3]), на берегу реки Газāнӣ. [Новому городу] дали название Газāн. Он прозывался также «Новым Булгаром» (Булгар-и джадӣд). В том месте они прекрасно, под знаменем ислама жили некоторое время. Во всех случаях они, согласно священному шариату, прибегали к [суду] мусульманских кадиев и великих сеидов. Они (кадии и сеиды. – И.М.) также, следуя сунне Пророка, занимались прекращением распрей и пресечением вражды. В этом городе прошло царствование шестнадцати ханов. Когда для Старого Булгара (Булгар-и кадӣм) наступили тяжелые времена, его ханом был Габдулла. В то время (букв.: в тот день. – И.М.) он стал шахидом. У него осталось два сына: один – Алтун-бик, другой – Галим-бик. Чтобы не допустить пресе-

[1] Оригиналда: «мокāбале».

[2] Болгардан төньяк-көнбатышка.

[3] Фарсы телендә – Кама койган урыннан өске якка булган Идел агымы. Ә Каманың бу өлеше – Ак Идел дип йөртелгән.

чения их рода, их увезли в лес и [там] спрятали. Поэтому они спаслись. Когда построили город (букв.: крепость. – И.М.) Газāн, по давнему правилу (кāнӯн) первым ханом стал Алтун-бик. Таким [же] образом вторым [ханом] стал Галим-бик, третьим – Мухаммед...».

*Алынды: [Мустакимов: 2008. С. 153–154].*

Бу чыганак хәзер русчага тулысынча тәрҗемә ителде (карагыз: [Гибадуллин: 2019. С. 687–719]).

Югарыда китерелгән ике документаль чыгнактан тыш тагы бер чыганакка игътибар итик. Аны үзенең кулында булган «фарсыча язма бер рисаләдән» татар тарихчысы Һ. Атласи «Казан ханлыгы» исемле хезмәтендә тәрҗемә итеп китерә:

**3. Фарсыча рисалә**

«Аксак Тимер мөгамәләсеннән котылгач, Болгар халкының бер төрлесе яңа кала бина итү фикеренә килеп, җәйге кояш баешы тарафына сәфәр иттеләр. Кара Иделнең янында, Газан елгасы кырыенда бер шәһәр бина итеп, аңа Газан дип исем бирделәр. Ул урында ничә ай вә ничә еллар, көннәр уткәрделәр. Һәр эшләрендә шәригатькә афыйк казыйларга һәм олугларга мөрәҗәгать иттеләр. Аларда, иман галәмәтенчә, низаглары һәм дә үз арадагы дошманлыкларны бетерделәр. Бу Казанда 16 падишаһ булып үтте [Монда Казан ханлыгында хөкем итүчеләр күз алдында тотыла – Д. И.]. Болгарга авырлык килгән заманда аның Габдулла исемле ханы бар иде. Ул шулчакларда үлеп, аның Алтынбәк вә Галимбәк исемнәрендә ике угылы калды. Нәселләре киселүдән куркып, аларны урманга яшергәннәр иде. Шуңа күрә сәламәт калдылар, Казанны бина иткәч, борынгы йола буенча, Алтын-бәк хан булды. Казан падишаһларының икенчесе – Галимбәк, өченчесе – Мөхәммәд...»

*Алынды: [Атласи: 1992. 198 б.].*

Китерелгән текст югарыда русчага тәрҗемә рәвешендә бирелгән «Хикәйәт» текстына бик якын (баш өлешендә бераз кыскартылган гына). Шуңа күрә дә И.А. Мөстәкыймов Һ. Атласи хезмәтендә басылган өзекне, М.А. Саләхетдинова фикеренә кушылып, «Хикәйәт» белән бер үк чыганак дип саный [Мустакимов: 2008. С. 144]. Бу фикер белән килешергә мөмкин. Чынлыкта, инде элегрәк фәнни әдәбиятта күрсәтелгәнчә (карагыз: [Усманов: 1972. С. 124]), бу текстның татарча версияләре дә булган һәм аларның берсе 1937-нче елны нәшер ителгән «История татар в документах и материалах» исемле хезмәттә русчага тәрҗемә итеп бастырылган [История: 1937. С. 122–123]. Китаптагы искәрмәләрдә әйтелгәнчә, ул «елъязма», 1864-нче елга караган Нурмөхәммәт б. Әзмәтҗан кулындагы

җыентыкта булып, алга таба Казанда яшәгән С. Атнагуловка күчкән булган [История: 1937. С. 133]. Ләкин, тикшерә торган өзек барыбер ахыр чиктә XVIII-нче гасырга караган һәм Идел буенда таралган фарсы телендәге әле өйрәнелеп бетмәгән бер кульязмадан алынган, дип уйларга урын бар [Салахетдинова: 1965. С. 148].

Тагы бер карала торган төркемгә кертелергә тиешле чыганак – «Дәфтәре Чыңгыз-намә» (XVII-нче йөз ахыры). Бу чыганак яхшы гына өйрәнелгән һәм аның аерым версияләре (барысы да түгел) басылган да (тарихын тикшерүне карый аласыз – [Усманов: 1972]). Аның текстын күп тапкырлар бастырдылар (без кулланачак вариант: [Мирастан: 2011. 40–92 бб.]). Менә ул әсәрдән өзекләр.

### 4. «Дәфтәре чыңгыз-намә» әсәрендәге өлешләр

#### 4.1. «Фи бейан-и тарих» («Ферхенг-намә» әсәренең варианты)

«...[Аксак-Тимер] ... Хаҗи Тархан шәһәренә килде. Орышып-сугышып, Хаҗи Тарханны да алды, буйсындырды. Анда биш-алты ел торды. Аннан соң янә Болгар шәһәрен алырга хәзерләнде. Күп хәрби көймәләр белән Болгар шәһәрен алырга килде. Кайбер сугышчылары ... көймәнең тышыннан килделәр... Алар монда гаскәр белән килгән дәвердә Болгар шәһәрендә Габдулла дигән хан иде. Габдулла ханга хәбәр иреште. Аксак-Тимер килә, дип. Шул заман Габдулла хан гаскәрен җыйды. Алар бер-берсе белән каты орыш кылдылар. Аксак-Тимер һөҗүменә түзмәделәр, сындылар. Килеп Болгар шәһәренә керделәр. Үлгәне – үлде, калганнары шәһәргә кереп бикләнделәр. Аксак-Тимер Шәһри Болгарны җиде ел камап торды. Тарих җиде йөз елда иде, зөлхиҗа аеның егермесендә Шәһри Болгарны алдылар, харап кылдылар. Йөз дә егерме дүрт олуг бик бар иде, аларның барысын да кырдылар. Һәркайсының энҗе кебек хатыннарын Аксак-Тимер әсир кылды. Ул бикләр арасында дүртесе асыл шаһзадәләр иде. Берсе – Икбали бәк, берсе – Кол Гали бик, янә берсе – Хаши бик, янә берсе Миркаши бик исемле иде. Һәркайсын һәлак кылдылар. Бик күп халык һәлак булды. Габдулла ханны да үтерделәр, әмма Габдулла ханның ике улы бар иде. Берсе – Алтынбик, икенчесенең аты Галимбик иде. Берсе – җиде яшендә, икенчесе тугыз яшендә иде. Яудан качып калган кешеләр Алтынбикне урман эченә илтеп яшерделәр. Аларны яхшы асрадылар. Аннан соң Аксак-Тимер ... Бүләр шәһәренә килде...»

*Алынды: [Мирастан: 2011. 60 б.].*
*Текст хәзерге әдәби телдә бирелә.*

#### 4.2. «Фасыл фи дастан фит-тарих»

«Җиде йөз елда иде Аксак-Тимер Шәһри Болгарны алды, Габдулла ханнан. Габдулла ханның ике улы бар иде. Берсе – Алтынбик, икенче-

се – Галибик. Бөлгенлектән соң килеп, Казан елгасы өстендә кала ясадылар, шәһәр иттеләр. Ул халык йөз дә дүрт ел анда торды. Ахыр ул урынны яратмыйча күчтеләр. Казан суының тамагында шәһәр төзеделәр. Йөз дә илле сигез ел анда булдылар... Казан шәһәрендә йорт биләгән ханнарның атлары болар: әүвәл Габдулла хан улы Алтынбик хан[,] Галибик хан. Аннан соң Мәхмүд хан...»

*Алынды: [Мирастан: 2011. 68 б.].*
*Текст хәзерге әдәби телдә бирелә.*

Шушы язма рәвештә сакланган чыганакларның бер-берләренә бәйле булганлыклары да, икенче төркем – «тарихи елъязмалар» дип аталганнарына мөнәсәбәтләре дә текстларны укыганда бик яхшы ачыла. Моның шулай икәнлеген ныграк нигезләү өчен безгә берничә «елъязма» дип билгеләнүче текстны карап үтү дә кирәк. Бу төр чыганакларга танылган татар тарихчысы Г. Рәхим инде игътибар иткән иде [Рахим: 2004], элегрәк ул турыда башка галимнәр дә яздылар (карагыз: [Катанов, Покровский: 1905]). Шунлыктан, аларга гомуми характеристика бирмичә, чыганакларның үзләрен генә китереп китәбез.

Беренче чыганакны Г. Рәхим XVII-нче гасыр ахрына кайтарып кала һәм аның «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәренең соңгы өлешенә тоташтырылган булганлыгын искәртә (кульязманың Меңгәр авылы мулласы кулында сакланган икәнлеген дә әйтә) [Рахим: 2004. С. 560]. Ул текст Г. Рәхим тарафыннан русчага тәрҗемә ителгәнлектән, аны русча китерәбез.

### 1. «Хикәят әсхаб фил»

«Глава в изложении повести по истории. Было даты в семисотом году Хромой Тимур взял город Болгар у хана Абдуллы. У хана Абдуллы было два сына: один из них Алтун-бик, (а) другой Алим-бик. После того разорения поставили над рекой Казанкой крепость, основали город. Тот народ прожил там сто четыре года; наконец, не возлюбивши того места, выселелись оттуда (и) у устья реки Казанки построили город. Сто восемь лет прожили там... Теперь, имена ханов, владевших юртом в городе Казани, следующие – сперва Абдулла-хан, сын Абдуллы-хана Алтун-бик, после него Махмудхан...».

*Алынды: [Рахим: 2004. С. 566].*

Әгәр дә без бу текстны югарыда китерелгән «Фасыл фи дастан фиттарих» дип исемләнгән «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәрендәге бүлек тексты белән чагыштырып карасак, ике детальдан башка (яңа Казанга күчкәнче Иске Казанда 158 ел тору һәм Казандагы ханнар исемлегендә Алим бикнең булмавы буенча) алар икесе дә эчтәлек ягыннан туры киләләр икәнлеген күрә алабыз. Алай гына да түгел, шул ук чыганакны, аның 1784-нче

елны Багаутдин исемле шәхестән алынган «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәре кульязмасы («Рукописи о Чингиз-хане») эчендә булганлыгын күрсәтеп, Н.Ф.Катанов һәм И.М.Покровский да китерәләр [Катанов, Покровский: 1905. С.309]. Шул ук галимнәр ул текстның тагы бер версиясен (ул Н.Н.Пантусов кулында булган 1864-нче елгы (яисә, 1902-нче елны аннан күчерелгән) «Дәфтәре Чыңгыз-намә» / «Книга о Чингизе» әсәренең бер кисәге) бастыралар, анда фәкать тик башлангыч өлештәге «700-нче ел» урынына «по истинным словам был 800-й год» [Катанов, Покровский: 1905. С.318], дигән сүзләрдә генә аерма бар. Соңыннан менә шушы дата белән аны совет чорында да бастырдылар [История: 1937. С.95]. Әмма, фактта барлык әйтелгән очракларда да без бер үк текстны күрәбез һәм ул шактый иртә чорга – XVII-нче гасырның ахырларына караган текст булып чыга. Тагы бер инде алдарак китерелгән язма текст Казан университеты профессоры И.Г.Яковкин кулында булган. Ул «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәренең бер оригиналь варианты булган булырга охшый.

## 2. Профессор И.Ф.Яковкин кулында булган кульязмадан өзек

«...Тамерлан ... против Болгар ... [в] 700г. ... умертвил хана Абдуллу ... 124 знатныя фамилии, женщин их взял в плен, а город разорил. Сей Абдулла хан происходил от поколения хана Джужи, сыновей его Бярки, Шибана и Кяшела ханов; сии два последних владели народом Болгарским после Бярки хана … Некоторые люди скрыли двух сыновей [Абдуллы хана] … Галим-Бека и Алтун-Бека (из которых первый был 9-ти, а второй – 7-ми лет)… Князья Галим-Бек и Алтун-Бек основали Казань на реке Казанке … царствовали в Казани … потом перенесли … основали нынешнюю Казань в 804г.х. …».

*Алынды: [Рыбушкин: 1833. С.1171].*

Аңлашыладыр, бу чыннан да шул ук «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәрендә булган текстның бер версиясе, әмма, анда Абдулла ханның Шибан нәселеннән икәнлеген күрсәткән бик әһәмиятле өстәмә бар. Китерелгән мисал «Дәфтәре Чыңгыз-намә» исемле чыганакларның барлык версияләрен дә җыеп бастыру кирәклеген күрсәтә, ә бу эш әле башкарылмаган.

Тагы бер кульязма рәвешендә билгеле булган тарихи чыганак турында А.Кавелин хәбәр итә һәм аны «Товариш ут-Даваир» дип атый [Кавелин: 1847. С.57]. Исеменә караганда, ул елъязма булган булырга мөмкин, шуңа күрә дә Р.А.Фәхретдинов аны «Тәварих уттава ир» дип исемли [Фахрутдинов: 1984. С.154]. Кызганычка каршы, ул кульязма сакланмаган һәм аннан фәкать тик А.Кавелин хезмәтендә китерелгән бер юл гына

билгеле: «...Галим-бек ... пришел в болгарский город Кошан, где был учителем...» [Кавелин: 1847. С. 57]. Бу фразага караганда, аның эчтәлеге «Янмый торган кыз» дастаны белән охшаш булган, дигән уй килә. Шуңа күрә дә ул, бәлки, елъязма булмагандыр.

Шулай итеп, каршыбызда төрле жанрларга (дастаннар, риваять / легендалар, елъязмалар) караган бер компендиум тарихи чыганаклар җыелмасы килеп баса. Аларның барысы да Габдулла (Абдулла, Абдаллах) хан, аның «уллары» һәм бер кызы аркылы бер-берсенә бәйләләр, ә бу шәхесләр исә «Түләк һәм Сусылу» дастанының төп герое Түләкнең улы булып саналган Габдулла хан варислары булып чыгалар. Чынлыкта, югарыда китерелгән татар чыганакларында Урта Идел буенда урнашкан Болгар / Казан вилайәтенең Алтын Урда таркалгандагы XIV-нче йөз ахыры – XV-нче йөзнең беренче яртысы арасында булган тарихы чагыла һәм аны шушы чыганакларга нигезләнеп өйрәнсәң, бик тә кызыклы яңа нәтиҗәләргә килеп чыгасың.

1) Тарихчылар арасында хәзерге вакытка кадәр Тимурның Алтын Урда дәүләтенә 1391, 1395/96-нчы елларда яу белән килгәндә Болгар вилайәтенә барып җитүе турындагы мәсьәлә буенча бәхәсләр бара [История татар: 2009. Т. III. С. 706–712; Сафаргалиев: 1960. С. 154–155, 166], чөнки ул походларны тасвирлаган тарихи чыганакларда бу вакыйга турында төгәл генә мәгълүмат юк. Ә менә татар чыганаклары аның мондагы җирләргә килгәнлеге турында сөйлиләр һәм Болгар шәһәре халкының Иске Казанга күченүен дә шушы вакыйга белән бәйлиләр. Шулай ук халкыбызда Аксак Тимергә бик тискәре бәя биргән бәетләр дә сакланган (карагыз: [Татар халык иҗаты: 1987. 29–30 бб.; Татар эпосы. Бәетләр: 2001. 72 б.]). Мондый бертавыштан Болгарның Аксак-Тимер тарафыннан алынуы турындгы хәбәрләргә, мөгаен, ышаныч белән карарга кирәктер. Шунлыктан, күренекле татар тарихчысы М. Г. Сафаргалиевнең ул вакыйганы 1395-нче ел белән билгеләгәнлеген истә тотарга кирәк [Сафаргалиев: 1960. С. 155].

2) Барлык татар чыганаклары да Тимурның Болгар вилайәтенә ясаган һөҗүме вакытында анда хан булып утырган һәм Болгар шәһәре алынганда үтерелгән Габдулла (Абдаллах, Абдулла) исемле шәхестән соң аның ике яки өч улы һәм бер кызы исән калуы турында сөйлиләр. Ләкин, аларның Тимур тарафыннан Болгар шәһәрен алу белән бәйле эпизодтагы язмышлары төрлечә тасвирлана. Күпчелек очракта Габдулланың ике улы – Алтынбик (Алтын бәк / бик) һәм Галим (Гали, Галым) бәк (бик) төньякка, урман эченә качырылалар һәм шунда Казанга (Иске Казанга) нигез салалар, дип сөйләнелә. Әмма кайбер риваятьләрдә сүз Габдулла ханның хатынының (ханбикәнең) һәм югарыда исемнәре аталган ике «сабый

баласының» башта Бүләр шәһәренә озатылуы турында әйтелеп, аларның Аксак-Тимер рөхсәте белән генә Иске Казанга килеп, анда «кала» корганлыклары турында хәбәр ителә. «Янмый торган кыз» дастанында, гомумән, Габдулланың Шеуне бәк исемле улының һәм Айшә (Гайшә) атлы кызының Тимур тарафыннан Сәмәркандка алып কителүе һәм аларның аннан кире әйләнеп кайтулары (башта – Кошан шәһәренә) ул әмир үлгәч кенә булганлыгы турында хәбәр ителә. Бер очракта (чыганак тулы килеш сакланмаган) Галим бикнең дә «болгар шәһәре» Кошанда яшәп, анда Шеуне бәк төсле укытучы булып торуы турында әйтелә. Димәк, Габдулла хан варислары Болгар харап булган вакытта, бәлки, Иске Казанга бераз вакыттан соң гына күчерелгәннәрдер, ә ул күчерелү турыдан-туры түгел, ә Бүләр һәм Кошан (Кашан) калалары аркылы булган булырга да мөмкин (Кошан шәһәрлеге Кама елгасының уң ягында, хәзерге Олы Елга һәм Шуран авыллары тирәсендә, Саескан тавы (Сорочьи Горы) авылыннан 1 верстага түбәнрәк, Кама елгасыннан кичү янында булган [Пономарев: 1893]). Әмма, кайбер очракларда легендаларда Кошан шәһәре исеме килеп чыгуының башка бер сәбәбе дә булган булырга мөмкин – нәкъ шул шәһәр турысында искедән Кама елгасы аркылы кичү урнашкан булганлыктан, бәлки, Габдулланың «уллары» Иске Казанга шул кичү аркылы күчерелгәннәрдер.

3) Габдулла ханның варислары Иске Казанга җыелганнан соң булган вакыйгаларда да игътибарага алырга кирәкле нюанслар бар. Беренчедән, монда Мөхәммәдкә (Олуг Мөхәммәдкә) кадәр «йорт тоткан» Габдулла ханның варислары турында чыганакларда кызыклы үзенчәлекләр күзәтелә. Күпчелек очракта Габдулла ханнан соң Иске Казанда (Болгар әл-җәдидтә) хан булып утыручылар мондый тәртиптә күрсәтеләләр: Алтынбик (Алтын бәк) → Галим (Гали) бик → Мөхәммәд (ягъни, Олуг Мөхәммәд). Бер караганда, Алтынбик белән Мөхәммәд (Олуг Мөхәммәд) арасында Казан/Болгар вилайәтендә хөкемдар булып торган Галим (Гали) бәк бу ике шәхестән сәяси статусы ягыннан аерылып тормаган кебек күренә. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Әйтик, «Янмый торган кыз» дастанында Алтынбик үзенең батыры Мулла Хозятаз белән бергә Иске Казанга нигез салучы дип атала. Аерым легендаларда да монда беренче хан буларак Алтынбик күрсәтелә, аның 14 яшендә тәхеткә «борынгы йола» буенча күтәрелүе турында әйтелә һәм кайбер очракларда Габдулла ханнан соң хан булган Алтынбик исеме артыннан бу биләмәдә хан булган Олуг-Мөхәммәд исеме атала, шулай итеп, мондагы ханнар исемлегеннән Галим бәк төшерелеп калдырыла. Шулай ук, Галим бәкнең Иске Казанда Алтынбиктән соң хөкем иткәнлеге әйтелсә дә, ул аерым чыганакларда хан дип аталмый һәм Алтынбиккә «береккән» килеш кенә күрсәтелә.

Алай гына да түгел, инде югарыда әйтелгәнчә, аның «Казанны яратмыйча» Тубыл Турага (Иске Тубыл Турага, ягъни, ахрысы Себер ханлыгының башкаласы Искергә) китеп барганлыгы турында әйтелә. Бу мәгълүмат реаль тарихка бик үк туры килмәсә дә, аның артында яшерелгән нindидер информация бар, дип уйларга урын бар.

4) Габдулла ханның ике «улы» – Алтынбик һәм Галим бәк төньякка күчерелгәндә алар әле яшь булганнар – беренчесенә – 9, икенчесенә – 7 яшь кенә (кайбер очракларда аларның яшьләре киресенчә куела). Бу күрсәтмәләр тарихи әһәмияткә ия, чөнки аларга таянып Иске һәм Яңа Казан белән бәйле кайбер даталарны чамаларга була.

5) Татар чыганакларында Габдулла ханның варисларын Кырым белән бәйләргә тырышу күзәтелә. Мәсәлән, «Фи бейан-и тарих» («Ферхенг-намә» әсәренең варианты) Алтынбик һәм Галим бәк «оругларының» Кырымда да барлыгы турында әйтә, ә Иске Казаннан Яңа Казанга күчүне оештыручы да (ул гадәттә Галим / Гали бәк белән бәйләнелә) бер легенда эчендә «Кырым ханы» дип атала. Ләкин башка очракта ул шәхес Алтынбик булып та бара.

6) Болгар вилайәтенең элекке сәяси үзәгенең Иске Казанга (Болгар әл-җәдиткә) күчерелүе дәверендә инде аерым бер Казан биләмәсенә (йортына) әверелгән дәүләткә – башта бәйлеккә (кенәзлеккә), аннан ханлыкка, Болгар шәһәре үзе һәм аның тирә-юньнәре дә кергән, дип уйларга урын бар. Бу турыда Иске Казанда «йорт тоткан» Алтынбикнең Болгар шәһәрендәге «Хәлиф җәмигы» дип исемләнгән мәчет янындагы «олы мәдрәсәне» төзәттерүе, ә Галим (Гали) бәкнең Болгарга атасы каберенә зиярәт кылуы турындагы легендар мәгълүматлар сөйлиләр. Шулай ук, «Янмый торган кыз» дастанында Габдулла ханның кече улы Шеуне бәкнең Иске Казаннан Болгарга килеп анда «хан» булып утыруы да шуны ук раслый.

Менә хәзер инде барлык чыганаклардан җыелган информациянең «ядрә» өлеше тупланып бетерелгәнлектән, аларны башка язма чыганакларда саклanган тарихи мәгълүматлар белән чагыштырып карарга мөмкинлек туа. Шулвакытта без Болгар / Казан вилайәтенең XIV–XV-нче йөз араларындагы тарихының моңарчы өйрәнелеп бетмәгән якларын ачыклый алачакбыз.

Фикерләүне дәвам итү өчен безгә Габдулла ханга караган каршылыклардан арынуны тәэмин итәрлек гипотеза кирәк: ничек итеп бер дәвердә – 1361/62–1369/70-нче елларда, Мамай Урдасында хан булып утырган Абдаллах (Габдулла), шактый озак вакыт үткәннән соң – 1390-нчы елларда, Болгар вилайәтендә хан тәхетен били? Бу мәсьәләне чишкәндә ул шәхеснең дастан буенча Түләкнең улы булуын да әйләнеп үтеп булмый. Ягъни, югарыда бирелгән сорауларга хәзер комплекслы җавап табу кирәк.

Безнең төп гипотезабыз мондый: Абдаллах (Габдулла) Мамай Урдасында хан булып утырса да, нәселе буенча Чыңгызый түгел, ә атасы төсле үк кыйат кабиләсеннән чыккан бәкләр нәселе вәкиле. Дөрес, бәлки анасы, яисә әбисе ягыннан ул Чыңгызыйлардан булган бегим (хан кызы, яки ханнарның башка кыз туганнары) дип йөртелгән зат нәселеннәндер (югарыда күрсәтелгән «шаһзадә»). Түләкнең дә, Габдулланың (Абдаллахның) да тәхеткә күтәрелүе гадәттән тыш шартларда – Мамай контроле астындагы Урдада Чыңгызыйларга бик нык кытлык килеп туганда башкарылган эш, дип уйларга мөмкинбез. Алай гына да түгел, Мамай Урдасының сәяси үзәге бәлки Кырымда түгел, ә Сарай шәһәрендә һәм ул Мамай бәк кулыннан киткәндә, Болгар шәһәрендә урнашкан булырга мөмкин. Ахрысы, Мамай үзенең көндәше Туктамыш хан тарафыннан тар-мар ителгән һәм үтерелгән вакытларга (1380-нче ел) кадәр дә, аннан соң да Габдулла Болгар вилайәте башында калуын дәвам иткән – хан булыпмы, «Болгар кнәзе» буларакмы – монысы билгесез, хәлбуки, ул биләмәнең Мамайдан соң Туктамыш ханга буйсынганлыгы билгеле (карагыз: [Исхаков: 2013-б]). Әмма, шуны истә тотарга кирәк: бу дәвердә башка Алтын Урда төбәкләрендә дә сепаратизм күзәтелгән һәм кайбер җирләрдә яңа ханнар тәхеткә күтәрелгәннәр. Мәсәлән, 1386-нчы елны Бек-Булат оглан Кырымда хан итеп игълан ителә һәм Туктамыш белән вакытлыча килешүгә килсә дә, ниндидер билгесез статуста Дон буйларына кадәрге җирләр белән 1392-нче елга кадәр идарә итә [Гулевич: 2018. С. 78–79]. Ягъни, гомуми ситуациядә Болгар вилайәтендә аерым хөкемдар булып утырган Габдулла уникаль булып күренми.

Шулай да югарыда китерелгән гипотезаның бер йомшак ягы бар: бүгенгә инде билгеле булган тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Алтынбәк (Алтынай) солтан – Шибанидлар нәселеннән, ә Али / Гали / Галим-бәк, «Казан бәге / кенәзе», кыйат кабиләсе бәкләре нәселеннән булып күренәләр. Бу ике шәхес тә бер үк атадан – Габдулла ханнан туган булырга мөмкиннәрме? Әгәр дә Габдулла һәм аның атасы Түләк берникадәр вакыт (Түләк турында, мәсәлән, дастанда 3 елдан алып 36 елга кадәр хөкем иткән, дип әйтелә) тәхет биләгәннәр икән, Габдулланың уллары саналган (барлык очракларда да түгел) Алтынбәк һәм Галим (Али / Гали) бәк (бий) икесе дә Казан (Болгар) вилайәтендә бергә хөкем иткән (русча – «соправительство») булырга мөмкиннәр. Әмма язма чыганаклар Казанны Олуг-Мөхәммәднең бер очракта «Алтынай солтаннан» (Үтәмеш-хаҗи), икенче очракта «Албай [һәм] Алтунбайдан» (Кырыми) алуы турында сөйләгәндә бу хәбәр бик аңлашылып бетми, кем монда чынлап та хөкемдар булган соң? Ә менә рус чыганаклары, мәсәлән, Воскресенск елъязмасы, 1445-нче елны Олуг-Мөхәммәднең

улы Мәхмүтәк (Мәхмүд) тарафыннан үтерелгән «Казан вотчичы»ның исемен «Либей» дип атый [ПСРЛ: 1859. Т. 8. С. 114]. Бу фәкать тик Гали / Али бәй генә булырга мөмкин. Никон елъязмасындагы шул ук вакыйга уңаеннан аталган исем – «Азы / Азый» [ПСРЛ: 1965. Т. 11–12. С. 251], чынлыкта исем түгел, ә кушамат, яки титул – «гази» (изге сугыш алып баручы) [Исхаков: 2013. С. 20], ул исә, башка вакыйгалардан күренгәнчә, элегрәк сугыш эшләрендә катнашкан Гали бәйгә күбрәк карый булса кирәк. Димәк, язма чыганаклар арасындагы каршылыкларны әлегә бөтенләй үк бетереп булмый һәм без Казан / Болгар вилайәтенә Олуг-Мөхәммәд җитәкчелегендәге төркем килеп урнашканчы анда төгәл генә кем хөкем иткәнен әйтә алмыйбыз.

Шулай булуга да карамастан, тупланган мәгълүматлардан чыгып эш итсәк, Алтынбик (Алтынай) һәм Али / Галим бәк яшәгән хронологик даталарга бәйле вакытларны бераз төгәлрәк чагылдырырга мөмкинлек бар. Әйтик, әгәр дә Болгар вилайәтенең сәяси үзәге булган Болгар шәһәреннән Иске Казанга күчү 1395/1396-нчы елның кышында башланган булса – нәкъ шул вакытларда Тимур гаскәрләре Хаҗи-Тархан һәм Сарай (Сарай-Берке) шәһәрләрен алалар һәм җимерәләр, ә Тукгамыш хан, кайбер мәгълүматларга караганда, Болгар тарафына чигенә – ул вакытта Алтынбиккә 9 яшь тулганлыгыннан чыгып карасак, аның Иске Казанда 14 яшендә тәхеткә утыртылуы 1400/1401-нче елларга туры килә дип уйлый алабыз (14–9=5; 1395/1396+5=1400/1401). Кызыгы шунда – бу даталарга якын елларда – 1398/1399-нчы елны, Казан (Иске Казан) рус елъязмаларында Болгар вилайәтендәге 4 шәһәрнең берсе буларак атала (калганнары: Болгар, Кирмәнчек, Җүкәтау) [ПСРЛ: 1965. Т. 11–12. С. 126–127]. Инде 1400/1401-нче еллардан ук Болгар вилайәтенең хөкемдары Казанда (Иске Казанда) утырса да, әле 1410/1411-нче елны да ул хөкемдар рус елъязмаларында «Болгар кнәзе / князь Болгарский» дип атала [Исхаков: 2013-б]. Монда сәбәп бер генә: баштагы дәвердә Иске Казанның исеме «Болгар әл-җәдит» / «Яңа Болгар» булган, шунлыктан, анда хөкем итүче «Болгар бәге / әмире» исемен йөрткән.

Күрсәтеп үтелгәнчә, 1410/1411-нче елларга Иске Казандагы төп хөкемдар (тәхет биләүче) Алтынбик (Алтынай) булган булырга тиеш. Дөрес, бу бер фараз гына, чөнки 1400/1401–1410/1411-нче еллар арасында Болгар / Казан вилайәтендә нәрсә булганын без төгәл генә белмибез. Әмма, 1445-нче елны аның Али бәй исемле «вотчичы» Казанда үтерелгән икән, ул үзе дә, Алтынбик (Алтынай) та шул килеш бу biләмәдә хөкем иткәннәрдер, дип уйларга урын бар (хәлбуки, Алтынбик (Алтынай) буенча бераз шөбһәләр калса да). Ләкин, тикшерелә торган мәсьәләгә авырлык өстәүче фактлар да бар – Болгар / Казан вилайәтендә

1398/1399–1429-нчы еллар арасында башка «царевич» (димәк, солтан) дип исемләнгән шәхесләр дә искә алыналар (1398/1399-нчы елны – Ентяк, 1410/1411-нче елны – Талыч, 1429-нчы елны – Мәхмүд-хуҗа) (тулырак карагыз: [Шунда ук. С. 27]). Шуның өстенә, тарихи чыганакларда бу биләмәнең 1428/1429-нчы елны «Күчмә үзбәкләр дәүләте» ханы Шибанид Абул-Хайрга буйсынганлыгы турындагы мәгълүматлар да бар [Шунда ук]. Ягъни, 1420-нче еллар ахрына Болгар / Казан вилайәте бөтенләй үк бәйсез була алмаган, димәк аның хөкемдары да суверен булмыйча, бәлки «Болгар әмире / Болгар кенәзе» буларак кына җирле тәхеттә утыргандыр, дигән фикер дә килә башка.

Тагы бер уйландыра торган як: 1398/1399-нчы елгы рус елъязмаларындагы хәбәрдә Болгар / Казан биләмәсендә нәкъ 4 шәһәр булуы. Бу ни өчен әһәмиятле? Менә ни өчен: бераз соңрак чорга (1410/1411-нче елларга) караган рус елъязмаларындагы хәбәрдә «Болгарьские князи, и Жукотинские» дигән сүзләр барлыгы билгеле [Исхаков: 2009-а. С. 126]. Әгәр дә һәрбер Болгар / Казан вилайәтендәге шәһәрдә аерым нәсел тәшкил иткән бәкләр утырсалар – ә бу алдагы информациядән чыгып фикер йөрткәндә мөмкин булып күренә – без Габдулла хан заманыннан билгеле 4 «шаһзадәләрнең» нәселләренә тап булмыйбызмы? Алар исә элегрәк әйтелгән безгә таныш булган 4 карачы бәкләр системасын чагылдырырга мөмкиннәр. Күрсәтелгәнчә, бу дүртнең берсе өлкән (*олы / улу бий*) карачы бәк булып, Алтынбик (Алтынай), яисә Гали (Галим) бәк нәселенә туры килә ала һәм сүз ул очракта кыйат кабиләсе бәкләре турында бара дип уйлыйбыз. Әгәр дә Алтынбик (Алтынай солтан) чын Чыңгызый булып, тәхеткә утыртылган булса, аның белән бергә хөкем итүче («соправитель») Гали (Галим) бәк биләмәдә булган өлкән бәк функциясен башкарган булып чыга. Ул вакытта Казан (Болгар) вилайәтенең «вотчичы» да ул үзе дигән сүз.

Әгәр дә төптән уйлап карасаң, Болгар вилайәтендәге 4 карачы бәкләрдән торган структура ул аерым ханлык булдыру өчен әзер сәяси нигез. Шуңа күрә дә Олуг-Мөхәммәднең улы Мәхмүтәк мондагы олы бәйне үтереп, шул структура нигезендә бу биләмәдә бик тиз мөстәкыйль ханлык оештыра алган. Әмма, безгә билгесез калганы шул – ул элекке кабиләләрне кулланганмы, әллә аларны үзе белән килүче дүрт башка (шырын, барын, аргын, кыпчак) кабиләләр белән алыштырганмы? Әгәр дә легендар информациядәге Галим бәкнең «Иске Тубыл Турага» китүен истә тотсак (хәлбуки, ул үтерелгән булырга да мөмкин), бәлки иске кабиләләрне Олуг-Мөхәммәд белән килүчеләр тулысынча алыштырганнардыр. Ләкин яңа чыганаклардан башка бу табышмакны чишү әлегә мөмкин түгел.

Берничә сүз «Иске Казаннан» хәзерге, «Яңа Казанга» күченү турында да әйтү кирәк, чөнки ул вакыйга Габдулла ханның «уллары» (яисә, бер

улы) дәверендә булган, дип уйларга урын бар. Кызганыч, язма чыганакларда бу турыда бер ышанычлы мәгълүмат та юк, шуңа күрә ул мәсьәләне тикшергәндә риваять / легендаларга таянырга туры килә.

Югарыда китерелгән чыганаклардан «Фи бейан-и тарих» («Ференг-намә» әсәренең варианты) дип исемләнгән чыганак Алтынбикне 14 яшендә «Казан дәрйәсе өстендәге кальгада», ягъни, Иске Казанда, тәхеткә утыртуларын сөйләгәч, анда башта Алтынбик белән Галим бикнең бергә «йорт тотканлыклары» турында әйтелә дә, аннан соң Галим бәкнең Иске Тубыл Турага китүе турында хәбәр ителә. Шуннан соң язмада мондый юллар бар: «Йәнә Алтын бик Яңа Казанга килептер». Тикшерелә торган чыганакта кайбер даталар да бар: Иске Казанда тору анда 104 ел дип билгеләнә, ә Яңа Казанда («Казан сувы тамагындагы шәһәрдә») тору 158 ел булганлыгы күрсәтелә. Шушы ук даталар «Дәфтәре Чыңгыз-намә» эчендәге «Фасыл фи дастан фит-тарих» исемле бүлектә дә бар һәм анда да «Казан елгасы өстендәге» каладан «Казан суының тамагына», ягъни Яңа Казанга килеп шәһәр төзү, элекке урында 104 ел торгач булган, итеп күрсәтелә. Ләкин ул вакыйганың нинди хөкемдар заманында булганлыгы ачыкланмый. Бу даталарга без әле әйләнеп кайтырбыз (хәлбуки, алар инде моңарчы да тикшерелделәр [Фахрутдинов: 1984. С. 153–166]), хәзергә Яңа Казанга күченүнең («килүнең») бу очракта Алтынбик белән бәйләнгәнлегенә игътибар итик. Ләкин, татар риваятьләрендә монда күченүне «хан Гали би / Галимбик» тарафыннан оештырылуы да күрсәтелә [Татар халык иҗаты: 1987. 50–53 бб.]. Кайбер очракта легендаларда аның исеме «Гомәр хан» яки исемсез «Кырым ханы», дип тә бирелә [Шунда ук: 48–49, 54 бб.]. Димәк, риваять / легендалардан һәм алар белән нык бәйле язма чыганаклардан тикшерелә торган мәсьәлә буенча төгәл генә нәтиҗә чыгарып булмый. Шуңа күрә дә кайбер башка мәгълүматларга да таянып эш итү кирәк.

Әйтик, тарихчы Х. Әмирханов үзенең «Тәварих-е Булгарийа» исемле хезмәтендә Яңа Казанның 1418-нче елны барлыкка килүе турында яза [Амирханов: 2010. 81 б.]. Кайсы чыганактан алган соң ул бу датаны? Бусы билгесез, әмма аның бу датаны санап чыгару методикасын ачып була. Х. Әмирханов фикере буенча, Иске Казанны нигезләүгә 558 ел [Амирханов: 2010. 81 б.] булып, ул бу турыда кулъязмасын бетерү датасыннан (1872-нче елны) чыгып язган [Исхаков: 2013-б. С. 60]. Димәк, сүз 1314-нче ел турында бара. Әгәр дә шушы датага Иске Казанның 104 ел яшәгәнлеге турындагы санны кушсак (1314+104=1418), безне кызыксындырган Яңа Казанга күчү датасы килеп чыга ала. Ләкин бу бердәнбер дата түгел. Әйтик, И.Ф. Яковкин кулындагы кулъязмада хәзерге Казанга нигез салу хиҗри белән 804-нче елны булган дип язылган

була, ә бу грегориан календаре буенча 1401/1402-нче елларга туры килә. Игътибар итик – китерелгән дата Алтынбикнең 14 яшендә Иске Казанда тәхеткә утыртылуы вакытына туры килә, шулай булгач, аның бәлки башка мәгънәсе булгандыр. Г. Рәхим бастырган татар елъязмаларында исә Иске Казаннан «Казан елгасы тамагына», ягъни Яңа Казанга, килеп урнашуның Казан шәһәрендә Шаһали хөкем итә башлаганлыгына кадәр 108 ел элек булганлыгы күрсәтелә [Рахим: 2004. С. 141, 182]. Әгәр дә бу шәхеснең беренче тапкыр Казан ханлыгы тәхетенә 1519-нчы елны утырганлыгын истә тотсак, сүз 1410/1411-нче еллар турында барырга мөмкин. Бу даталар да, югарыда әйтелгәнчә, ниндидер әһәмияткә ия булганнар. Әмма, ахыр чиктә без Казан / Болгар вилайәтенең сәяси үзәге күчерелүнең ким дигәндә ике датасын – 1410/1411 һәм 1418-нче елларны, күрәбез (1401/1402-нче елны, уйлавыбызча, төшереп калдырырга була). Нәтиҗәдә, сәяси үзәкнең Иске Казаннан Яңа Казанга күчерүен Алтынбик һәм Гали (Галим) бәк фигуралары белән бәйле рәвештә карау кирәк булып чыга – татарлар арасында сакланган легендар информация дә нәкъ шул турыда сөйли.

Бәлки, күчешнең ике төрле датасы (1410/1411 һәм 1418-нче еллар) булуының башка бер сәбәбе дә бардыр. Ул уңайдан менә нәрсәгә игътибар итәргә кирәк: аерым татар риваятьләрендә (мәсәлән, «Елан тавы» исемле легендада) Иске Казаннан күченүнең башта «Елантау» дигән урынга булганлыгы турында сөйләнә [Татар халык иҗаты: 1987. 50 б.]. Шул ук урын башка легендаларда да искә алына [Шунда ук: 50–55 бб.]. Әгәр дә бу хәбәр дөрес булса, Яңа Казан башта икенче урында урнашкан булып чыга. Шуның өстенә, «Казанская история» дип билгеле булган чыганакка күз салырга кирәк. Анда исә Олуг-Мөхәммәднең бу якларга килүе турында сөйләнгәндә, ханның 40 ел «буш торган» («стояще пусте») «Казань Саинов юрт» дигән урынга килеп, башта шунда төпләнеп, 7 ел буена шул җирдә ханлык итүе турында әйтелә (хронология буенча, ул бу җиргә 1438-нче елны ук (1445–7=1438) килгән булып чыга). Ләкин иң әһәмиятлесе бу очракта менә нинди хәбәр: Олуг-Мөхәммәд «...постави себе деревянный град крепок на новом месте, крепчаише старого, недалече от старыя Казани, разоренныя от русские рати» [Казанская история: 1954. С. 49, 53]. Чыганактагы эчке хәбәрләрдән күренгәнчә, «Старая Казань» / «Иске Казан» дип аталган шәһәр 1398/1399-нчы елгы рус гаскәрләре походы вакытында таланган була [Исхаков: 2013-б. С. 15–17], әмма, бөтенләй үк буш булмый. Бәлки, Олуг Мөхәммәт шушы Иске Казаннан ерак булмаган бер урында (Камай шәһәрлегендә?) яшәп торгандыр. Ә Иске Казанның төп халкы бу вакытларга инде Яңа Казан булачак җирләргә күчкән булганнардыр (башта Җылан / Елантау тирәсенә). Ахрысы, нәкъ менә шул

шәһәрне Мәхмүтәк Гали бәк (Галим би) кулыннан «хәйлә белән» алып, аның үзен үтерә.

Шул вакыйгадан соң гына Болгар / Казан вилайәтендә элеккедән килгән хөкем итүчеләрнең нәсел җепләре өзелә һәм Казан ханлыгына әйләнгән дәүләттә Туктамыш ханның туганы Олуг-Мөхәммәднең улы Мәхмүтәк хан җитәкчелегендәге (рус елъязмалары аны юкка гына «вольный царь» – суверен хөкемдар, дип атамаганнар) яңа бер Алтын Урда татарлары төркеме кереп урнашкан ханлык барлыкка килә. Шулай итеп, Түләк б. Габдулла ханның «алтын тәхете» аның варислары өчен юкка чыга, һәм «Түләк һәм Сусылу» дастаны геройларының заманы үтә, яңа, аерым татар ханлыклары дәвере башлана.

Ул эпоханың кайбер геройлары белән без әле «Чура батыр» дастанын тикшергәндә очрашырбыз.

## III-нче бүлек

## «Идегәй» дастанының серләре




*Edigu.* Алибек Койлакаев.

## § 1. Дастанга кереш

«Идегәй» дастаны бик билгеле, күп төрки халыкларда (алтайлыларда, башкортларда, казакъларда, каракалпакларда, нугайларда, төркмәннәрдә, үзбәкләрдә һәм төрле төркем – Себер, Кырым, Идел-Урал буе татарларында) киң таралган эпик әсәр. «Идегәй» дастаны яхшы өйрәнелгән эпик әсәрләр рәтенә кертелә ала [Татар халык дастаны: 1940; Жирмунский: 1974; Сикалиев: 1994; Урманче: 1999; Эдигэ: 2016; Исхаков: 2018; 2019; Мөхәмәтҗанова: 2019]. Кайбер хезмәтләрдә, мәсәлән, В.М. Жирмунский монографиясендә, бу дастанның тарихи җирлегенә зур игътибар бирелсә дә, «Идегәй» эпосының төрле сюжетларында күренгән аерым фактларга, вакыйгалардагы тасвирлауларга әле тарихи яктан аңлатмалар бирелмәде, шулай ук әсәрдәге күп кенә шәхесләрнең кемлеге мәсьәләсе дә тикшерелмәгән, шунлыктан дастанның тарихи нигезләрен ачып салу әле күп көч таләп итә. Гомүмән, бу эпос күбрәк фольклор әсәре буларак кына өйрәнелгән килеш кала.

Аның төрле милли версияләре күләме һәм эчтәлеге ягыннан да бер-берсеннән аерыла. Аларның һәрберсендә үзенә генә хас үзенчәлекләр сакланган, алар артында исә еш кына билгеле тарихи вакыйгалар һәм конкрет җирлек тора, ләкин ул җирлек белән бәйле вакыйгалар агымы теге яки бу дәрәҗәдә төгәллеге һәм аерым тарихи мәсьәләләрне чагылдыру ягыннан бертөрле генә бармаска мөмкин. Нәкъ менә шушы милли үзенчәлекләр аркылы ул дастан эчендә сакланган төбәк тарихына бәйләнгән вакыйгаларны һәм сюжетларны барларга мөмкин дә. Билгеле, аннан башка ул эпик әсәрдә гомуми, барлык милли версияләр өчен дә уртак булган яклар да бар. Моның төп сәбәбе – дастанның бөтен вариантларында да үзәктә бер үк шәхеснең – Идегәйнең торуы (хәлбуки, кайбер очракларда, мәсәлән, башкортларда, эпик әсәрнең төп герое булып Идегәй түгел, ә аның улы Нуретдин-Морадым тора).

Аңлашыладыр, безне беренче чиратта бу дастанның татарлар арасында таралган версияләре кызыксындырачак, чөнки алар Кырым-Идел-Урал-Себер яклары, ягъни, татарлар халык булып формалашкан төбәкләрнең тарихы белән бәйләнгәннәр. Әмма, ул версияләрдә чагылган кайбер гомуми тарихи информация дә безнең игътибардан читтә калырга тиеш түгел, чөнки алардагы мәгълүматлар урта гасыр татар тарихын тулаем күзаллау өчен бик әһәмиятле, эпоста бит төп вакыйгалар гаять киң яссылыкта яшәгән Алтын Урда эчендә баралар. Дөресрәге, шушы дәүләтнең таркала башлау дәвере тарихын чагылдыралар. Юкка гына дастанның татар версиясе мондый юллар белән тәмамланмый:

*Идел-йортны дау алды,*
*Яу өстенә яу килде,*
*Идегәй әйткән көн килде.*
*Чыңгызның куйган хан тагы*
*Кан тагы булып әверелде;*
*Хан сарае камалды.*
*Кырым, Казан, Аҗдаркан*
*Башлы-башлы ил булды,*
*Алтын Урда таралды.*

Язмабызга кереш буларак тагы ике мәсьәләгә кыскача гына булса да тукталып китү кирәк. Беренче мәсьәлә – эпосның төп герое булган Идегәй шәхесе турында.

Билгеле булганча, Идегәй – тарихи шәхес һәм аның үлгән елы да билгеле – 1419-нчы ел. Аның туган елы турында төгәл мәгълүмат юк, 1359-нчы ел булса кирәк. Чыганакларда ул беренче мәртәбә 1376-нчы елда искә алына. Моңа кадәр Күк Урда ханы Урус (ул Алтын Урданың сул канаты ханы булган) янында хезмәт иткән Идегәй, ниндидер сәбәп аркасында, аның белән конфликтка кереп, Тимур (Аксак-Тимер) белән союзда Алтын Урда тәхете өчен көрәшкән Туктамыш ханга хезмәткә күчә. Кабиләсе буенча ул мангыт (төгәлрәге – ак мангыт) кабиләсе вәкиле булган [Трепавлов: 2001. С. 62–64]. Идегәйнең тарала башлаган Алтын Урда дәүләтенең социаль-политик структурасындагы урынын кайбер тарихи чыганаклар бик төгәл билгелиләр. Мәсәлән, гарәп елъязмачысы ад-Дзехабиның (1348/1349-нчы елны үлгән) дәвамчысы булган бер билгесез елъязмачы Идегәйнең үлеме турындагы хәбәрдә, әйтә: «...Сарай һәм Дәште-Кыпчак белән идарә иткән бөек әмир Идики вафат булды...; ул икенче әмир генә иде, чөнки аннан башка Тегинэ исемле тагы бер әмир бар иде. Анда [ягъни, Алтын Урдада – Д. И.] өлкән әмирләр уң канат һәм сул канат әмирләре булалар. Уң канат әмире урынын Тегинэ алып тора. Сул канат әмире урынында Идегәй утыра иде...» [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. I. С. 244]. Димәк, Идегәй Алтын Урдада сул канатта булган кабиләләр һәм җирләр белән идарә иткән. Аның сәяси статусы – бәкләр бәге (гарәпчә – әмир – әл-умара, русча – князь, князей). Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, аның атасы да (Балтычак / Балынчак бәк) сул канат ханы Тимур-Мәлик б. Уруста шул ук статуста булган [Трепавлов: 2001. С. 63]. Ә бу исә Идегәйнең затлы татарлар нәселеннән булуы турында сөйли. Дастан вариантларында Идегәйнең атасы булып саналган тагын бер шәхес – Котлыкыя би (аның турында карагыз: [Шунда ук. С. 64]). Безнең фикер буенча, бу исем

Идегәйнең нәсел шәҗәрәсенә хатын-кызлар ягыннан кергән. Аның турында эпоста Туктамыш хан тарафыннан әйтелә:

*Һай син татар, һай татар,*
*Мангыттан азган чал татар, – дип* [Идегәй: 1988. 21 б.].

Тулаем алганда, Идегәйнең Чыңгыз хан дәверендә ук билгеле булган мангыт кабиләсенең бәкләре нәселеннән булганлыгы бәхәссез. Дөрес, бу кабиләнең борынгы чорының тарихында әле бүген дә ачылмаган ак таплар кала бирә һәм шуларның берсе – ул кабиләнең чын монгол кабиләсе булуында шөбһә. Чынлап та, әйтелгән кабиләнең исеменең бер варианты – мең (меңнәр / мәңг) булып, ул исем Җучиның 1207-нче елны Алтайны Еке Монгол олысына кушып йөргән чорындагы бер төрки кабилә исеменә якын. Сүз Алтайда яшәгән мингат (монда этнонимның тамыры– минг / мең, ә ат / ут – монгол телендә күпчелекне белдерүче формант) кабиләсе турында бара (карагыз: [История и культура татар Западной Сибири: 2015. С. 125]).

Икенче мәсьәлә – татарларда табылган «Идегәй» дастанының вариантлары һәм аның җыелма әсәр буларак бастырылып чыгарылган милли версиясе турында. Бүгенге көнгә татарлар арасында табылган шушы дастанның 20-гә якын варианты билгеле [Надиров: 1988. 6 б.]. Аннан башка, ул эпосның Себердә фольклорчы Н. Хәмит язып алган һәм эшкәрткән [Татар эпосы: 2004. 334–337 бб.], соңыннан басылган тексты, Н. Исәнбәт Урал буйларында табып алган һәм шулай ук ул эшкәртеп нәшер иткән [Татар халык дастаны: 1940] версиясе, соңгы дәвердә шул ук нигездә басылып чыккан «классик» дип исемләнергә хаклы дастанның тагын бер варианты бар [Идегәй: 1988]. Әмма, барлык бу очракларда да, җыйнама текстны төзегәндә ул эшне башкаручыларның текстка үз якларыннан керткән «өстәмәләр» һәм «төзәтүләр» мәсьәләсе кала. Ул турыда үз вакытында бик йомшак кына итеп Н. Исәнбәт болай дип әйткән: «...сәнгать реставраторлыгы булу ягыннан», бу җыйнама текстны басмага әзерләү эше «беркадәр иҗади эш итеп каралырга тиеш» (бу турыда тулырак карагыз: [Мөхәммәтҗанова: 2019]). Менә шушы «реставратор» үзлегеннән керткән өлешне без әле төп аутентик өлештән аерып алу мөмкинлекләреннән ерак торабыз. Сәбәбе бик гади: халыктан язып алынган төрле версияләр бергә җыйналып басылмаган килеш кала бирә. Бу шартларда безгә басылып чыккан вариантлар белән эш итәргә туры киләчәк. Алдан ук кисәтәбез – югарыда күрсәтелгән сәбәптән ул басылган текстларга бераз саграк карарга кирәк. Дөресен генә әйткәндә, «Идегәй» эпосының барлык милли версияләрен чагыштырып өйрәнгәндә генә – ә мондый фәнни хезмәт дөньяда әлегә юк – төп, аутентик

булган эпос эчтәлегенең, ягъни аның инвариант өлешен, чамалап булыр иде. Ләкин, әйтелгәнчә, төрки халыклар фольклорын өйрәнүче фәннең мондый дәрәҗәгә әле күтәрелгәне юк. Шуңа күрә, безнең түбәндә китерелүче тарихи күзәтүләребез берникадәр чикләнгән дип каралырга тиешләр. «Идегәй» дастаны күпкырлы эчтәлекле һәм бик четерекле заманны чагылдырган әсәр булганлыктан, бу язмаларыбызда без аның барлык ачылмаган якларын да анализлый алмабыз, андагы кайбер тарихи яктан әһәмиятле сюжетларын тикшереп, барлап чыксак та, безнең бурыч үтәлгән булыр, дип уйлыйбыз.

«Идегәй» дастанының төп сюжетына килсәк, ул түбәндәгечә. Алтын Урда (эпос буенча башка атамасы – «Ак Урда») дәүләтендә, «татардан туган Нугай илендә», хан булып утырган Туктамыш һәм «аягы чонтык» (аксак) Сәмәркандта хөкем иткән «әмир Бырлас» Шаһ Тимер (ягъни, барлас кабиләсенең башы булган Аксак Тимер) арасында конфликт килеп чыга. Аның нигезе – ханның ау кошларын караучы Котлыкыя бинең (дастанда – Идегәйнең атасының) хөкемдарыннан яшерен рәвештә атаклы ау кошы – «кара лачын Төкле Аякның» йомыркаларын Аксак Тимергә озатуында. Бу хыянәт ачылгач, Туктамыш Котлыкыя бине үлемгә хөкем итә, шулвакытта хан якыннарыннан булган Җантимер би, улларының берсен корбан итеп, дусты Котлыкыя бинең бишектәге улын коткарып кала һәм Идегәйне үз балалары белән бергә тәрбияли башлый. Башка исем астында үсеп җиткән Идегәй Туктамыш ханга хезмәт итә, ләкин ахыр чиктә аларның аралары бозылып, Идегәйнең дә кем баласы икәнлеге ачылгач, ул Шаһ Тимер (Аксак Тимер) янына кача һәм юлда аның кызын коткарып, бу әмиргә хезмәт итә башлый. Шулвакытта Идегәйнең ватанында калган улы Норадын (Нур-ад-Дин) атасы янына бара, алар аннан соң Туктамыш хан өстенә гаскәр белән киләләр, Шаһ Тимер дә аларга кушыла. Сарайны алгач, Идегәйнең улы Норадын качып киткән Туктамыш ханны эзәрлекләп барып, аны үтерә. Аннан соң Идегәй белән Норадынның аралары бозыла, улы атасыннан аерыла, бер дәвердән кире кайтып, хан булырга уйлый, ләкин моңа рөхсәт ала алмый. Ахыр чиктә, ул атасын йорттан куалый, моннан файдаланып Норадынны Җанбай би Туктамышның улы Кадыйрбирде солтанга тотып бирә, ә аннан соң Идегәйгә бу турыда хәбәр җибәрелә. Шуннан соң башта Норадын үтерелә, аннан соң Кадыйрбирде белән Идегәй арасында сугыш булып, җиңелгән һәм яраланган Идегәйне качып барганда Кадыйрбирденең биләре тотып алып, үтерәләр.

Чынлыкта, поэтик формада булса да, тикшерелә торган дастанда Аксак Тимер дәүләте белән Алтын Урда арасында булган зур сугышлар һәм

ул заманнардан соңгы вакыйгалар тасвирлана. Ул тасвирлауда күренгән һәрбер вакыйга, аерым элементлар, сюжетлар – барысы да әһәмиятле һәм эчтәлекле. Моны аңлау өчен аларны берәм-берәм өйрәнергә, ул дәвердәге тарих агымының нечкәлекләрен күрсәтеп, төп вакыйгаларның эчтәлеген ачып сала белергә кирәк.

**§ 2. Нәрсә ул, «ал тәхет»?**

Тикшерелә торган дастанда берничә урында хан утыра торган «ал тәхет» искә алына. Әйтик, эпосның сюжет җепләре әле башланган урыннарда ук Алтын Урда ханы булган (1380–1397/98) Туктамыш турында мондый юллар китерелә:

*...Туктамыш хан килгәндә*
*Ал тәхеткә менгәндә,*
*Ал тәхетнең аркасы –*
*Алтын егач тутый кош*
*Сайрап телгә килгәндә* [Идегәй: 1988. 39 б].

Дастан текстыннан күренгәнчә, бу тәхет «хан сараенда» торган тәхет булган. Алга таба, шул ук тәхет Аксак Тимер Сарай шәһәрен алуны тасвирлаганда күренә. Төгәлрәге, сүз шушы яулап алучы Сарайда булганда аның янына Идегәйнең Болгардан килүе турында сөйләнгән эпизодта әйтелгән тәхетне искә алу турында бара. Идегәй Аксак-Тимерне сорагач, аның якыннарының берсе Идегәйгә әйтә:

*Шаһ Тимерне сорасаң,*
*Шаһ Тимердәй олы хан*
*Алтын агач тутый кош*
*Ал тәхетне алдырып*
.................................
*Сәмәркандка юнәлде, – дип* [Шунда ук. 170 б.].

Өченче тапкыр шул ук тәхет, инде ул алдарак Сәмәркандка алып кителде, дип күрсәтелсә дә, Сарайда, төгәлрәге, хан сараенда, тагы пәйда була. Бу очракта Идегәйнең улы Нуретдин (Норадын / Ир Норадын / Морадым) Сарайга хан булырга теләп килү белән бәйле рәвештә ул тәхет турында әйтелә:

*Алтын сарай, хансарай,*
*Хан сарае ак ишек,*
*Ир Норадын килгәндә,*
*Ал тәхеткә менгәндә,*
*Ал тәхетнең аркасы –*
*Алтын егач тутый кош*
*Сайрап телгә килгәндә* [Шунда ук. 219 б.].

Соңгы тапкыр ул тәхет Туктамыш ханның улы Кадыйрбирде (ә бу реаль тарихи шәхес) инде үлгән ханның биләренең берсенә – Киң Җанбайга, сорау бирү эпизодында искә алына:

*Туктамышның бие идең,*
*Бүген кемгә би булдың?*
*Алтын ташлы тәхетенә*
*Бүген кем углын мендердең?* [Шунда ук. 280 б].

Күренә ки, без тикшерә торган дастанда Алтын Урда ханнарының сарайларында (хан сарае, алтын сарай) торган аерым бер тәхет искә алына.

Аның эпоста ике төрле билгеләмәсе бар: «ал тәхет» һәм «алтын ташлы тәхет». Мәгънәви яктан бу ике төшенчә чынлыкта бер-берсенә якын, чөнки татар телендә «ал» сүзе төсне генә түгел (игътибар, рус телендәге «алый» сүзе дә шуннан), ә «әйбәт, яхшы, матур, гүзәл» дигәнне дә аңлата (карагыз: «Безнең эшләр ал да гөл»). Шуның өстенә, үз чиратында «алтын» төшенчәсенең туры мәгънәсеннән тыш башка бер мәгънәсе дә бар – ул «яхшы, матур/гүзәл, кыйммәтле»не аңлата ала (мәсәлән: «алтын бала», «алтын кеше», «алтын куллы» һ.б.).

«Идегәй» дастанында «алтын ташлы тәхет» төшенчәсенең дә шундыйрак мәгънәсе бар, дип уйлыйбыз. Шуңа күрә дә, дастандагы «ал тәхетне» без «алтын тәхет» белән бер үк корылма, дип карый алабыз. Аның шулай икәнлеге бу тәхетнең «Алтын сарай» (хансарай) эчендә торуыннан да килеп чыга. Безнең фикеребезчә, «ал тәхет» – ул «алтын тәхет» төшенчәсенең кыскартылган варианты гына. Бу фикерне башкача нигезләргә дә була: әсәрдә күрсәтелгән тәхет «кызыл» (ал) алтын белән капланган булса (русча – «червоное золото»), бу бигрәк тә шулай.

Бу рәвешчә фикер йөртсәк, безнең каршыбызда Алтын Урдада власть символы булган «алтын(ал) тәхет» пәйда була. Димәк, «Идегәй» дастанында сүз «Түләк һәм Сусылу» дастаныннан күренгән шул ук тәхет урыны турында бара. Әмма, соңгы эпоста аның бик кызыклы яңа бер элементы килеп чыга – ул да булса шушы тәхетнең арка ягында кошларча тавыш чыгара ала торган «алтын тутый кош» булуы. Икенчедән, дастанда ул «ал тәхетнең» Сәмәркандка алып кителүе турында әйтелсә дә, аның элекке урынында калуы күренә. Димәк, бу «алтын тәхет» элекке урынына – Сарай шәһәренә «беркетелгән» булган. Аның шулай «беркетелгән» булуы чынлыкта шушы «тәхет урынының» Чыңгызыйлар династиясенә бәйле булуы аркылы гына аңлатыла ала. Чынлап та, тарихи чыганакларда Сарай шәһәренә, ягъни Алтын Урданың сәяси үзәгенә, бәйле рәвештә искә алына торган, русча «Саинов стул» (монда «Саин» – Бату хан дигән-

не аңлата) дип йөртелгән тәхет урыны билгеле. Ул югарыдагы «ал/алтын тәхет» була түгелме?! Ә инде Туктамыш ханның улы Кадыйрбирде, би/бәк булган Киң Җанбайдан (аның кабиләсе – *кенегес*) син ул тәхеткә кемне мендердең соң, дип сораганда, инде без алдагы язмада тикшергән карачы бәкләрнең ханнарны шушы тәхеткә күтәрүләре турында әйтелә. Чынлап та, XIV–XV-нче йөзләрнең чикләрендә Алтын Урдада солдат булып хезмәт иткән баварияле И. Шильтбергер күрсәткәнчә, «Алтын Татариядә» ханны тәхеткә утырту йоласы мондый булган: «... корольне (ханны – Д. И.) ... ак киезгә утыртып өч мәртәбә күтәрәләр. Аннан соң аны палатка тирәли [күтәреп] йөртәләр һәм тәхеткә утырталар, алтын кылыч бирәләр. Шуннан соң ул аларның гадәтләре буенча ант итә» [Шильтбергер: 1984. С. 44].

Нәтиҗә итеп шуны әйтергә кирәк: «Идегәй» дастанын укыганда без «ал тәхет» төшенчәсен күргәч, сүзнең Алтын Урдадагы власть үзәге турында барганлыгын аңларга тиешбез. Димәк, әле дастан формалашкан дәвердә төрки-татарлар арасында бу тарихи символның элекке мәгънәсен аңлау булган.

**§ 3. «Дәүләт кошы» турында**

Бу бүлекнең башына куелган дастандагы «дәүләт кошы» дигән юллар артында нәрсә торганлыгын төшенү өчен безгә «Идегәй» эпосының төп сюжетын искә төшерергә кирәк булыр.

Дастанның башланып китүе Шаһ Тимердән, ягъни, Аксак-Тимердән (эпос аны бик төгәл рәвештә «бырлас [кабиләсенең] әмире» дип билгели), Туктамыш ханга килгән хат белән бәйләнелә. Ул хатта Аксак-Тимер авызыннан чыккан мондый юллар булганлыгы әйтелә:

*Җаектан ашу Ак Түбә,*
*Иделдән ашу Күк Түбә,*
*Күк Түбәдә – ак сарай;*
*Анда утырган Туктамыш –*
*Ул Туктамыш син булсаң,*
*Сине баккан мин булсам,*
*Тугрына кунган Төкле Аяк*
*Тугыз йортка дан булса,*
*Аны миңа тапшыргыл* [Идегәй: 1988. 12 б.].

Дастанга комментарийлар бирүчеләр фикере буенча, «тугры» – кош кундыра торган агач (башка вариантлары – «тур / тургач») [Шунда ук], шуңа күрә «Төкле Аяк» дип исемләнгән җан иясе – ул кош. Менә шул даны бик еракларга таралган кошны таләп итә Аксак-Тимер Туктамыш ханнан. Мондый дорфа хатка җавап биргәндә ачуы чыккан Тук-

тамыш, үзенең Чыңгызхан нәселеннән булуын, ә Шаһ Тимернең әмир генә икәнлеген искә төшереп, хатта әйтә [Шунда ук. 13 б.]:

*Кара лачын Төкле Аяк,*
*Сиңа булмас, Шаһ Тимер, – дип.*

Димәк, дастанда сүз Кара лачын турында бара һәм ул алга таба ау кошлары белән бәйләп карала, ә ул кошларны багучы буларак Котлыкыя би (Идегәйнең дастандагы атасы) атала. Шуннан соң бу Кара лачыннан (= Төкле Аяктан) туган ике кош баласын Туктамыш сынап карарга уйлый һәм шулвакытта аларның даны таралган ау кошыннан тумаган икәнлеген аңлап, Котлыкыяга әйтә [Шунда ук. 17 б.]:

*Ау лачыным караган*
*Котлыкыя син булсаң,*
*Салган ике йомыркасын*
*Оядан алган да син икән! – дип.*

Алай гына да түгел, ул Котлыкыяны шушы лачынның балаларын Аксак-Тимергә бирүдә гаепли, аның алтынга (акчага) сатылып, Шаһ Тимер ягына чыгуы турында әйтә. Хан каршында үзен акларга тырышкан Котлыкыяны әрләгән Туктамыш аңа болай дип белдерә:

*Куш канатлы алтын таҗ,*
*Күз урынында гәүһәр каш,*
*Чыңгыздан килгән дәүләт кош*
*Бу башымда түгелме?* [Шунда ук. 18 б.].

Шулай итеп, Кара лачын токымыннан булган «Төкле Аяк» исемле реаль ау кошы урынына дастанда кинәттән генә ике канатлы (куш канатлы) алтын таҗ пәйда булып (тасвирлауга караганда, аның хәтта гәүһәрдән эшләнгән күзе-кашы да булганлыгы белдерелә), аңа гаять әһәмиятле мәгънә бирелә – хан башындагы шушы таҗ «Чыңгыздан килгән» ниндидер «дәүләт кошы» белән тәңгәлләштерелә.

Без күрсәтелгән кош образын, төгәлрәге – «дәүләт кошы» образын, Чыңгыз ханнан килүче «алтын таҗны» истә калдырыйк та, дастанны алга таба күзәтик, чөнки Туктамыш хан Котлыкыя бидән аның ни өчен сатылганлыгын белергә тели. Җавап итеп, ханга Котлыкыя ике гаеп ташлый: бердән, сәүдә элемтәләре кимеп, бигә байлык килмәү, икенчедән, аның үз илен Идел аркылы ике тапкыр күчереп, уңайсыз җиргә китереп утыртуын. Ахырдан ул әйтә:

*Йорттан йортым күчкәне –*
*Бездән ырыс киткәне,*

*Куштан кошың күчкәне –*
*Сездән дәүләт киткәне* [Шунда ук. 20–21 бб.].

Ягъни, Котлыкая бинең фикеренчә, аның йортының – биләмәсенең, бер җирдән икенче җиргә күчүе, бәхетнең (ырысның) китүенә тәңгәл, ә оядан (куштан) кошның күчерелүе, ханнан дәүләтнең китүенә тигез. Котлыкыя би үзенең хыянәтен таный һәм аннан җәза алырга әзер икәнлеген белдерә [Шунда ук. 21 б.]:

*Бер башымны ике итеп,*
*Ике ханга баш орсам,*
*Ул да булса, ханиям,*
*Йорттан абруй киткәне,*
*Чабучы булсаң, баш – менә!*
*Түгүче булсаң, кан – менә!*

Каршында җәза алырга тезләнгән Котлыкыяга хан әйтә [Шунда ук]:

*Син дә кичә би булдың,*
*Бүген килеп, син дә бер*
*Үлем белән тиң булдың –*
*Токымыңны ораен! – дип.*

Шушы сүзләрдән соң Туктамыш үз биләренә Котлыкыяны һәм аның бөтен токымын юк итәргә боера. Шулай итеп, дастанның баш өлеше тәгәлләнә, алга таба бу өлештә күренгән «Төкле Аяк» исемле кош башка искә алынмый, «дәүләт кошы» кыяфәтле «алтын таҗ» да бүтән дастанда пәйда булмый.

Чынлыкта «Төкле аяк» атамасының мәгънәсе беренче карашка гына «йонлач (төкле=йонлы) аяк» булып күренә ала, әмма аның чын мәгънәсе башкача булырга тиеш. Бу турыда татарларда булган «текеле аягың белән кер» ягъни «якшылык, бәхет китереп кер» дигән фразеологизм булуы күрсәтә. Димәк, чынлыкта, югарыда әйтелгән кошның исемендә дә менә шушы соңгы мәгънә салынган булса кирәк. Ләкин бер сорау кала: нинди «дәүләт кошы» турында сүз бара соң дастанда һәм ни өчен Кара лачын нәселеннән булган ау кошы Туктамыш хан өчен әһәмиятле булган? Куелган сорауга җавап эзләгәндә, безгә эпик дөнья белән эш иткәнебезне онытырга ярамый. Әмма, дастанда искә алынган ике төр кош (ау кошы – Кара лачын һәм «дәүләт кошы» – куш канатлы, кашлы / күзле алтын таҗга «сеңгән» кош кыяфәтле сын) арасында ниндидер, әлегә безгә билгеле булмаган, бәйлелек бар кебек.

Ул бәйлелекне сүтә башлар өчен безгә яңадан «Түләк белән Сусылу» дастанында искә алынган «алтын тәхет» куелган Балкан тау өстен-

дә очып йөргән «миңезлик кошка» (нәселе – ак шоңкар) әйләнеп кайту кирәк. Исегезгә төшерәбез: ул кошның билгеләмә өлешенең мәгънәсенә «акча, тәңкә» төшенчәсе дә керә, ягъни, «акчага сугылган кош» [сурәте] күз алдында тотыла. Шулай булгач, монда да «дәүләт кошы» килеп чыга түгелме? Безнең уйлавыбызча, андый нәтиҗәгә чынлап та килергә мөмкин, ләкин аңа кадәр бу мәсьәләнең кайбер нюансларын тикшерү кирәк (түбәндә китереләчәк мәгълүматлар буенча махсус рәвештә карагыз: [Исхаков: 2013-б]).

Иң башлап, «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәренә мөрәҗәгать итик. Билгеле булганча, анда Чыңгызханның бәкләренең кабилә билгеләреннән (*оран, агач, кош, тамга*) тыш аның үзенең дә аерым шундый ук атрибутлары китерелә. Менә алар: оран – йан каба (*jan qaba*), агач – чинар, кош – ике баш кара кош, тамга – кош баш[ы]. Мәсьәләнең кызыклы ягы шунда – үз вакытында Чыңгызханның бабалары чыккан кыйат кабиләсенең бу чыганакта китерелгән билгеләре башка төрле: оран – аруйан (*arujan*), агач – карагай, кош – шоңкар, тамга – ашамай (*ačamay*) [Ivanics, Usmanov: 2002. PP. 56, 59]. Мондый аерманы ике төрле аңлатырга мөмкин: 1) Чыңгыз ханның нәселе кыйат кабиләсенең аерым бер тармагыннан – бурджигин исемле ырудан булу сәбәпле, бәлки, бу тармакның билгеләре башка төрле булгандыр; 2) Күрсәтелгән нәсел Бөек Монгол империясендә иң югары дәрәҗәгә күтәрелгәч һәм кабиләләрдән өстен урын алгач, аның токымының билгеләре дә үзгәргән булырга мөмкин. Чыннан да, кайбер фактлар шундыйрак нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, табигатьтә бит ике башлы кошлар юк, димәк, бу атрибут – ясалма. Шулай булгач, Чыңгызхан нәселенең башка билгеләре дә уйлап чыгарылган булырга мөмкин.

Ничек кенә булмасын, «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә бирелгән Чыңгызханның кошының атамасы – «кара кош», инде китерелгән «Идегәй» дастанындагы Туктамыш ханның кошының исемен хәтерләтә («кара лачын»).

Әмма, мәсьәлә алай гади генә түгел, шуңа күрә, аны чишү өчен, орнитология фәненә дә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Эш шунда ки, татарларда билгеле «каракошны», орнитологлар карчыгалар гаиләсенә кертсәләр дә, ул тагы бер исем йөртә – «кара бөркет» дигән. Ә ул төр кошлар шул ук карчыгалар гаиләсенә карыйлар. Шул ук вакытта лачын – ул башка отрядка – лачыннар отрядына (Falconidae) карый. Димәк, татарларда каракош һәм бөркет – карчыгалар гаиләсенә карый торган кошлар. Шулай булгач, Туктамыш ханның «кара лачыны» Чыңгыз ханның «кара кошы» белән бөтенләй ук тәңгәл килми. Дөрес, «кара» дигән төс билгесе монда уртак.

Шулай да, Чыңгызхан нәселенең борынгы кабилә билгесе булган «шоңкар» дигән кошның лачыннар гаиләсенә керүен дә истә тотарга кирәк. Бу очракта Туктамыш ханның «кара лачынын» без бөтенләй үк тикшерүдән төшереп калдыра алмыйбыз. Мондый рәвешле фикер йөртсәк, алдагы нәтиҗә килеп чыга: төрле исемдәге кошларны барлаганда ике мәдәни традиция күренә – монгол традициясе лачыннар рәтенә керүче шоңкар белән эш итсә, төрки традиция бөркетләр һәм карчыгалар рәтенә керүче каракошны алга чыгара. Ахрысы, «Идегәй» дастанында без ике мәдәни традициянең үзара кушылуын күрәбез. Әмма, бу очракта да бер проблема чишелмичә кала: борынгы монгол традициясендә Чыңгызхан нәселенең кошы ак төстә (ак шоңкар), ә «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә аның кошы кара төсле (Кара кош, кара кош) буларак билгеле. Монда ике аңлатма мөмкин: яисә бу шушы төр кошларның ике төрле исеме генә, яисә бу очракта без ике төрле этномәдәни (монгол һәм төрки) традициянең чагылышы белән очрашабыз. Әгәр дә соңгысы дөрес булса, «Идегәй» дастанында шушы ике традициянең үзара синтезы күзәтелә – «кара лачын» әле лачыннар рәтенә керә, ләкин төсе буенча ул инде «каракошка», ягъни бөркетләр һәм карчыгаларга якынайтыла.

Әйтелгәнгә өстәп тагы бер мәсьәләгә тукталу кирәк – Чыңгыз ханның тамгасына. Инде күрсәтелгәнчә, ул татар тарихи традициясендә «кош баш» дип йөртелгән. Һәм бу юкка гына түгел – әгәр дә Бату хан нәселенең («Бату йортының») акчаларын тикшерсәң, анда кошка охшаган (ике якка караган томшыклары да чамалана аерым очракларда) рәсем бар. Менә алар: . Ә инде Үзбәк һәм Җанибәк ханнар дәверендә шул ук урында акчаларда ап-ачык рәвештә ике башлы кош сурәтләнә. Нәкъ менә шул инде ул «ике баш каракош» (русларның гербларындагы «двуглавый орел» да аннан килә, дип уйлыйбыз). Фәнни әдәбиятта Алтын Урда акчаларында мондый рәсемнәрнең барлыкка килүен төрлечә аңлатсалар да (мәсәлән, Византия йогынтысы дип), аны шушы дәүләткә нигез салган Чыңгызыйларның борынгы кабилә символы дип карарга да мөмкин. Ягъни, ике башлы кош – каракош, ак шоңкардан, Чыңгызхан кабиләсенең сульдэ / онгоныннан үсеп чыккан булырга мөмкин. Тамгалары да шул кош рәсеме белән бәйле булган булырга тиеш (ләкин онытмыйк: кош һәм тамга – икесе ике җисем). Шушы рәвешле фикер йөрткәндә, «Идегәй» дастанындагы Туктамыш ханның кошы мәсьәләсе бөтенләй башка мәгънә ала.

Беренчедән, «алтын таҗга» беркетелгән пар канатлы кош сыны иске монгол традициясе белән килүче Чыңгызхан нәселенең сульдэ кошы

белән бәйле дәүләт символы дәрәҗәсенә күтәрелгән билге булып чыга (акчаларга да сугылгач, ул инде, димәк, герб урынына йөргән). Ә бу кош – ыру-кабилә, нәселнең рухы, димәк, язмышы (бәхете – ырысы) белән дә бәйле.

Дастандагы реаль «кара лачын», ау кошы буларак күрсәтелсә дә, символик тотем кошын чагылдыра булса кирәк. Димәк, Котлыкыя би ул «дәүләт кошының» балаларын чит җирләргә җибәреп, үзенең хөкемдары Туктамыш ханга гына хыянәт итми, ә Алтын Урда дәүләтенә, аның сәяси элитасы булган Чыңгызыйлар нәселенә дә хыянәт ясый.

Шуңа күрә дә дастандагы ике рәт кошларны – реаль һәм символик – без бергә карарга тиешбез, чөнки сүз анда, чынлыкта, бер үк нәрсә турында – дәүләтнең язмышы турында бара һәм монда символик мәгънә белән реаль чынбарлык бер-берсенә тарихи рәвештә бәйләнгәннәр. Димәк, эпостагы кошлар мәсьәләсенә тирән мәгънә салынган.

### § 4. «Туктамышның дәвере»: затлы татарлар мәсьәләсе

«Идегәй» дастанын өйрәнгән вакытта шуны истән чыгармаска кирәк – XIV-нче йөзнең икенче яртысы – XV-нче йөзнең башларында Алтын Урда дәүләтенең хөкем итүче халкы, ягъни, татарлар, кабилә-ыруларга бүленгән булганнар, ә алар исә, үз чиратында, югары дәрәҗәле (иң затлылары – карача бәкләр бирүче кабиләләр, әйтелгәнчә, алар дүртәү булган) һәм түбәнрәк дәрәҗәле кабиләләрдән торганнар. Туктамыш хан дәверендә һәм Идегәй заманында бу кабиләләрнең төгәл саннары билгеле түгел – XIV-нче йөзнең башларында алар 60–70-тән дә ким булмаганнар [Исхаков, Измайлов: 2007. С. 132–133]. Бәлки, XIV–XV-нче йөзләрнең чикләренә бу сан 90-га җитеп, тагы да арткандыр (алга таба карагыз), чөнки яшәп килгән кабиләләрдә – ә Алтын Урдадагы ыру-кабилә бүленеше булган татарларның саннары XIV-нче йөз урталарына ким дигәндә 2–2,8 млн җиткән [Шунда ук. С. 166] – аларның тармаклануы күзәтелгән. Ләкин, бу кабиләләрнең этник тамырлары һәм Алтын Урда җәмгыятендә тоткан урыннары төрле-төрле булганлыктан, алар дәүләт эшләрендә барысы да бертигез дәрәҗәдә катнаша алмаганнар.

Менә шул яктан «Идегәй» дастанына анализ ясасак, без аннан шактый гына фән өчен яңа булган нәтиҗәләр чыгара алачакбыз. Дөрес, аларга килеп җитү өчен нык тырышырга кирәк булачак, чөнки ул информация дастаннарга хас үзенчәлекләр белән бирелә, ачык итеп, туп-туры гына китерелми. Һәм, һәрбер эпостагы кебек, монда да вакыт – хронология реаль рәвештә түгел, ә эпик закончалыклар белән

бара, ягъни, төрле дәверләрдә яшәгән тарихи шәхесләр дастанда бер заманда хәрәкәт итүчеләр буларак бирелергә мөмкиннәр, ә бу, билгеле, шушы эпик геройлар артында торган тарихи чынбарлыкны «тотып алырга» комачаулый. Әйткәнне истән чыгармыйча, безгә башта тарихи яктан билгелерәк, чыганаклар нигезендә ачыграк бирелгән вакыйгаларга мөрәҗәгать итү һәм аларда күренгән шәхесләрне барлау кирәк. Аннан соң инде тарих томанында калган сәяси төркемнәргә, алар белән бәйле шәхесләргә тукталырбыз.

Идегәйнең үлемен дастанда яктыртуны беренче итеп карап китсәк, уңышлырак булыр. Дастаннан күренгәнчә, Туктамыш ханның улы Кадыйрбирде солтанны бәрелеш вакытында Идегәй би үз кулы белән үтергәч һәм качып киткәч, «Барын мырза» дип исемләнгән шәхес, «Туктамышның биләренә» мөрәҗәгать итеп әйтә:

*Идегәйне кем җиңсә,*  
*Җитеп башын кем алса –*  
*Хан тагына ул менәр! – дип* [Идегәй: 1988. 240 б.].

Шуннан соң, «унике түрә, алты би», Идегәйне куып китәләр һәм аны бер күл янындагы камышлыктан эзләп табып, бик нык яралыйлар, тегесенең хәле беткәч, Барын мырза Идегәйнең янына килеп, аны үтерә:

*Барын мырза бер җитеп,*  
*Идегәйне бер чапты.*  
*Башы тәненнән аерылып,*  
*Тәгәри биреп аны әйтте...* [Шунда ук. 243 б.].

Тәгәрәп киткән баш берничә хикмәтле сүз әйтеп өлгерсә дә, аннан соң Идегәй җан бирә. Шушы фактны күрсәткәч, дастанда мондый юллар китерелә:

*Идегәйнең башын кискән Барын булды,*  
*Башын китергән Шырын булды* [Шунда ук].

Дастанның бу өлешен тирәннән аңлау өчен безгә кайбер тарихи чыганакларга мөрәҗәгать итү кирәк. Ләкин аларны тикшерә башлаганчы, «Идегәй» дастанының кырым татарлары арасында сакланган версиясенә күз салыйк. Анда исә югарыда сурәтләнгән вакыйга турында сөйләнеп, аның буенча тулырак мәгълүмат бирелә. Менә ничек бара анда вакыйгалар агымы: Шырын мырза Барын мырзага Идегәйнең киселгән башын сорап мөрәҗәгать итә һәм кеше үтерү белән бәйле авырлыкны үз өстенә алып, аның белән мырзаны «каннан арындырырга», ягъни, үч алудан коткарырга вәгъдә итә. Әмма, башны тотуга, Шырын мырза качып китә,

аны Кадыйрбирде солтан алдына алып килеп сала да, бүләк ала – аңа «хөкемдар» статусы бирелә. Барын мырза исә «мырза» булып кына кала. Шушы үзе өчен тискәре нәтиҗә турында Барын мырза дастанда Шырын морзаның башка кеше башкарган эшеннән файдаланганын әйтеп, Идегәйне үтерү «Барынга хезмәт итмәде», дип белдерә. Аннан соң ул мырза Идел-Урал яклары арасында язылган (яисә, аның текстына кырым татарлары версиясеннән алынып өстәлгән) дастан версиясендә булган сүзләрне әйтә:

*Идель юрты деврильди,*
*Яу устюне яв кильди.*
*Эдиге айткан кунь кельди,*
*Чынгъызның къойган хан дагъы*
*Хан (дөрестәге – кан – Д.И.) дагъына айланды.*
*Алтын Орду таркъалды,*
*Хан сарайы къалмады.*
*Къырым, Къазан, Аҗдаркан*
*Айры-айры иль болды* [Къырымтатар: 1991. 56 б.].

Чынлыкта, югарыда китерелгән 1419-нчы елны Идегәйне үтерү белән бәйле эпизод турында тарихи чыганаклар да сөйлиләр һәм без алардан ул вакыйгага бәйле кайбер детальләр турында белә алабыз. Әйтик, Кадыйр-Гали бәкнең «Җамигыт-тәварих» (1602) исемле хезмәтендә мондый юллар бар: «Идегә би алтмыш өч яшендә вафат булды. Кадыйрбирде хан белән сугышта яраланды, Барин Сарай шәһит кылды [аны]» [Мирастан: 2011. 16 б.]. Димәк, Идегәйне үтерүче шәхеснең исеме Сарай булып, ул Барын кабиләсе вәкиле икән. Шулай ук, Үтәмеш-хаҗиның «Кара-таварих» (XVI–XVII-нче йөз чикләре) исемле хезмәтеннән күренгәнчә, яраланган Идегәй күл буенда качып ятканда аны Сарай бәк (димәк – Сарай мырза гына түгел, ә бәк булган) табып ала да, аны судан чыгара. Шулчакта Идегәй аннан сорый: «Сезнең ханыгыз бармы?» – дип. Тегесе җавап бирә: «Тәңре рәхмәтигә барды» (ягъни, үлде – Д.И.), – дип. Идегәй тагы да әйтә: «Сез[нең] ил ни булгай, бурунгы падишаһлар андаг халде ил гамын кайгусын[нан] йер икендур» (ягъни, ашарлар иде – Д.И.) [Утемиш-хаджи: 2017. С. 146–147]. Соңгы чыганакта башка детальләр күренми.

Гомумән алганда, кырым татарлары (аларның зур өлеше, билгеле булганча, нугайлардан) арасында сакланган «Эдиге бий» дастаны вариантында Идегәй бинең үлеме турында мәгълүмат тулырак. Тагы бер галим – XVIII-нче йөздә Кырым ханлыгында яшәгән тарихчы – Шырын бәкләре нәселеннән булган Абдулгаффар Кырымлының «Умдәт ул-әх-

бар» исемле хезмәтендә, без тикшерә торган эпизод буенча ике яңа мәгълүмат күренә: беренчедән, Сарай бәкнең Барын кабиләсенең бәге икәнлеге монда турыдан-туры раслана [Кырыми Абдулгаффар: 2014. С. 95, 103], икенчедән, Идегәйнең башын кисеп алып ханга китереп бирүче итеп Шырын кабиләсенең бәге Ректимур (Урәң-Тимур) күрсәтелә. «Шуның өчен ул Җанибәк (Җәләлетдин булса кирәк – Д. И.) хан тарафыннан бүләкләнә»,– дип әйтелә чыганакта. Ә менә Сарай бәккә шул вакыйга уңаеннан Хаҗи-Тарханда даруга бәге булу дәрәҗәсе бирелә [Шунда ук: С. 103]. Ләкин, Абдулгаффар Кырымлы бу хәбәрнең Үрәң-Тимурга кагылышлы өлеше буенча, аңа ышанып бетмичә, шөбһә белдерә һәм аның Туктамыш ханнан соң ук үлүен әйтә, ә «баш карачы» дәрәҗәсенең Шырын бәге Текене (Тегинә) б. Ректимурга күчүен күрсәтә [Шунда ук: С. 103–104].

Шулай итеп, тарихи чыганакларда Идегәйнең үлеме эпизоды буенча беркадәр каршылыклар бар. Әмма, төп вакыйгалар агымы һәм сюжет линиясе дастан белән туры килә.

Булган информация нигезендә безгә хәзер югарыда күрсәтелгән ике затлы татар – «Шырын мырза» (бу очракта бәкләр: Урәң-Тимур яисә аның улы Тегинә күз алдында тотыла) һәм «Барын мырза» (Сарай бәк) турында тирәнрәк мәгълүмат бирә алабыз. Ә аның өчен шушы бәкләрнең һәм аларның кабиләләренең таралып баручы Алтын Урдадагы социаль статусларын ачып бирү кирәк.

Беренче чиратта моның өчен безгә яңадан Үтәмеш-хаҗиның «Кара таварих» әсәренә мөрәҗәгать итәргә кирәк булачак. Шушы тарихчы хезмәтендә Кадыйрбирде һәм Җәләлетдин ханнар (икесе дә – Туктамыш хан уллары) янында Шырын кабиләсе бәге Үрәң-Тимурның уллары Йахшы-хуҗа һәм Тегинә искә алыналар. Аннан соң, Тегинә бәкнең Конграт кабиләсе бәге Хәйдәр белән бергә поход шартларында солтан Олуг-Мөхәммәдне хан итеп күтәрүләре тасвирлана бу чыганакта [Утемиш-хаджи: 2017. С. 69–71]. Тагы бер затлы татар – Айас бәк, кыпчак кабиләсенең бәге ахрысы – Олуг-Мөхәммәд тарафыннан сугышлардагы уңышлары өчен Сарайчыкта даруга [бәге] дәрәҗәсен ала [Утемиш-хаджи: 2017. С. 77–78].

Идел буенда язылган «Дәфтәре Чыңгыз-намә» хезмәтенең бер версиясендә инде тикшерелгән Идегәйнең үлеме белән бәйле эпизодта Шырын бәге Урунг (Үрәң)-Тимур белән бергә Барын бәге Сарай да искә алынганлыгы инде безгә мәгълүм [Исхаков: 2002. С. 34].

Чынлыкта, күрсәтелгән шәхесләр Туктамыш ханның үзе һәм аның варислары янындагы карача бәкләр булганнар, Кырым ханлыгында да шушы династия вәкилләре утыру сәбәпле, 4 кабиләдән (Шырын, Барын,

Аргын, Кыпчак) чыккан бәкләр карачылар урынын биләгәннәр. Ә моның тарихи сәбәпләре бар: Үтәмеш-хаҗи үзенең «Чыңгыз-намә» әсәрендә күрсәткәнчә, нәкъ менә санап кителгән 4 кабилә («ил») «Туктамыш ханның бабаларының искедән килгән илләре», – дип саналган [Утемиш-хаджи: 1992. С. 114]. Бу очракта «*каучин*» атамасы белән йөртелгән Чыңгызхан дәвереннән Чыңгызыйларга бүлеп бирелгән кабилә-илләр күз алдында тотыла. Ягъни, «Идегәй» дастанында «Шырын» һәм «Барын» мырзалар дип исемләнгән шәхесләр – чынлыкта бу кабиләләрне белдерүче эпонимнар – XIV–XV-нче йөзләрнең чикләрендә сәяси әһәмияткә ия булган карачы бәкләренең үз кабиләләрен чагылдыралар, чөнки традиция буенча нәкъ менә шул илләр / кабиләләр Алтын Урданың сәяси тормышында төп рольне уйнаганнар – ханнарны тәхеткә утыртканнар, хәрби хезмәтне башкарганнар.

Әйткәннәргә өстәп тагы бер информация китерүне кирәк, дип санйбыз. Инде күптән басылган, ләкин тарихчыларыбызның игътибарыннан читтә калып килүче бер чыганак бар – 1455-нче елда Мәскәү митрополиты Ионаның Казан ханлыгында яшәгән бер аксөяккә язган хаты сакланган [Акты: 1841. С. 497–498]. Аның адресаты – «Шаптак Сараевич», дип исемләнә. Олуг-Мөхәммәд ханның да Туктамыш хан белән якын туганлыгын исәпкә алганда, бу шәхес тә безгә таныш булган Барын Сарай бәкнең туганы (улы?) булып чыгарга мөмкин (Казан ханлыгында Барыннарның булуы бәхәссез – карагыз: [Исхаков: 1998]). Шулай итеп, инде тикшереп үтелгән мәгълүматлар күрсәткәнчә, «Идегәй» дастанында исемнәре телгә алынган башка аксөяк татарлар да аерым игътибарга лаек, чөнки алар артында да Алтын Урда дәүләтендәге татар кабиләләре яшеренгән булырга тиеш. Кайбер очракта бу яхшы күренә, ә башка очракларда аерым анализсыз аны ачыклап булмый. Безнең алдыбызда торган бу бурычны башкаруга керешкәнче, дастанда күрсәтелгән Алтын Урда дәүләте эчендә яшәп килгән бер бүленешкә тукталып китү кирәк.

Дастанның баш өлешендә Туктамыш хан турында мондый юллар бар:

*Татардан туган Нугай илендә*
*Туктамыш дигән хан булды,*
.................................................
*Сарай дигән каласы,*
*Сиксән күчә арасы,*
*Сары мәрмәр Алтын Таш*
*Сигез йортка дан булды* [Идегәй: 1988. 11–12 бб.].

Эпоста китерелгән сүзләрдән безгә «сигез йорт» дигән төшенчәгә игътибар итү кирәк, чөнки ул, безнең фикеребезчә, әһәмиятле бер про-

блемага ишарә. Эш шунда ки, әмир Аксак-Тимер («Бырлас Шаһ Тимер») Туктамыш ханга хат язгач, соңгысы аңа җавап хаты җибәрә һәм анда әйтә:

*Тугыз йортка дан булган,*
*Кара лачын ау кошым*
*Сиңа булмас, Шаһ Тимер, – дип* [Шунда ук. 13 б.].

Бу сүзләрдән соң ул үзе, Шаһ Тимергә мөрәҗәгать итеп, болай ди:

*Сигез йортка сыймадың,*
*Тугыз йортны куймадың...* [Шунда ук. 14 б.].

Китерелгән репликадан аңлашыла – «сигез йорт» Аксак-Тимер биләмәләренә якын (яисә, аларга инде кергән) җирдә булып, «тугыз йорт» Туктамыш хан биләмәләренә караган. Эпоста алга таба әле генә китерелгән фикер тулысынча раслана. Мәсәлән, Субра-ерау (җырчы) Идегәйгә карап мондый сүзләр әйтә:

*Яу түбәгә баш егет,*
*Яшең утызга җитмәен,*
*Тугыз йортка дан булдың, – дип* [Шунда ук. 59 б.].

Бу очракта, һичшиксез, Идегәйнең Кобогыл исеме астында Туктамыш ханның төп биләмәләре урнашкан төбәктәге «йортлар» эчендә яшәүе күз алдында тотыла. Ләкин, «Нугай иле» = Алтын Урданың эчке бүленешләренең дастанда башка вариантлары да күрсәтелә. Әйтик, дастанда вакыт-вакыт «азамат ир» Туктамышның «Туксан башлы урдасы» искә алына. Дөрес, эпоста «Алтын Урда, Ак Урда Алтмыш йортка юл иде», – дигән сүзләр дә әйтелә [Шунда ук. 20 б.]. Әмма, анда күбрәк «туксан башлы Урда» дигән төшенчә кулланыла. Әйтик, Идегәй яшьләр арасында беренчелекне даулаганда, әйтә:

*Туксан башлы Урданың*
*Туксан угылы бер булып, – дип* [Шунда ук. 28 б.].

Дастанның тагы бер урынында, Идегәйнең Туктамыш хан исеменнән хәрәкәт иткән Киң Җанбайга әйткән сүзләрендә, шушы ук сандагы «башлы» Урда тагы искә алына:

*Туксан башлы Урдага*
*Тунамый ия булмасам, – дип белдерә Идегәй* [Шунда ук. 85 б.].

Шул ук санны Идегәй белән бергә киткән 17 егет тә аның сүзләрен раслап, кире кайтарып әйткәндә, кабатлыйлар:

*Сине йорттан аерган,*
*Байтак куган Туктамыш*

*Туксан башлы урдасына*
*Туналмый ия булырсың.*
……………………………[ Шунда ук. 92 б.].

Туктамышның «туксан башлы урдасы» эпоста соңгы тапкыр менә мондый юлларда тагы бер мәртәбә искә алына:

*Азамат ир Туктамыш –*
*Унике ире алдында,*
*Тугыз ире артында*
*Туксан башлы урдасын*
*Тәңре хөкеменә тапшырып,*
*Дәрвазасын яптырып,*
*Шәһәренә кереп камалды* [Шунда ук. 154 б.].

Бу юллардан аңлашыла – «туксан башлы» бүленеш ул Урда булып оешкан, ягъни, күчмә тормышлы, татарлар өчен хас булган.

Дастандагы информация нигезендә инде югарыда әйтелеп киткән «тугыз йорт» мәсьәләсен дә бераз конкретрак күз алдына китерүгә мөмкинлек бар. Сүз Туктамыш ханның «тугыз ире» яисә «тугыз батыры» турында бара. Беренче тапкыр дастанда аларны «хан ханәше» Йәникә Туктамыш ханга мөрәҗәгать итеп, Кобогылның (чынлыкта – Идегәйнең) кем икәнлеген раслау өчен «туй кылдыру» (киңәшкә корылтай җыю) кирәклеген искә алганда әйтә: «Тугыз ирең чакырткыл», – дип [Шунда ук. 45 б.]. Кобогылның кем икәнлеген белә алмагач, Туктамыш хан үзе янына Туктар улы Тугача бине чакыртып ала. Тегесе табышмакны чишә алмагач, әйтә:

*Тугыз батыр агасы*
*Кыпчак биең бар булыр,*
*Белсә белер Кыпчак би,– дип* [Шунда ук. 48–49 бб.].

Эпоста Кыпчак бинең сугышчы буларак билгеләнүче сыйфатлары китерелә (пычаклар, тимер тун – көбә, сөңге) һәм аның турында өстәп әйтелә: «Мөйтеннән туган Кыпчак би», – дип [Шунда ук. 49 б.]. Димәк, «тугызның» башында торган («агасы» булган) бу би Мөйтен кабиләсеннән (иленнән) икән. Алга таба, Субра ерау Туктамышка ни өчен Аксак-Тимер биләмәләренә качып киткән Идегәйне куып җитәргә кирәклеген аңлатканда, дастаннан, хан «тугыз ирен торгызып», алар боерыкны үтәү өчен атка атланганда, боларның барысының да биләр булганнар икәнлеге күренә [Шунда ук. 73 б]. Туктамыш хан шулвакытта Кәмалның улы Киң Җанбайга Идегәйне тотып алырга боера да, әйтә:

*Әй тугыз ир, тугыз ир!*
*Җанбай белән бара күр!*

*Алдап-йолдап Идегәйне*
*Үз кашыңа ала күр! – дип* [Шунда ук. 75 б.].

Дастан текстыннан күренгәнчә, Киң Җанбай б. Кәмал ханның «киңәш бирүче бие», «олы би» һәм Туктамышның «өлкән аталыгы» саналган [Шунда ук. 22, 49–50, 52, 115 бб.]. Ләкин ул «тугыз ир» составына туры-дан-туры кермәгән, ахрысы. Нәтиҗә мондый: тугыз «ир / батыр» – барысы да биләр (бәкләр), аларның башында Кыпчак би («Мөйтеннән туган») торган, ләкин «олы би» дип исемләнгән Җанбай (Киң Җанбай) б. Кәмал да шушы берләшмәне җитәкләүдә катнашкан. Монда, инде аңлашылганча, сүз Алтын Урда эчендә булган ниндидер бер әһәмиятле бүленеш турында бара, әмма аның серен ачу өчен безгә «тугызлыкның» асылына төшенү кирәк.

Чынлыкта, дастанда шушы «тугыз ирне/батырны» берничә мәртәбә аерым рәвештә санап китәргә тырышу да күзәтелә. Ул исемлекләр бер-берсе белән бөтенләй үк тәңгәл килмәсәләр дә, аларда уртаклыклар да бар (1 таблицаны карагыз). Андагы мәгълүматлар шушы «тугызлыкның» бер серен шунда ук ачып бирә – чынлыкта, шушы сандагы «ирләр / батырлар» – барысы да биләр / бәкләр – артында татар кабиләләре яшеренгән, чөнки Кыпчак, Аргын, Дөрмән (Дөрбән), Кинегес (Кенегес), Төмән – Алтын Урдада булган татар кабиләләренең (илләренең) атамалары. Шул уңайдан безгә, беренче чиратта, дастандагы «тугыз ирнең/батырның» исемнәре китерелә торган өч исемлеккә игътибар итү кирәк (I–III). Алар арасында беренчесе – иң тулысы булырга охшаган. Ләкин анда да исемлектә 9 түгел, ә 11 атама бар (II-версиядә – 10, III-версиядә – 8). Дөрес, бәлки бу исемлектән «йорт бие» һәм «ил бие» дип аталган ике позиция төшереп калдырылса – бу очракларда кабилә җитәкчеләре түгел, ә административ дәрәҗәләргә ия булган шәхесләр күз алдында тотыла булса кирәк – «тугыз» килеп чыга. Әмма, дастанда Барын мырза турында да «олыс бие» дигән төшенчә кулланылу сәбәпле – ә ул карала торган исемлектәге «йорт / ил бие» төшенчәләренә бик якын – бу исемлек мәсьәләсе тагы катлаулана.

Мәсьәләне ныграк дәлилләү өчен безгә дастанның нугайлар арасында таралган версияләренә мөрәҗәгать итү кирәк (таблица 2). Таблицадан шул күренә – Идел-Урал буе татарларыннан язып алынган дастан версияләре белән чагыштырганда, нугайлардагы эпос вариантларында кабиләләр исемлеге башка төрлерәк. Беренчедән, ул конкретрак, икенчедән, исемлекләр үзара аерыла (иң тулысы таблица 2 китерелгән вариант I). Ләкин монда да кайбер позицияләрнең кабиләләре билгеле түгел, ә кайберәүләре артында (мең, йөз) ыру-кабиләме, хәрби бүленешме тора, белеп булмый. Һәрхәлдә, соңгы ике позицияне исемлектән алсак, шул ук «тугызлык» килеп чыга.

*Таблица 1*

**«Идегәй» дастанындагы «тугыз ир / батыр»**

| | **Исемлекнең версияләре** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| № | I | II | III | IV | V |
| 1 | Мөйтеннән туган Кыпчак би | Мөйтеннән туган Кыпчак би | ... | ... | Мөйтеннән туган Кыпчак |
| 2 | Исәнтәй улы Ходайбирде би | ... | ... | Исән углы Ходай-бирде | ... |
| 3 | Кара Кужа Аргын би | ... | ... | Аргынның углы Кара Кужа | ... |
| 4 | Кәмалнын улы Киң Җанбай | Кәмалнын улы Киң Җанбай | ... | Кәмалнын углы Җанбай | Кәмалнын углы Җанбай |
| 5 | Яңгура – йорт бие | Яңгура – йорт бие | Яңгура – йорт бие | ... | ... |
| 6 | Илтәрәс – ил бие | Илтәрәс – ил бие | Илтәрәс – ил бие | ... | ... |
| 7 | Айбалталы Дөрмән би | Айбалталы Дөрмән би | Айбалталы Дөрмән би | ... | ... |
| 8 | Байназар – диван би | Байназар – диван бие | Байназар – диван бие | ... | ... |
| 9 | Кинегесле Кәрим би | Кинәгесле Кәрим би | Кинегесле Кәрим би | ... | ... |
| 10 | Уймавыттан Үмәр би | Уймавытта Үмәр би | Уймавыттан Үмәр би | ... | ... |
| 11 | Тармавыктан Төмән би | ... | ... | ... | ... |
| | I – версия: Идегәй 1988. 142 б | Кушназар-кош бие | ... | ... | ... |
| | | Алаңгасар Алман би | Алаңгасар Алман би | ... | ... |

| | | | |
|---|---|---|---|
| II – версия: Идегәй: 1988. 116, 121 бб. | Чакмагыштан – Чакалы би | … | … |
| | III – версия: Идегәй: 1988. 155–156 бб. | Акның угылы Булат | … |
| | | Алчагыр угылы Мырза | … |
| | | Соргантай угылы Субра | … |
| | | IV – версия: Идегәй: 1988. 205 б | Олыс бие – Барын |
| | | | Орыш бие – Шырын |
| | | | Төмән башы – Туйбак |
| | | | Аждарканнан – Мулай |
| | | | V – версия: Идегәй: 1988. 221 б |

Әмма, нугайлар арасында язып алынган «Эдигэ» эпосы эчендә башка кабиләләр дә күренеп китә: Кыргыз, Мангыт, Алчын, Конграт, Керей (Герей, Кыпчак-Герей), Тамалы (Тама?), Келеши, Барын [Эдигэ: 2016. С. 32, 56, 75, 158, 210, 239]. Димәк, бу очракта да «тугыз батырны» җиңел генә санап чыгу мөмкин түгел. Әмма алар арасында Кенегес, Шырын, Барын, Аргын, Кыпчак (Мөйтеннән яисә Герейиттан), Найман, Уйшын (тармагы – Төмән булырга мөмкин), Канлы, Дөрмән булган, дип уйлыйбыз. Чынлыкта, бу кабиләләрнең абсолют күпчелеге (Дөрмәннән һәм Барыннан башкалары) – төрки кабиләләр.

Ничек кенә булмасын, тупланган мәгълүмат алга таба «тугызлыкның» тирәнрәк мәгънәсенә төшенергә ярдәм итә һәм безгә ул нигездә бик тә кызыклы нәтиҗәгә килергә мөмкин булачак.

*Таблица 2*

**«Эдигэ» дастанында «тугыз батыр»**

| Вариантар | | | |
|---|---|---|---|
| № | I | II | III |
| 1 | Мең Болат батыр | – | – |
| 2 | Йөз Ногай батыр | – | – |
| 3 | Хырювның Буган батыры | – | – |
| 4 | Найман Касай батыры | – | – |
| 5 | Уйсын Нукай батыр | – | – |
| 6 | Байрабастның Толыш улы Янмухамбет батыр | – | – |
| 7 | Кыпчак Куба батыр[1] | – | – |
| 8 | Канлы Кара Байысы | – | – |
| 9 | Шырын Сылу-Мамбет | – | – |
| 10 | Мангыт Манъка йырав | – | – |
| 11 | Кенгесе улы Кер-Янбай бий | Джанбай сын Кобая из племени кенегес | Кенегестин Кен Жанбай |
| 12 | – | Омрук-Тимир из племени киргиз | |
| 13 | – | Кара-Ходжа из Крыма, аргын | |
| 14 | – | Дженгай-Кусса из племени кипчак | Каракыпчак Копланды |

[1] Башка мәгълүматлар буенча – «тугыз Герей бабасы», ягъни Кыпчак-Герей тармагы.

| Вариантар | | | |
|---|---|---|---|
| № | I | II | III |
| 15 | – | | Муйтеннән чыккан Косдавлет |
| 16 | – | | Эсентай улы Кудайберди батыр |
| 17 | – | | Акбалтыр улы Увак |
| 18 | – | | Монжир улы Чувак |

*Алынды: [Эдигэ: 2016. С. 31–32, 56, 80–82, 210].*

Моның өчен, беренче чиратта, «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә сакланган бер затлы татарлар (титуллары – биләр) исемлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Анда 10 бинең исеме атала, ләкин 6 очракта ул атамалар кабилә этнонимнары булып тора. Менә алар: 1) [Уйшын] Майкы би, 2) Калдар би, 3) Урдуж (Ордач) би, 4) Кыбчак (Кыпчак) би, 5) Тамйан (Төмән / Тӓмӓн) би, 6) Кирайет би, 7) Буркыт (Буртак) би, 8) Тимер Котлы би, 9) Муйтен би, 10) Теленгут / Таленгут / Тангут би [Ivanics, Usmanov: 2002. P. 49; Мирастан: 2011. 75 б.]. Шушы ук чыганакның башка бер версиясендә шулай ук 10 бинең (5 исем-эпоним) исемлеге китерелә, ләкин анда югарыда аталган исемлек белән бераз аерымлыклар да бар: 1) Майкы би, 2) Калдар би, 3) Уркеш би (Урдач булса кирәк), 4) Кыпчак би, 5) Тамиан би, Кереит би, 7) Кунрад (игътибар!) би, 8) Темиркутлу би, 9) Тулак би, 10) Теленгут би [История Чингиз хана: 1907. С. 131]. Ике очракта да бу биләр агалары басымы астында читкә китеп барган Чыңгызны эзләп киләләр һәм аларны әйдәп баручы итеп Уйшын Майкы би күрсәтелә. Чынлыкта, икенче исемлектәге «Кунрад би» анда була алмый, чөнки «Дәфтәре Чыңгыз-намә»нең беренче версиясендә күрсәтелгәнчә, Чыңгызны эзләргә барудан 4 би баш тарта – алар Кунгырат би, Кытай би, Салчут би һәм Кыят би [Мирастан: 2011. 48 б.; Ivanics, Usmanov: 2002. P. 49]. Алар барысы да монгол кабиләләрен чагылдыралар.

Әгәр дә без дастандагы исемлекләрдәге кабиләләрнең тулы атамаларын торгызсак, мондый нәтиҗә килеп чыга: 1) Уйшын, 2) Кимак (бәлки – Албыр / Ольбер), 3) Мең, 4) Кыпчак, 5) Төмән, 6) Кирайет, 7) Буркыт, 8) Тангаур, 9) Муйтен, 10) Теленгут / Толенгут. Алар, уйлап карасаң, һәммәсе дә диярлек «чын татарлар», ягъни төркиләр. Монголлардан төрле исемлекләрдәге Мангыт (сорау астында), Дөрбән, Барын кабиләләрен генә санарга була. Шулай да, кимаклардан булган Калдар б. Балын бәкне (ул – Албыр кабиләсеннән булган) искә алмаганда, са-

нап кителгән «йортлар» электән «ышанычлы» яки «иске» (Чыңгызхан дәвереннән килгән) кабиләләрдән булып, аларның бәкләре Чыңгызыйлар белән якын булып чыгалар. Бәлки, без монда төркиләрнең күплелеген Җучи Олысы «татарларының» этник составыннан чыгып аңлатырга тиешбездер.

Әгәр дә санап кителгән кабиләләр арасыннан – «тугызлыктан» – берсен өскә чыгарсак (бу очракта – Кенегес кабиләсе вәкилен), шул ук юл белән «Дәфтәре Чыңгыз-намәдәге» Уйшын Майкы би дә башкалардан аерыла, чөнки эшләгән эшләре өчен Чыңгызхан аңа «бәклек» дәрәҗәсе бирә [История Чингиз хана: 1907. С. 131; Мирастан: 2011. 49 б; Ivanics, Usmanov: 2002. P. 51].

Нәтиҗәдә «тугызлыкны» без 1+8 дип карый алабыз, ә бу исә Туктамыш хан биләмәләрендәге «тугыз йорт», «тугыз ир/батыр» саны белән туры килә. Монгол тарихчысы Лубсан Данзан буенча, Кенегес (Кингит) кабиләсенең башлыгы Хукин нойон Җучи Олысының көнбатыш өлеше өчен җаваплы итеп билгеләнгәндә, аның карамагында 8000 гаскәри булган [Лубсан Данзан: 1973. С. 232]. Ә бу бит 8×1000 дигән сүз, меңлек исә Монгол империясендә әһәмиятле сугышчылар төркеме булган. Рәшид ад-Динда исә Кенегес (Кингит) кабиләсенең Җучи олысына кергән 4 берәр меңлек гаскәр эчендә булуы күрсәтелә [Рашид ад-Дин: 2002. Т. I. Кн. 1. С. 172]. Ләкин бу тарихчы ул биләмәдә уң як (*барунгар*) гаскәрләре белән Уйшын Майкы би җитәкчелек иткәнлеген күрсәтә [История татар Западной Сибири: 2015. С. 123–124]. Бусы исә «Дәфтәре Чыңгыз-намә»дә Уйшын Майкы бинең Чыңгызханнан уң якта утыруында чагыла. Димәк, Кенегес һәм Уйшын кабиләләре (һәм аларның бәкләре) тигез дәрәҗәдә саналганнар һәм Җучи Олысында көнбатыш өчен җаваплы булганнар. Шуңа күрә «Идегәй» дастанында нәкъ шушы төбәкне чагылдырган «тугыз ир/батыр» башында Кенегес кабиләсеннән булган Җанбай б. Кәмалның [Эдигэ: 2016. С. 31–32, 41, 56, 61 и др.] торуы очраклы түгел. Юкка гына ул дастанның кайбер версияләрендә «вәзир, олыг вәзир» дип кенә түгел [Шунда ук. С. 180, 185, 244], ә Туктамыш ханның «олы бие», «корылтай башы», «беренче киңәшчесе», «иң акыллы бие» [Шунда ук. С. 61, 137], дип аталмый. Аннан соң, ул дастанда кайбер очракларда «кенегеснең артык бие», «кенегестән киткән» би итеп күрсәтелә [Шунда ук. С. 31–32, 90, 160]. Димәк ул Кенегес кабиләсеннән «өстен» торган, ахрысы, кайсыдыр чорда Җанбай бәкләр бәге/олы бий буларак Ак Урданы – Алтын Урданың көнбатыш өлешен кулда тоткан, дип уйлый алабыз. Ә аның моңа, күргәнебезчә, тарихи хокукы булган.

Ә нәрсә күз алдында тотылган соң Аксак-Тимер «сыймаган» башка бер, «сигез йорттан» торган биләмә астында? Һәрхәлдә, ул биләмә Аксак Тимернең үз җирләре булганга охшамый, чөнки дастанда Туктамыш хан Аксак-Тимер турында мондый сүзләр әйтә:

*Асылсыздан туган Тимер би*
*Сәмәркандка шаh булса,*
*Унике йортка баш булса* [Идегәй: 1988. 115 б.].

Күренә ки, Аксак-Тимернең биләмәсендә 8 түгел, ә 12 «йорт» булган булып чыга. Шуның өстенә, «сигез йорт» дастанда Алтын Урда белән бергәрәк карала:

*Алтын Урда, Ак Урда*
......................................
*Сарай дигән каласы,*
*Сиксән күчә арасы,*
*Сары мәрмәр Алтын Таш*
*Сигез йортка дан булды*
....................................... [Шунда ук. 12 б.].

Шулай булса да, Туктамыш ханның Аксак-Тимергә җибәргән хатыннан күренгәнчә, бу «сигез йорт» «Сәмәркандта утырган» Шаh Тимергә, «әмир бырласка» (Барлас кабиләсенең әмиренә) да, нииндидер мөнәсәбәттә була:

*И Шаh Тимер, Шаh Тимер,*
*Тешең җитсә, таш кимер!*
*Сигез йортка сыймадың,*
*Тугыз йортны куймадың* [Шунда ук. 14 б.].

Безнең фикеребез буенча, дастандагы «сигез йорт» астында Алтын Урданың сул канаты кабиләләре – элекке Күк Урда – күз алдында тотыла. Моны дастандагы мәгълүмат аркылы гына раслап булмый, ә менә башка бер тарихи чыганак – Ибн Баттута (1304–1377) язмаларыннан чамалап була. Ул Хәрәзм вилайәтендә булганда, аның сәяси үзәге – Хәрәзм шәhәрендә барган суд процессын күрә hәм тасвирлый. Ибн Баттута күрсәтә: монда бөек әмир булган Котлы-Тимер (Кутлудумур) резиденциясендә көн саен була торган суд эшләрендә кази hәм хокук белгечләре белән битекче (*яргучылар*), шулай ук (игътибар!) «өлкән әмир, аның янында 8 [башка] өлкән әмирләр hәм төрки шәехләр (яргучылар)» катнашканлыгын [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 146]. Күренә ки, суд эшләрендә «утыручы» 8 «өлкән әмир» мондагы төп 8 кабиләнең бәкләре булырга мөмкин. Ахрысы, бу «сигезлеккә» тагы бер судта

катнашкан «өлкән әмир» кермәгән, бәлки ул «бөек әмир» Котлуг[Котлы]-Тимернең (кабиләсе буенча Кыйат булса кирәк – карагыз: [Исхаков: 2009-б. С. 39–40]) вәкиле буларак катнашкандыр бу судларда. Әгәр дә шушы гипотезаны кабул итсәк, «Идегәй» дастанында әйтелгән «тугыз йорт» һәм «сигез йорт», ягъни Алтын Урданың уң һәм сул канатларындагы төп кабиләләрнең – «йортларының», тулаем саны 17 булып чыга. Нәкъ менә шул сан безгә Ибн Баттутадагы тагы бер мәгълүматка таянырга ярдәм итә.

Бу тарихчыга 1334-нче елны (вакыйга 2-нче июньдә була) Биштау (Бишдаг / Пятигорск) төбәгендә булган зур бәйрәмдә (корылтай булса кирәк) катнашырга туры килә (тулырак карагыз: [Исхаков: 2011]). Шул бәйрәм вакытында башка йолалар һәм церемонияләр белән бергә, Үзбәк хан анда хәрби парадка охшаган гаскәри берләшмәләрне (сүз төмәннәр / унмеңлек гаскәри берләшмәләр турында бара) барлауны да үткәрә. Бу вакыйгада исә 17 әмир / төмән башлары (темниклар) катнаша! (карагыз: [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 138]). Алар кул астында, чыганактан күренгәнчә, 17 унмеңлек (17×10000) гаскәр була.

Бу уңайдан тагы бер чыганакка мөрәҗәгать итү кирәк. Сүз «Дәфтәре Чыңгыз-намә»нең яңа бер версиясе турында бара (карагыз: [Мустакимов: 2009]. Хәзер бу чыганак тулы килеш басылды (карагыз: [Чыңгызнамә: 2019])). Анда «Җанибәк хан заманындагы бәкләрнең атлары» башы астында бер төркем затлы татарлар санап кителә (безгә таныш булган Шырын Урук-Тимур, Аргын Кара-Ходжа, Барын Сарай-бий да бар анда). Аларның саннары шулай ук 17! Санап кителгән бәкләр барысы да Җанибәк хан дәверендә яшәмәсәләр дә [Исхаков: 2009-б. С. 4–35], бу очракта китерелгән сан әһәмиятле, чөнки ул югарыда ясалган нәтиҗәне хуплый.

Шулай булгач, Үзбәк хан һәм Җанибәк хан дәверендәге Алтын Урданың «тугыз йортка» (уң канат – Ак Урдага) һәм «сигез йортка» (сул канат – Күк Урданың калдыгына) бүленеше XIV–XV-нче йөзләрнең чикләренә кадәр килеп җиткән. «Идегәй» дастанындагы мәгълүматлар моны ачык күрсәтәләр.

Инде «туксан башлы Урда» төшенчәсенә дә тукталып китик. Безнең фикер буенча, аның артында билгеле бер дәвердә (XV-нче йөзнең башларында) Алтын Урдада булган кабиләләр һәм эре ыруларның саны тора. Чөнки, тарихчылар инде билгеләп үткәнчә [Султанов: 1977], күчмә тормышта яшәгән Шибанидлар («күчмә үзбәкләр») дәүләтендә XVI-нчы гасырда «илатийа» (мәгънәсе – күчмәләр) дип билгеле булган 92 кабилә-ыруга бүленеш булган (моны Ахсикендиның «Маджму

ат-таварих» хезмәтеннән дә күреп була – [Сайф ад-дин: 1996. С. 6–17]). Шибанилар җитәкләгән «күчмә үзбәкләр» (ягъни, Үзбәк ханнан калган халык) XVI-нчы йөз башларына кадәр (төгәлрәге – 1509–1511-нче елларга кадәр) Урал буе – Көнбатыш Себер – Казакъстан далаларында көн күреп, аннан соң гына көньякка – Аксак-Тимер варисларының биләмәләренә күчеп китүләрен истә тотсак, шушы 92 ыру / кабилә Алтын Урданың «туксан башын» чагылдыра, дип уйлый алабыз. Дөрес, чынлыкта кайбер очракларда «Идегәй» дастанында Ак Урданың – Туктамыш хан Урдасының, «алтмыш башлы» булуы турында да әйтелә (нугай версиясендә: [Эдигэ: 2016. С. 79]). Идел буе татарлары арасында язып алынган дастан версияләрендә исә Ак Урданың, инде билгеләп үтелгәнчә, «Алтмыш йортка юл» булганлыгы күрсәтелә [Идегәй: 1988. 20 б.]. Сүз бер үк җисем – Алтын Урдадагы кабиләләр саны турында барса кирәк. Ләкин, бу соңгы очракта без шушы дәүләттәге иртәрәк чор өчен – XIV-нче йөзнең урталарында, яисә XIII-нче йөздә булган кабиләләр саны белән очрашабыз, дип уйларга урын бар. Мәсәлән, ан-Нувейри (1279–1333) билгеләп үткәнчә, 1316-нчы елга Үзбәк хан кул астында 70 әмир – төмән башлыклары, булган [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 84].

Безгә хәзер яңадан «Идегәй» дастанындагы 9 «иргә / батырга / бәкләргә» әйләнеп кайту кирәк. Дастан текстында санап кителгән бәкләр (кайбер очракта аларның исемнәре урынында кабилә атамалары – эпонимнар гына тора), чынлыкта, барысы да тарихи шәхесләр булганнар, дип уйларга урын бар. Әйтик, «аргыннарның башы» саналган Кара-Ходжа (Кара‘ужа) бәк Шәрәфетдин Али Йездинең «Зафәр-намә» (1424/1425) әсәреннән күренгәнчә, качып йөрүче Туктамыш хан исеменнән Тимур янына килә. Аның турында чыганакта бик төгәл итеп шушы ханның «элгәредән килгән нукерларыннан иде», дип языла [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 66]. Бу вакыйга Тимурның 1405-нче елны Отрар шәһәрендә үлүе алдыннан була. Чынлыкта, Кара‘ужа бәк Олуг-Мөхәммәд белән бергә соңыннан Казан вилайәтенә килеп урнашкан һәм ул бәкнең нәселе Кырым ханлыгында да калган. Алга таба бу мәсьәләгә без «Чура батыр» дастанын тикшергәндә тулырак тукталырбыз (Казан ханлыгындагы Аргыннар турында карагыз: [Исхаков: 2002]). Инде «Барын мырза» һәм «Шырын мырза» турында әйтелде. Барын мырзаның без Барын кабиләсе бәге Сарай икәнлеген ачыкладык. Шырын мырза исә Тегинә бәк булырга тиеш. Хәлбуки, нугайларда язып алынган «Эдигэ» эпосының кайбер версияләрендә Шырын кабиләсе «батыры» итеп «Сылув-Мамбет» күрсәтелә. Гомумән, нинди җирлектә язып алынуына карап «Идегәй» дастанындагы «ирләр / батырларның» кабиләләре һәм исемнәре беркадәр аерылырга

мөмкин. Монда иң әһәмиятлесе – аларның саннары – «тугызлык». Ләкин ул сан да тотрыклы түгел. Әмма, бу мәсьәләне без хәзер ныклап тикшерә алмабыз, чөнки ул төп темадан ераклаштырыр язмабызны.

Хәзер безгә башка бер мәсьәләгә кучү кирәк булачак – ул да булса Алтын Урда дәүләтенең атамалары һәм аларның барлыкка килү сәбәпләре.

**§ 5. Алтын Урда, Ак Урда һәм Бүз Урда...**

«Идегәй» дастанын өйрәнгәндә тагы бер, шактый катлаулы һәм фәндә әле дә чишелеп бетмәгән, мәсьәлә буенча яңа фикер әйтергә мөмкинлек туа. Сүз Җучи Олысының үз атамасы турында. Бу турыда бара торган бәхәсләрнең нигезендә берничә проблема ята: беренчедән, аның ике өлешкә бүленеп – Ак һәм Күк Урдаларга – кайсы өлешенең ничек аталуы буенча; икенчедән, Алтын Урда (русча «Золотая Орда», инглиз телле әдәбиятта, русчадан калька рәвешендә, «Golden Horde») терминының барлыкка килүе (генезисы) һәм мондый атаманың Җучи Олысының гомуми исеменә әйләнүенең сәбәпләре. Шул уңайдан тарихи әдәбиятта таралган «Алтын Урда / Золотая Орда» төшенчәсенең историографиягә рус әдәбияты аркылы керүе турындагы карашның [Кушкумбаев: 2017-а. С. 356] дөреслеге мәсьәләсе дә бар. Соңгы карашның нигезе – XVI-нчы гасырның икенче яртысына караган «Казанская история / Казанский летописец» дип аталучы рус чыганагына барып тоташа, чөнки ул әсәрдә чынлап та «царство Златыя Орда царя Ахмата», «Золотая Орда», «великие Орды Златыя» дигән атамалар очрый (карагыз: [Казанская история: 1954. С. 45, 49, 53, 55]). Ләкин бу фикер башка бер европалы автор язган хезмәттәге мәгълүмат тарафыннан юкка чыгарыла. Бу очракта без бавариялe солдат (ул Идегәй дәверендә Җучи Олысында хезмәт итә) Иоганн Шильтбергер хезмәтен истә тотабыз. Ә ул автор исә шушы дәүләт турында язганда, аңа карата «Алтын Татария / Золотая Татария» һәм «Бөек / Олуг Татария / Великая, Большая Татария» яисә «Татария» генә дигән терминнарны куллана [Шильтбергер: 1984. С. 33–34, 43, 44–46]. «Татария» төшенчәсен «Татар иле» дип карап булганга, аның «Урда», ягъни, дәүләт булып оешкан татарлар берләшмәсен аңлатканлыгын төшенергә мөмкин [Исхаков: 2007-а]. Кыскасы, «Татария» – ул шул ук «Урда» дигән терминның калькасы. Моннан күренә – XV-нче гасыр башында инде Җучи Олысына карата ике атама кулланылган – «Алтын / Золотая Татария / Урда» һәм «Олуг (Бөек) Татария / Урда». Чынлыкта «Казанский летописец» исемле хезмәттә дә нәкъ шушы ук терминнар кулланыла (андагы «великие Орды Златыя» «Олуг / Бөек» һәм «Алтын / Золотая» Орда («Татария») төшенчәләрен чагылдыра, дип уйлыйбыз). Әгәр дә без тагы бер документны – 1393-нче елны Туктамыш ханның Литваның бөек князе вә Ляхистанның (Польшаның) короле Ягайлога язган хатын карасак, анда Алтын Урданың «Олуг Олыс» дип

исемләнгәнен күрә алабыз [Özyetegin, Kemeloğlu: 2017. S.40–41]. Монда «Олыс» – «Урда» төшенчәсен чагылдыра.

Менә шушы ике рәт атамалар булуы – «Алтын» һәм «Олуг» Олыс / Урдалар – аңлатуны таләп итә дә, чөнки бу ике терминның үзара мөнәсәбәтләре бик үк аңлашылып бетми. Моңарчы алар арасындагы бәйлелекне Җучи Олысында хөкем иткән Чыңгызыйларның сәяси үзәге – кабул итүләрдә алып барыла торган ставкасының, «алтын» термины белән билгеләнүе аркылы аңлаталар иде (карагыз: [Федоров-Давыдов: 1973. С. 64–67; Исхаков, Измайлов: 2007. С. 83– 84]). Бу фикер тулаем алганда дөрес булса да, ул тикшерелә торган мәсьәләнең кайбер якларын бик үк аңлатып бетерми – мәсәлән, «Ак Урда» белән «Алтын Урда» төшенчәләренең үзара мөнәсәбәтләре нинди булганлыгын. Ачык күренә бит, бу ике термин арасында эчтәлек ягыннан аермалыклар бар, аларның мәгънәләре бер үк түгел. Менә шуңа күрә дә безгә «Идегәй» дастанына мөрәҗәгать итү кирәк, чөнки анда булган мәгълүмат, безнең фикеребезчә, югарыда куелган сорауларга тулырак һәм тарихи яктан дөресрәк итеп җавап бирергә мөмкинлек бирә.

«Идегәй» дастанының татарлар арасында табылган вариантларында мондый юллар бар:

*Алтын Урда, Ак Урда*
*Алтмыш йортка юл иде* [Идегәй: 1988. 20 б.].

Монда «Алтын Урда» һәм «Ак Урда» терминнары бер-берсен алмаштыручы, тәңгәл булган төшенчәләр буларак кулланыла. Әмма, «Алтын Урда» төшенчәсе эпосның татар версияләрендә аерым да кулланыла, мәсәлән, аның соңгы юлларында:

***Идел-Урал буйлары татарлары варианты***

*Кырым, Казан, Әҗдаркан*
*Башлы-башлы ил булды,*
*Алтын Урда таралды*
[Идегәй: 1988. 245 б]

***Кырым татарлары варианты***

*Алтын Орду торкъалды,*
*Хан сарайы къалмады.*
*Къырым, Казан, Аждархан*
*Айры-айры иль болды*
[Къырымтатар: 1991. 57 б].

Башка халыклар арасында таралган дастан вариантларында бу төшенчә – «Алтын Урда» термины – күренми, шул исәптән, нугайларда да. Әмма, аларда башка бер термин бар. Ул – «Ак Урда» төшенчәсе. Мәсәлән, эпосның нугай версияләрендә «алтмыс / туксан басты Ак Урда» дигән билгеләмәләр бар [Эдигэ: 2016. 79, 84, 302 бб.]. Шуңа охшаган термин дастанның казакъ версияләрендә дә очрый – «Еңесі биік Ак Орда», «Алты канат Ак Орда» [Кушкумбаев: 2015. С. 41; Эдіге: 1989.

С. 90]. Исегезгә төшерик, Идел-Урал буе татарларында да «алтмыш/туксан башлы Урда» термины күзәтелә, ләкин ул «ак» дип билгеләнми. Әмма, татарларның «Идегәй» эпосында «Ак Урда» термины барыбер килеп чыга. Ул Идегәйнең үзенең улы Морадымга (Нур-ад Дингә) әйткән сүзләреннән күренә:

*Алтын тауга барганмын,*
*Түрә булып алганмын,*
*Халкын җыеп алып килеп,*
*Ак Урдага салганмын, – ди Идегәй* [Идегәй: 1988. 21 б.].

Тикшерелә торган мәсьәлә турында сүз алып барганда, эпостагы «Алтын Урда», «Ак Урда» төшенчәләрен куллануның бер нюансы барлыгын искәртеп китү кирәк: дастанга «урда» терминын хан ставкасына карата куллану да, аңа якынайтырга тырышу да хас. Мәсәлән, «Идегәй» дастанында әйтелә:

*Алтыннан суккан урдасын,*
*Көмештән суккан ишеген*
*Төсе суык чын булат*
*Очы белән ачмасам…* [Шунда ук. 85 б.].

Эпосның нугай һәм казакъ версияләрендә дә шундый ук мәгънә салынган:

***Ногай варианты:***

*Алтындан сокган ак орданын*
*Көмештен соккан ак эсик*
*Туъссе сувык чын болат*
…………………………[Эдигэ: 2016. 84, 88 бб.].

***Казакъ варианты:***

*Алтын соққан Ақордаң,*
*Күмістен соққан ақ есік* [Кушкумбаев: 2017-а. С. 359].

Күренә ки, бу очракта сүз дәүләт, халык турында түгел, ә ставка – чатыр, тирмә турында бара. Шулай булгач, Алтын Урда / Ак Урда төшенчәсенең ике мәгънәсе барлыгы ачыла – ул, бер яктан, сәяси берләшмәне – дәүләтне белдерсә, икенче яктан аның сәяси үзәген – хан ставкасын аңлаткан.

Шул ук хәлне без эпоста параллель рәвештә кулланылган «Бүз Урда» төшенчәсе буенча да күзәтә алабыз. Беренчедән, дастанның татар, казакъ һәм нугай версияләрендә «Ак Урда» урынына «Бүз Урда» атама-

сы да кулланыла. Мәсәлән, «Иңәсе биек Бүз Урда» [Идегәй: 1988. 78, 81 бб.], «Энегесе бийик Боз Урда» [Эдигэ: 2016. С. 38, 85, 163, 183, 211, 278], «Еңсесі биік Боз Орда» [Кушкумбаев: 2015. С. 40]. Бер караганда, монда сүз дәүләт турында бара һәм «Бүз / Боз Урда / Орда» термины «Алтын Урда / Ак Урда» төшенчәсен алыштыра кебек. Казакъ тарихчысы А.К. Кушкумбаевның моның шулай икәнлегенә басым ясап, «Бүз / Боз Урда / Орда» төшенчәсенең «аксыл / якты» мәгънәсе барлыгын күрсәтеп, аның «Ак Урда» урынына күчмәләрдә кулланылган образлы-метафорик термин булганлыгын искәртүен искә алсак [Кушкумбаев: 2015. С. 41], бу бигрәк тә шулай. Ләкин, икенче яктан караганда, «Бүз Урда» дигән төшенчә дә дастанда югарыда әйтелгән «сәяси үзәк, хан ставкасы» термины мәгънәсенә ия. Әйтик, дастанның нугай версияләрендә мондый юллар бар:

*Каслы, каслы, каслы орда*
*Босагасы боз орда,*
*Босагасы болаттан,*
*Болатка алтын ялаткан* [Эдигэ: 2016. С. 214, 289].

Бу очракта шушы «Урданың» үзенең «Алтыннан суккан», ишегенең «көмештән суккан» икәнлеге турындагы югарыда китерелгән җөмлә белән турыдан-туры мәгънәви охшашлык барлыгы ярылып ята. Шулай ук, дастанның казакъ версияләрендә күренгән «Алты канат Ак Орда» дигән термин да дәүләткә түгел, ә ставка – чатырга карарга мөмкин, чөнки Алтын Урдада / Ак Урдада «алты канат» бервакытта да булмаган, алар икәү генә (уң, сул канатлар). Тагы бер уйландыра торган төшенчә – «Иңәсе биек Бүз Урда / Ак Урда». Бу сүзләрне тәрҗемә иткәндә А.К. Кушкумбаев «иңәне» «биек» сүзе белән бергә «высоковерхая», «высокая, просторная» дип тәрҗемә итеп [Кушкумбаев: 2015. С. 40–41], аңа дәүләтне аңлатучы термин буларак карарга кирәклегенә ишарә ясый. Чынлыкта исә бу терминологик рәт тә дәүләтне түгел, ә хан ставкасын, чатыр / тирмәне белдерә булса кирәк. Нәкъ менә шул чатырның кырыйлары – иңгәләре, биек булган булырга тиеш. Әйтик, дастанның нугай версияләренең берсендә (русча гына сакланган), Джамбай Идегәйгә әйтә: Туктамыш ханга кил дә «припади к его ногам в его высоком (игътибар – Д. И.) белом шатре», – дип [Эдигэ: 2016. С. 56].

Хәзер безгә инде тарихи материалларга таянып тикшерелә торган мәсьәләгә ачыклыклар кертеп китү мөмкин. Ул эшне башкарганда үзебезнең бер хезмәткә (карагыз: [Исхаков: 2014] һәм А.К. Кушкумбаевның [2015; 2017-а; 2017-б; 2017-в]) элегрәк басылган хезмәтләренә таянып эш

итәрбез. Алга таба китерелгән фикерләрнең кайбер детальләрен, монда язылмаган очракта, шул мәкаләләрдән карарга кирәк.

### *Ак Урда төшенчәсе*

Тарихи чыганаклардан Җучи Олысындагы тәхет куелган үзәкнең, ягъни, хан ставкасының XIII-нче гасырда ак төстәге тирмә/чатыр булганлыгы турында мәгълүмат сакланган. Әйтик, Абуали Шафи б Мөхәммәт (Каһирә шәһәрендә 1329/30-нчы елны үлгән) үзенең елъязмаларында Берке ханнан Мисырга Бейбарс солтан янына килгән илчеләреннән ишеткәннәре турында яза: «Они разъяснили ему (солтанга – Д. И.) все, о каждой должности отдельно, равно как о том, что у него (Беркедә – Д. И.) войлочный шатер, в котором помещается 500 всадников и который внутри отделан жемчужинами и драгоценными камнями» [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 70]. Менә шушы бик зур «киез чатыр» (тирмә) турында аль-Муфаддаль исемле Мисыр елъязмачысы (информациясе 1259–1341-нче елларга карый) хезмәтендә Бейбарс илчелегенең Берке хан вакытында Җучи Олысына баруы турында язмада тулырак яза. Бу автор әйтә: «...царь Берке ... находился в большом шатре, в котором помещается 100 человек (башка вариантларда – «500 человек / всадников»), покрытом белым войлоком (менә ул Ак Урда! – Д. И.), внутри обитом шелковыми материами и китайками и украшенным жемчужинами и драгоценными камнями. Он (хан) сидел (там) на престоле...» [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 92–93, 97]. Бу чатырны Плано Карпини һәм Вильгельм Рубрук та күргәннәр. Беренче автор Бату ставкасында булганда «чатырларны» искә төшерә һәм әйтә: «... алар бик зур һәм матур иделәр, тукымадан эшләнеп, элек венгр короленыкы булганнар», – дип [Карпини Плано Джованни: 1997. С. 73]. Димәк, сүз бу очракта хәрби трофейлар турында бара. Шул ук чатырны Вильгельм Рубрук да тасвирлый: «...безне палатка уртасына кадәр керттеләр... [Анда Бату] озын, ятак кебек киң тәхет урынында тәхеттә утыра һәм ул бөтенләе белән алтынланган иде...» [Де Рубрук Вильгельм: 1997. С. 117]. Моннан аңлашыла – чатыр эчендә алтын белән капланган тәхет урыны (престол) да булган. Шуңа күрә дә без Ак Урдадан, әкренләп, Алтын Урдага күчә алабыз һәм ул күчешне гарәп сәяхәтчесе Ибн Баттута хезмәтенә таянып ясарга мөмкин.

### *Алтын Урда төшенчәсе*

Ибн Баттута, Җучи Олысында Үзбәк хан дәверендә булып, үзенең шәхси күзәтүләренә нигезләнеп, хан чатыры турында яза: «...Җомга көнне, намаздан соң» хан «алтын чатыр дип исемләнүче (димәк, бу – Алтын Урда – Д. И.), бизәлгән һәм хикмәтле чатырга кереп утыра». Чатыр «алтын белән капланган агач рәшәткәләрдән тора..., аның уртасында агач тәхет

урыны торып, ул алтын йөгертелгән (исегездәме югарыдагы «алтын ялатылган» дигән фраза дастаннан? – Д. И.) [иде]; аның аяклары көмештән, ә өске ягы кыйммәтле ташлар белән бизәлгән», – ди бу автор. Ибн Баттута дәвам итә: «Солтан (Үзбәк хан – Д. И.) шушы тәхеткә утыра». Алга таба ул, бик тәшвишләп, чатырда кемнең (ханның хатыннарының, балаларының, бәкләренең) кайсы урында утырганлыгын күрсәтә [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 132–133].

Шулай итеп, безнең каршыбызда Җучи Олысының чәчәк аткан дәверендәге сәяси үзәге – Алтын Урданың хан ставкасының, тасвирламасы килеп чыга. Әлеге бу зур чатыр Урда күчеп йөри торган урыннарда кулланылган, ә кыш көннәрендә исә ханнар һәм аның бәкләре далада түгел, ә башкала төзелгәч Сарай шәһәрендә яшәгәннәр. Аларның яшәгән бикалары турында язганда (үз күзләре белән күреп!), Ибн Баттута солтанның (Үзбәк ханның) андагы сарае турында да мәгълүмат бирә – аның исеме «Алтынташ» булганлыгын әйтеп, гарәп сәяхәтчесе атаманың беренче өлешен алтын белән бәйли, ә икенче кисәген – «таш» төшенчәсен, «баш» дип тәрҗемә итә [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 143]. «Идегәй» дастанының татар версиясендә дә Сарай (шәһәр булса кирәк) белән бергә «Сары мәрмәр Алтын Таш» шулай ук искә алына [Идегәй: 1988. 166 б.]. Ләкин бу урынны дөрес аңлау өчен безгә әл-Омари хезмәтенә мөрәҗәгать итү кирәк. Ибн Фадлаллах әл-Омари (1348/49-нчы елны үлгән) үзенең тарихи-географик хезмәтендә Сарай шәһәрендә «патша һәм аның якыннарының» кыш көне яши торган «зур сарае» булуын күрсәтеп, ул урынның «стеналар, башня һәм әмирләрнең өйләре белән әйләндереп алынганлыгын» да әйтә һәм хан сараеның авырлыгы «ике мисыр кантыры» булган «алтын ярымай» белән төгәлләнгәнлеген күрсәтә [Золотая Орда в источниках: 2003. Т. 1. С. 109]. Шуңа күрә, бәлки, сарайның исеме «Алтынбаш» булгандыр, ягъни, мәгънәсе ягыннан «златоглавый/алтынбашлы» килеп чыгарга мөмкин. Менә шушы алтын белән бәйле сарайны А.К. Кушкумбаев Җучи Олысы хөкемдарларының официаль резиденцияләренең кышкы (стационар) варианты итеп карарга тәкъдим итә [Кушкумбаев: 2015. С. 40]. Без бу фикер белән тулысынча килешәбез.

Тикшерелә торган «Алтын Урда» исемле чатыр, чынлап та булган һәм бер тарихи чыганактан без аның кайчан юкка чыкканын да беләалабыз. Ул турыда Үтәмеш-хаҗиның «Чыңгыз-намә» исемле әсәрендә түбәндәге мәгълүмат китерелә. Үзбәк ханның хатыны Тай-Дула бегим, хан үлгәннән соң, Хызырны чакырып китереп аны хан иткәч, «туй бүләге итеп ... Үзбәк ханнан һәм Җанибәк ханнан калган алтын юртаны куйган». Ләкин, Хызыр хан аны хатынлыкка алудан баш тарткач, Тай-Дула бегим аңа каршы хәрәкәт итә башлый. Шул вакытта ачуы

чыккан хан «алтын юртаны ватып, аның алтынын үзенең казаклары арасында бүлергә уйлый». Бегим шунда хан янына кеше җибәреп, әйтә: «...Алай эшләмәсеннәр. Алтын белән көмеш булмаганда хан булган кеше өчен бу [алтын юрта] – байлык. Башка яхшы кешеләр тарафыннан төзелгән бинаны җимермәсеннәр», – дип. Ләкин Хызыр хан аның сүзләрен тыңламый һәм ул юртаны «ватып аны бүлә» [Утемиш-хаджи: 1992. С. 112].

Шулай итеп Җучи Олысының сәяси үзәге булган «Алтын Урда» / «Алтын юрта» юкка чыга. Бәлки бу чыганактагы мәгълүмат аллегорик мәгънәгә иядер, ягъни, Алтын Урданың таркала башлаганлыгын белдерүче бер билгедер, әмма, шулай булса да, монда тарихи факт та чагыла төсле– «Алтын юрта» чынлап та ватыла, ахрысы.

### *Бүз Урда төшенчәсе*

Шушы төшенчәнең мәгънәсен тикшергәндә, Үтәмеш-хаҗиның «Чыңгыз-намә» исемле хезмәтендәге бер урынга игътибар итәргә кирәк (ул турыда казакъ тарихчысы А.К. Кушкумбаев язган идее, карагыз: [Кушкумбаев: 2017-а]). Бу әсәрнең авторы Шибан, Туктамыш, Тимур-Кутлуг һәм Урус ханнарның варисларының үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлаганда – ә сүз аларның кайсысының даладагы социаль иерархияда югарырак, кайсысының түбәнрәк булуы турында бара – мондый бер тарихи легенда китерә.

Имеш, Чыңгызхан Җучиның улларына юрталар куеп, киңәш (корунш, корылтай) үткәрә һәм анда Җучи Олысын бүлү мәсьәләсе карала. Шулвакытта Саин ханга (Батуга) уң канат бирелә (Идел һәм аның вилайәтләре), ә Эҗәнгә (Орда-Иченга) сул канат эләгә (Сыр елгасы һәм аның буендагы вилайәтләр). Шушы вакыйгалар барган вакытта, Чыңгызхан Җучиның уллары өчен мондый юрталар куйдыра: «Алтын босагалы ак өргәне Сайын ханга [Батуга] салды, күмүш босагалы кок орданы Эҗәнгә [Орда-Иченга] салды, болат босагалы боз орданы Шәйбанга салды» [Утемиш-хаджи: 1992. С. 92, 93, 121]. А.К. Кушкумбаевның фикере буенча, «өргә» дигән термин монголларда булган «урга» төшенчәсен белдереп, хөкем итүчеләрнең чатыр-ставкасын чагылдыра [Кушкумбаев: 2017-а. С. 356]. Шуңа күрә дә Батуга (Сайын ханга) бирелгән юртаның тулы атамасы «Алтын бусагалы ак урга / урда» булып чыга. Соңгы ике Чыңгызыйның юрталарын тасвирлаганда аларның исемнәрендә «урга» урынына инде «урда / орда» сүзе кулланыла. Игътибар итик, Шибанга бирелгән юртаның атамасы – «болат босагалы боз орда». Шулай итеп, монда «Боз Орда» төшенчәсе килеп чыга.

Билгеле, А.К. Кушкумбаев язганча – ә без аның белән тулысынча килешәбез – бу легендар хикәяттә Җучи улларына урдалар – юрталар

бирү символик булса да, алар аркылы Җучиның нәселе эчендәге иерархия билгеләнә: бусагасы алтын булган Ак Урда ханнары – Батуидлар – өлкәнрәк, ә бусагасы көмештән булган Күк Урда ханнары – Ордуидлар – түбәнрәк дәрәҗәле булып чыгалар. Шибанидларга исә булат бусагалы Бүз Урда ханнары буларак, тагы да түбәнрәк урын калдырыла. Димәк, дастандагы «Бүз Урда» төшенчәсе «Ак Урда» термины белән тәңгәлләштерелсә дә (моны «бүз» дигән сүзнең «ак, аксыл» дигән сүзгә мәгънәви яктан якынлыгын да күрсәтә; мәсәлән, «акбүз ат» – ул «аксыл төсле» атны аңлата), ул берникадәр дәрәҗәдә мөстәкыйль җисем буларак та карала ала. Әмма, төсләр чагыштырмасыннан чыгып карасаң, иң башта «Бүз Урда» халкы «Ак Урдага», ягъни Җучи Олысының уң канатына кергән, дип уйларга туры килә. Бу турыда бәхәсләр барса да, безнең элегрәк язган фикеребез шушы караштан чыгып әйтелде [Исхаков: 2009-б; 2013-б]. Кайбер башка галимнәр дә шундый ук карашны белдерделәр [Парунин: 2015]. Бу очракта Алтын Урда чоры шагыйре Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендәге Тинибәк ханның хатыны Мәликә ханбикәгә язылган багышлауын да (алга таба карагыз) истә тотарга кирәк [Котб: 2003. 36 б.].

Әгәр дә тарихи чыганаклардан чыгып эш итсәк, Батуидлар хөкем иткән Җучи Олысының көнбатыш өлеше – уң канаты – башта «Ак Урда» исемен алып (ә ул ак төстәге хан ставкасы – Ак чатыр / юрта / урда, атамасыннан), соңыннан «Алтын Урда» (алтын белән бизәлгән «Алтын чатыр / урда» атамасыннан) төшенчәсенә бәйле рәвештә карала башлый. Шуңа күрә дә «Идегәй» дастанында бу ике термин синонимнар буларак кулланыла. Ә менә «Бүз Урда» төшенчәсе без тикшергән эпоста искә алынса да, күбрәк «чатыр / юрта / ставка» мәгънәсенә ия. Бәлки, ул берникадәр дәрәҗәдә шактый иртә юкка чыккан (Үзбәк хан дәверендә яисә бераз соңрак) «Күк Урда» терминын алмаштыргандыр. Ул алмашу Җучи олысындагы XIV-нче йөзнең 60-нчы елларында башланган сәяси кризистан соң Күк Урда һәм Шибанидлар Олысы (Бүз Урда) ханнарының дәүләтнең уң канатына үтеп кереп, анда идарәгә килүләре белән дә бәйле булырга мөмкин.

Тулаем алганда, «Алтын Урда» атамасы Җучи Олысның чын исеме түгел, аның дөрес, официаль атамасы, 1393-нче елда язылган Туктамыш ханның хатында күренә – «Олуг Улыс». Нәкъ шул төшенчәне соңыннан рус документларында таралган дәүләтнең төп варисы булган һәм «Саин урынын» («Саинов стул»), ягъни Алтын Урданың ставкасын, саклаучы «Большая Орда» дип исемләнүче дәүләткә бирәләр дә.

Әмма, «Идегәй» дастанында «Ак Урда / Алтын Урда» терминнарының сәяси үзәк / хан ставкасы мәгънәсе ачык күренсә дә, аларның

дәүләти берләшмәне билгеләгән мәгънәсе дә чагыла. Әйтик, Котбның «Хөсрәү вә Ширин» исемле әсәрендә (ә ул Тинибәк б. Үзбәк ханга бүләк итү өчен язылган) шушы ханның хатыны Мәликәгә багышлауда дәүләт «Ак Урда» буларак атала [Парунин: 2015. С. 56; Котб: 2003. 39 б.]. Шуңа күрә дә без Иоганн Шильтбергердагы «Алтын Татария / Олуг (Бөек) Татария» терминнарының Җучи Олысына, ягъни дәүләткә карата кулланылганын күзәтә алабыз (карагыз: [Парунин: 2015. С. 55]). Моннан шундый нәтиҗә килеп чыга: «Алтын Урда» төшенчәсен Җучи Олысына карата куллану, әгәр дә аның килеп чыгышын дөрес итеп аңлатсаң, чынлыкта, мөмкин.

Шушы атама турында тарихи чыганакларда кызык кына мәгълүматлар да бар. Әйтик, Кытай чыганакларында Җучи Олысы «Цзинь жань хань» / «Ханство Золотой Юрты» дип исемләнгән [Кычанов: 2000. С. 157]. Үз чиратында, бу атаманың инде без карап үткән Үтәмеш-хаҗидагы «Алтын юрта» һәм «Алтун босагалы Ак өргә / урда» белән бәйләнгән булуы ачык. Әмма, Җучи Олысына кадәр «Олуг Алтын урда» (оригиналда – «Урду-и-заррин-и-бузург» / «Большая Золотая ставка») әле Чыңгызхан ставкасы буларак, 1224-нче елны ук Монгол империясендә билгеләп үтелә. Ахрысы, нәкъ шул сәяси үзәкне кытайлылар Пен Да-я һәм Сюй-Тин үзләренең «Хэй-да ши-лю» («Кара татарлар турында кыскача хәбәрләр») исемле хезмәтләрендә искә алалар: «... Алтын чатыр (тирмә) эчендә берничә йөз кеше сыя...». Аны Плано Карпини да күрә: «...был приготовлен ... шатер, называемый у них Золотой Ордой» (димәк, бу шул ук «Урду-и-заррин-и-бузург» – Д. И.) [Исхаков: 2014]. Шундый ук ставка (берсе җәйге, икенчесе – кышкы) Юань империясендә Хубилай каһан вакытында да булган һәм Марко Поло аның тасвирламасын калдырган [Поло Марко: 1998. С. 251, 261–263]. Ахыр чиктә, бу «Алтын Урда» дигән ставка кую традициясе бик ерак заманнарга барып тоташа – ул борынгы төрки каһанлыкларда да билгеле [Кушкумбаев: 2017-б; 2017-в].

«Идегәй» дастанында кабатлана торган «алтыннан суккан урда» [Идегәй: 1988. 85 б.; Эдигэ: 2016. С. 84], «босагасы алтын сарай», «босагасы болаттан, болатка алтын ялаткан» [Эдигэ: 2016. С. 246, 263, 289] дигән сүзләр татарлар һәм нугайлар арасында иске рухи традицияләрнең XIV–XV-нче йөзләрнең чикләрендә әле яшәгәнлеген күрсәтәләр. Ә кырым татарларындагы дастан версияләрендә Идегәйнең улы Нуретдинның Туктамыш ханга әйткән сүзләре моны тагы да ныгыта:

*Алтын Сарайны къурдургъан*
*Алтын босагъа аъойдырган –*
*Чыңгызмын, – ди бер Чыңгызый* [Къырымтатар: 1991. С. 46]

Шулай итеп, «Идегәй» дастанын ныклап өйрәнеп, анализлап карасаң, аннан милли тарихыбызны баета торган бик күп яңа мәгълүмат табарга була.

Алдагы язмабызда инде вәгъдә ителгән «Чура батыр» дастанына тукталырбыз һәм ул әсәр безне Алтын Урданың сәяси һәм мәдәни варислары булган татар ханлыкларының XVI-нчы йөзнең беренче яртысы тарихларына, ягъни, «Идегәй» дастаныннан бер гасыр чамасы соңрак булган дәвергә алып керер. Ул дәвернең исә үз проблемалары, аерым үзенчәлекләре булган һәм безгә аларны шушы дастан аркылы күрергә һәм аңларга мөмкинлек бар.

# IV-нче бүлек

## «Чура батыр» дастаны һәм «киләчәк буыннарны кисәтү»



*Алтын Урда сугышчысы.* Алибек Койлакаев.

*«Чора батыр» – телдән сөйләнүче эшкәртелгән дастан. Ул Үзәк Азиядәге миллилекнең (идентитетның) әһәмиятле якларын чагылдыра».*

*Хәсән Б. Паксой*

**§1. «Чура батыр» дастанын өйрәнү һәм аның кыскача эчтәлеге**

Кыпчак телле күп кенә төрки халыкларда (төрле төркем татарларда, башкортларда, нугайларда, каракалпакларда, казакъларда) сакланган «Чура (Чора~Шора) батыр» исемле эпик әсәр (кайбер халыкларда, мәсәлән, казакъларда, аның атасына багышланган аерым дастан да бар) төрки-татарлар тарихының әһәмиятле бер чорын яктырта – сүз Алтын Урданың сәяси варислары булган дәүләтләрнең бәйсезлекләрен югалта башлаган дәвер турында бара.

Шушы заманнарда (исегезгә төшерәм, XVI-нчы гасыр урта гасырларның соңгы йөзьеллыгы булган, чөнки Яңа вакыт XVII-нче гасырдан башлана) татарлар руслар белән бик нык конфронтацияга кергәннәр. Бу дәвер турында без күбесенчә рус чыганакларыннан гына беләбез, чөнки татар җәмгыятьләрендә тудырылган тарихи чыганаклар аз сакланган (Кырым ханлыгы буенча күбрәк), шуның өстенә озак еллар буенча Россиядә официаль тарихчылар аларны, беренче чиратта, яулап алучылар белән татарлар арасында булган каршылыклар турындагыларын, инкарь итеп килделәр. Аеруча бу идеологик мәсьәләләрне яктырткан чыганакларга карый. Шуңа күрә дә XVI-нчы йөздән сакланган эпик әсәрләрнең әһәмияте бик зур. Бу әсәрләр яулап алу эшенә керешүчеләр тарафыннан «санкцияләнмәгән» [Paksoy: 1986. P. 253] булу сәбәпле, аларда шул дәвер бабаларыбызның дөньяга аутентик, чын карашлары сакланып калган. АКШта яшәп иҗат иткән күренекле төрек тарихчысы һәм фольклорчысы Хәсән Б. Паксой язганча, тикшерә торган дәвергә караган «Чура батыр» дастанында, башка проблемалар белән бергә, «киләчәк буыннарны кисәтү» дә сакланган [Шунда ук]. Нәрсә турында кисәтә соң безне ул дастан? Бу кисәтүнең асылын аңлау өчен безгә шушы эпос аркылы XVI-нчы йөз татар җәмгыятьләренең үзенчәлекләрен, гомуми яшәү контекстларын өйрәнү кирәк булачак. Шулвакытта рус чыганакларының тарихи процессны берьяклы гына яктыртулары ачылыр һәм бабаларыбыз яшәгән XVI-нчы йөз тарихы белән бүгенге буыннарны бер тарихи агымга тоташтыруның дастаннарда сакланган мәгълүматлардан, татарларның дөньяга, тарихи вакыйгаларга үз карашларыннан башка мөмкин түгеллеге күренер. «Чура батыр» дастаны моның өчен җирлекне җитәрлек итеп бирә.

Без тикшерә торган дастан фольклорчылар тарафыннан, шул исәптән, Татарстанда да (карагыз: [Урманче: 1995–1996; Ибраһимова:

2002]), шактый өйрәнелде. Әйтик, Л.Х. Ибраһимова хезмәтендә «Чура батыр» эпосының милли версияләрен барлау һәм аларны тикшерү тарихы да бирелгән. Казакъстанда да шундый хезмәт басылды [Қорғанбеков: 2014]. Бу безгә аларда тикшерелгән мәсьәләләргә кермичә, турыдан-туры төп проблемага – дастан кысаларында сакланып калган халкыбыз тарихына, аның XVI-нчы гасырдагы кискен борылыш дәвере өчен хас булган татар менталитетына, ул дастанда хәрәкәт иткән батырларның тарихи прототипларына мөрәҗәгать итү мөмкинлеген бирә.

Иң башлап, өйрәнелә торган эпосның төп сюжет линиясен карап чыгып, аның героеның кемлеге мәсьәләләренә тукталып китик.

Татарларда язып алынган дастан версияләреннән (карагыз: [Татар халык иҗаты: 1984. 108–119 бб.; Татар эпосы: 2004. 386–398 бб.; Къырымтатар: 1991. 57–72 бб.]) эпосның түбәндәге эчтәлекле булуы күренә.

«Дагстан йортыннан» булган Казый би атлы бер «олуг мирза» күчеп йөргән вакытта бер ир бала табып ала, аңа Наррәң / Нарәң (нар рәңле – кызыл битле, ут төсле) дип исем бирә һәм ул бала шушы би янында тәрбияләнеп, үсеп җитә. Казый би аны Миңсылу исемле «Кабак башы Кара үздән» исемле кешенең кызына өйләндерә. Соңыннан Казый бинең энесе Канмирза Миңсылуга гашыйк булып, Нарәң батыр аны, хатынына дәгъва кылган өчен, би янында кылыч белән чабып үтергәч, бу батыр хатынын алып качып китә һәм «Хаҗитархан шәһәренә, Акча солтанга килеп», шунда көн итә башлый. Ләкин бу солтанның да аның бик чибәр хатынына күзе төшә, шуннан Нарәң батыр аны да үтереп, тагы качып китә, шулвакытта юлда аның улы туа, аңа Чура дигән исем кушыла. Ахыр чиктә алар «Кырымга барып», шунда торалар. Кечкенә вакыттан ук Чура, балалар башына басып, «батыр» исеме йөртә, аның даны Кырымнан «Идел халкына» да барып җитә. Үскәч шунда китеп, Чура Колынчак атлы берәүнең кәләшен урлап, аның белән бергә кача, соңыннан алар кире кайтып, Колынчакның рөхсәте белән, никах кылалар, ә Чура Колынчакка үзенең кыз туганын хатынлыкка бирергә вәгъдә итеп, алар хатыны белән Кырымга кайтып китәләр.

Чура батыр «Идел тарафында» йөргәндә, Кырымдагы Акташтан Гали (Али) бәк атлы берәү Нарәң батырны талап, кыйнап, Миңсылуга «яман сүзләр» әйтеп, китеп бара. Чура батыр кайткач, атасы аңа бу турыда сөйли, моны тыңлаганнан соң батыр Гали бине башын кисеп үтерә, әмма, нәтиҗәдә, аңа читкә китәргә туры килә – «шул киткәндә Чура батыр Казан шәһәренә барды», диелә эпоста. Ул анда килгәндә Колынчак батыр да шунда икән, башка батырлар арасына кергән Чура алар белән бергә Ка-

зан шәһәрен алырга тырышкан рус гаскәре белән сугышларда катнаша. Ә Кырымда ул вакытта үтерелгән Гали бәкнең кардәшләре, Нарәң батырдан үч алып, аның бөтен байлыгын тартып алалар, ул хатыны Миңсылу белән бөлгенлеккә төшә.

Русларны исә Казанда үзләренә нык каршылык күрсәткән Чура батыр борчый, алар хәтта астрологларын (*мөнәҗҗимнәрен*) җыеп, азтырләб (астрономия приборы астролябия) аркылы карап, белергә уйлыйлар – ничек Чура батырның әҗәле килүе мөмкин икәнлеген. Ысул табыла: Чура батырның әҗәле бер кыздан икән. Шуңа күрә руслар матур киенгән кызны сайлап алып, аңа җибәрәләр, ул аннан йөкле булгач, качып кире кайтырга тиеш була. Ул шулай эшли дә, кайткач исә бу хатын бер ир бала таба. Аны руслар үзләрендә тәрбияләп үстерәләр һәм Чура батырның улы рус гаскәрендә хезмәт итә башлый.

Ул заманда Кырымда калган Нарәң батыр ярлылыкка түзә алмый Казандагы улы Чура янына килә, бик хәерче кыяфәттә булгач, Чура аны башта танымаган булып тора, аннан соң, аны төрле хәйләләр белән, үзе хезмәт иткән гаскәр белән таныштыра. Нарәң турында сүз Шаһали ханга барып ирешә. Хан исә Нарәңне үз янына алдырып, хөрмәт итеп, аңа бүләкләр бирә, бу батырны үзендә тота.

Ул арада Шаһали кызы Сарыкани батырларга, һәрберсенең дәрәҗәсенә күрә, бүләкләр өләшә. Чура батырга фәкать тик бер «алтын котык», ягъни шкатулка / тартма гына эләгә. Мондый аз бүләккә үпкәләгән Чура аны ташлап, сугышка бармас була. Соңыннан Сарыкани аның янына барып, әйтте: «Шул котыкны ачып карачы», – дип. Чура, аны ачса, анда «Күк чыбык» атлы бик яхшы кылыч күрә һәм, кызны гафу итеп, гаскәр белән килгән яуларга каршы сугыша. Ә Шаһали хан аның атасына күп мал, хәзинә биреп, аны кире Кырымга кайтара, анда исә Нарәң батыр зур туй, мәҗлес үткәрә.

Шул вакытларда Чура батыр Колынчакка мең куй, ат биреп, Кырымга барып, ата-анасының хәлләрен белеп, үзенең кыз карендәше Айсылуны да күрерсең, дип, аңа Кырымга юл тотарга кирәклеген әйтә һәм тегесе шунда чыгып китә. Ул Кырымга барып Чура батырның өенә килсә, батырның анда калган хатыны бер егет белән кочаклашып ята икән. Күргәннәрен Колынчак Чурага кайтып сөйләгәч, моңа түзә алмаган батыр Кырымга юнәлә һәм хатынын үтерергә уйлый. Әмма, каршысына чыккан карендәше Айсылу аңа әйтә: «Ул егет түгел иде, ә мин идем, без аны бер хәйлә ясап сине Кырымга китерү өчен эшләдек, – ди. Чура моннан соң өендә бер кич кунып, хатыны мине үзең белән ал дип әйтсә дә, аны калдырып, кире Казанга кайтып китә.

Чура батыр шәһәргә кайтып җитсә, бөтен халык каядыр качып бара. Чураның соравына, аңа аңлаталар: «Казан шәһәрен яу алды, аның өчен качып барамыз», – дип. Шунда Чура мондый җырны башкара:

*Мин Чурамын, Чурамын,*
*Түрә түгел, карамын,*
*Асылымны сорасаң, –*
*Күкес углы Тамамән* [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б.].

Аннан соң ул, «Казанга килеп», дошманны җиңә, ул турыда ишетеп, аның янына Шаһали хан һәм Сарыкани киләләр. Алга таба рус гаскәре тагы да яу беләнябырыла һәм бу юлы анда Чура батырның инде үсеп җиткән улы да була, шуңа күрә Казан гаскәре Мәскәү гаскәрен җиңә алмый. Бу сугышны күзәткән Сарыкани Чураны үз янына чакырта: «Сусагансың, килеп су эчеп кит», – дип әйтә ул. Чура аңа җавап итеп, каһәрләнеп әйтә:

*Шаһали ханның йорты өчен,*
*Сарыканиның күңеле өчен*
*Күк чобарым арытмай,*
*«Күк чыбыгым» кара канга җебетмәй,*
*Бу гавернең кереш күзле малаен*
*Иңрә-иңен ана Иделгә колатмай,*
*Бу гавер менә серен чыктырмай,*
*Ак мәсҗедләр салдырмай,*
*«Аллаһ»лап азан әйттермәй,*
*Морадыма җиткермәй*
*Кайтмам да, кайтмам да,– дип* [Шунда ук. 119 б.].

Шушы сүзләрне әйткәннән соң, Чура батыр тагы гаскәр эченә чума, анда нык сугыша, ләкин үз улын үтерә алмый азаплана. Аның бу бик каты булган сугышта атының аягы kыза һәм ул туктый алмый, ат, хуҗасы белән бергә, Иделгә сикерә, шунда Чура батыр «суга китеп», үлә. Үлеп барган Чура җырлап [Шунда ук]:

*Казан алды катлау-катлау кара су,*
*Камышлап төшеп идем сай да, дип.*
*Тирән дә юк, сай да юк,*
*Индегедән арбаган [уңыш, бәхет] бездәй ирләргә*
*Казан атлы сар [шәһәр] да юк,*–дигән сүзләрне әйтә һәм үлә.

Чураның үлеме турындагы эпизод буенча, дастанның татарларда телдән язып алынган бер вариантында мондый өстәмә бар: аның атының аягын дошман ягында сугышкан улы яралый, нәкъ шуннан соң Чура

Иделгә егылып төшә дә [Татар эпосы: 2004. 398 б]. Кырым татарлары арасында язып алынган дастан версиясендә исә атасы белән улы берсен-берсе куышып барганда, икесе дә суга төшеп китеп үләләр [Къырымтатар: 1991. 72 б.]. Суга төшеп үләр алдыннан улын җиңә алмаган Чура батыр, эпосның бу версиясендә әйтә:

*Алай да достлар, алай да,*
*Алдангъанман малайгъа.*
*Къатип отсин къылычым.*
*Озюмден тувгъан балайгъа, – дип* [Шунда ук].

Башка халыкларның милли версияләрендә дә Чураның үлеме турында шундый ук мәгълүмат бар. Мәсәлән, нугайларда язып алынган «Шора бaьтир» дастанында әйтелә: «Соннан сонъ Казан уьстине яв келеди. Бу согыста Шора баьтир йигитлерше согысып Карагер аты ман Эдил сувына батып оьледи», – дип [Ногай: 1969. 79 б.]. Ә менә казакъларда сакланган «Шора» дастанында аның үлеме башкача сурәтләнә – калмыклар белән каты сугыштан соң, Шора белән булган Колынчакның көнчыгыштан килеп чыккан бер аждаһа (айдаһар) еланга корал белән кизәнүе аркасында, Шора юкка чыга, аны убылып киткән җир йота. Чынлыкта, бу елан Шораның әрвахы булган икән, – дип белдерелә дастанда [Батырлар жыры: 1989. 368–369 бб.].

**§ 2. Кем ул Чора (Шора) ~ Чура батыр?**

Башка тарихи эпослардагы төсле үк, дастанның төп герое булган Чура батырның да реаль прототибы бар. Аның кемлеге мәсьәләсен Татарстанда иң элек без (карагыз: [Исхаков, 1994; 1997; 2002; 2022], аннан соң башка галимнәр дә тикшерде [Урманче: 1995–1996; Ибраһимова, 2002; Мухаметзянова: 2022; Қорғанбеков: 2014]. Нәтиҗәдә, хәзер тарихи Чураның кем булганлыгы шактый яхшы өйрәнелгән. Ләкин ул өйрәнү берьяклырак барды һәм бара, чөнки бу «батырның» XVI-нчы йөз төрки-татар дәүләтләрендә тоткан урынын аның нинди кабилә-ырудан икәнлеген төгәл билгеләмичә аңлап булмый. Бу турыда исә тәшвишләп фәкать тик без генә яздык.

Әйтергә кирәк, дастанның төрле вариантларын анализлаганда Чура батырның кабилә-ыруын гына түгел, ә шактый озын шәҗәрәсен дә чамалап була. Шул мәгълүматлардан чыгып, аның Алтын Урданың сәяси варислары булган татар дәүләтләренең социаль-сәяси структураларындагы урынын да ачыклау мөмкин. Бу исә феодаль җәмгыятьләр өчен бик әһәмиятле, чөнки аларда кешенең тоткан урыны аның нинди социаль катламнан, нинди кабилә-ырудан, нәселдән булуы белән бәйле булган. Шуннан инде «Чура батыр» дастаны героеның тормышы күпкә яхшырак

аңлашыла башлый. Гомумән, ул яшәгән дәвердәге татарларның көнкүреше, уй-фикерләре яңача ачылып китә, без элегрәк аңлап җиткермәгән мәсьәләләргә башка җирлектән чыгып карау мөмкинлеге туа.

Эпик Чура батырны Казан ханлыгында XVI-нчы йөзнең беренче яртысында билгеле булган бер аксөяк татар – Чура Нарыков (рус чыганакларында фамилиясе шулай бирелә) белән тәңгәлләштерү соңгы вакытта әдәбиятта киң таралды [Урманче: 1995–1996; Исхаков: 1994; 1998; 2022; Ибраһимова: 2002; Қорғанбеков: 2014]. Ә бит әле күптән түгел генә Чура Нарыков турындагы мәгълүмат күбесенчә М.Г. Худяковның «Очерки истории Казанского ханства» (1923) исемле хезмәте кысаларында гына билгеле иде. Анда исә бу шәхес турында аның «талантлы дәүләт эшлеклесе» булуы гына билгеләнеп, Чура Нарыковның Казандагы 1545–1546-нчы еллардагы тәхет өчен көрәштә катнашуы белән чикләнде бу автор [Худяков: 1990. С. 102–104, 110]. Ләкин мондагы информация нигезендә ул аксөякнең кем булганлыгын, ни өчен аңа аерым дастан багышланганлыгын аңлап булмый. Казан ханлыгы тарихы буенча соңрак вакытларда чыккан хезмәтләрдә дә ул турыда ачык кына язылмый [Алишев: 1990. С. 53; 1995. С. 81–847; Бахтин: 1998. С. 92–93; История татар: 2014. Т. IV. С. 320–321]. Фольклорчылар да үз хезмәтләрендә Чура Нарыков турында күбрәк шушы тарихчылар китергән шактый чикләнгән мәгълүматларны гына кулланып килделәр һәм киләләр [Урманче: 1995–1996; Ибраһимова: 2002; Қорғанбеков: 2014]. Чынлыкта исә Чура Нарыков турында тарихи чыганакларда мәгълүмат шактый, ләкин ул информация систематик рәвештә өйрәнүне таләп итә. Аннан соң, «Чура батыр» дастаны эчендә дә бик әһәмиятле тарихи мәгълүмат бар, әмма аны эзләп табу һәм аңлату өчен татар ханлыклары турында концептуаль фикерләү дә, чагыштырма материаллар да кирәк, алардан башка бу үзенчәлекле чыганактан әллә ни алып булмый. Дөресен әйткәндә, Чура батырның кемлеген аңлау өчен тарихи рус һәм шәркый чыганакларны барлап чыгып, алар нигезендә шушы шәхескә багышланган дастанда сакланган информацияне яңадан тикшерү кирәк. Шул очракта гына без дастанның төп героеның чын йөзен ачыклап, ни өчен аның аерым дастанга лаек булганлыгын төшенә алачакбыз.

Бөек Мәскәү кенәзлеге эчендә барлыкка килгән тарихи чыганаклардан башласак дөрес булыр, чөнки нәкъ менә алар эпик Чура батырның прототибы булган Чура Нарыковның Казан ханлыгында яшәү дәвере турында кайбер әһәмиятле мәгълүмат биреп, аның үлү елын, дәүләт сәясәтендә катнашуының төгәл даталарын билгеләп, бу шәхеснең тормышын конкрет хронологик кысаларга кертеп карау мөмкинлеген тудыралар.

Чура исеме рус чыганакларында беренче мәртәбә 1526-нчы елны күренә – шушы елның март аенда Мәскәүгә Казаннан өч кешелек илче-

лек килеп, анда «кенәз» дип күрсәтелгән ике шәхеснең берсенең исеме «Чура» дип атала [ПСРЛ: 1965. Т. 13. С. 45]. Бу вакыйга алдыннан Казан ханлыгында зур сәяси үзгәрешләр күзәтелә: 1519-нчы елның мартында Казанга 13 яшьлек Шаһали Касыймнан китерелеп (бу кандидатура Мәскәү белән килешенгән була), тәхеткә утыртыла. Ләкин ул Казан аксөякләренә тиз арада охшамый башлый һәм алар теләге буенча, 1521-нче елны ханлыкның тәхетенә Кырымнан Гәрәйләр нәселеннән булган Сахиб-Гәрәйне күтәрәләр. Тәхеттәге үзгәрешләр вакытында Шаһали тарафдарлары һәм аның янында булган рус отряды бик нык зыян күрә, ә яшь хан 300 кешелек исән калган яраннары белән Мәскәүгә качып китә. Әмма, яңа хан да Казан тәхетендә озак утырмый – 1524-нче елның язында ул Кырымнан үзенең туганы Сафа-Гәрәйне чакыртып алып, Истамбулга китеп бара һәм аннан кире кайтмый (1532-нче елны ул аннан төрек солтаны карары белән Кырымга хан итеп җибәрелә).

Шулай итеп, әле бик яшь булган (13 яшендә) Сафа-Гәрәй Казан ханлыгында хөкем итә башлый, русларга исә аның монда калуы бер дә охшамый, алар 1524-нче елны ханлыкка каршы поход та ясап карыйлар, ул уңышсыз тәмамлана һәм Бөек Мәскәү кенәзлеге Сафа-Гәрәйнең ханлык итү хокукын танырга мәҗбүр була. Менә шул турыда сөйләшүләр алып бару өчен килгән илчелек составында «Чюра князь» дә була [Худяков: 1990. С. 77–93]. Дөрес, исеменнән башка бу шәхес турында 1526-нчы елгы рус документлары башка мәгълүмат бирмиләр, шуңа күрә дә аның Чура Нарыков булуын бер гипотеза буларак кына расларга мөмкин. Әмма Чура батырның дастаннарда сакланган Кырым белән бәйлелеген (алга таба карагыз) искә алганда һәм «Чюра кенәзнең» 1526-нчы елны Кырым династиясе вәкиле булган Сафа-Гәрәй исеменнән килгән илчелек составында булуыннан чыгып караганда, ул безне кызыксындырган Чура Нарыков булган, дип уйларга мөмкинбез. Моның шулай булганлыгын раслаучы бер факт 1540-нчы елга карый. Шул ел астында рус елъязмаларының берсендә Кострома тирәләренә Казан ханлыгыннан килгән яу турында сөйләнә һәм әйтелә: «...приходили казаньские люди, Чюра Нарыков, а с ним было [8000] человек казанцев и черемисы и чуваши, а воевали многие Костромские места» [Шмидт: 1951. С. 288]. Дөрес, бу очракта да без барыбер 1526–1540-нчы еллар арасында бу шәхес турындагы информациядән хәбәрдар түгелбез. Шулай булса да, шушы затлы татар алга таба да Казан ханлыгында яшәгән, дип уйлыйбыз, ләкин озак вакыт ул рус чыганакларында бүтән искә алынмый тора. Икенче тапкыр югарыда китерелгән чыганакта, ягъни, 1512-нче елгы Хронографның дәвамында, Чура Нарыков 1545-нче елга караган рус җирләренә килгән яу турындагы язмада искә алына. Шушы елның кышында менә нәрсә була: «...приходили

на Володимирские места с казанскими людьми в головах [Амона / Аманак] князь казанской да Чюра [Нарико]в... А у Гороховца, у острогу, с казанскими людми травилися мужики гороховцы, да взяли у казанских людей голову их Аманака князя» [Шмидт: 1951. С. 290].

Өченче тапкыр Чюра (Чура) – аның Нарыков фамилиясен дә күрсәтеп – «Патриарх (Никон) елъязмасында» 1546-нчы елны искә алына – Казаннан шул елның 17 гыйнварында тәхеттән төшерелгән Сафа-Гәрәй урынына үзләренә хан итеп яңадан Шаһалине сорап килгән илчелек составында була ул. Бу очракта аның титулы күрсәтелми [ПСРЛ: 1965. Т. 13. С. 148]. Әмма, 1546-нчы елның 13 июнендә тәхеткә утыртылган Шаһали Казанда озак ханлык итә алмый – бер айдан соң казанлылар Сафа-Гәрәйне яңадан тәхеткә кайтаралар, Шаһали исә аз гына үлемнән калып, Мәскәү ягына кача. Шушы элек Касыйм ханы булган Шаһалинең качу эпизодына аерым игътибар итү кирәк, чөнки ул турыда бер рус чыганагында өстәмә мәгълүмат бар. Аңа килгәнче әйтеп китик: 1546-нчы елны казанлылар исеменнән Мәскәүгә килгән өч илче (Абеюрган сәййед, Кадыш кенәз һәм Чюра Нарыков) исеменә һәм «бөтен Казан җиренә» Иван IV тарафыннан җавап хаты җибәрелүен искә алсак, Чура Нарыковның Казан ханлыгының югары аксөякләре арасында булганлыгы ачык.

Хәзер тарихи Чура Нарыковның ничек һәлак булганлыгына тукталабыз, чөнки безне кызыксындырган чыганакта ул мәсьәләгә карата өстәмә информация бар. Башлап, «Патриарх (Никон) елъязмасындагы» 1547-нче елның 20 сентябрендә Мәскәүгә хезмәт итәргә килгән татарлар (алар арасында «Чюра Нарыковның энеләре» булганлыгы да күренә) турындагы мәгълүматка килик. Алар хәбәр иткәнчә, «царь (ягъни, Сафа-Гәрәй – Д. И.) в Казани побил Чюру-князя Нарыкова (игътибар, монда аның «кенәз» титулы ачык күренә), Баубека-князя, Кадыша-князя и иных многих» [ПСРЛ: 1965. Т. 13. С. 149]. Димәк, Чура Нарыков Сафа-Гәрәй яңадан тәхеткә кайткач үтерелә. Сәбәбе билгеле – ул Сафа-Гәрәй урынына Шаһалине Казан тәхетенә китереп утыртуда катнаша. Ә менә «Казанская история [Казанский летописец]» дип аталган чыганакта (аны озак еллар Казанда яшәгән билгесез рус авторы язган) мондый юллар бар: Казанга хан булып килгән Шаһали белән Чура Нарыков нык якыная һәм ул ханның хәле авырайгач, аңа качарга ярдәм итә, хәтта качып китүчеләрне Идел буена кадәр озатып куя. Шулвакыт ул ханга әйтә: «Аз царю, вместо тебе умру в Казани, и моя буди глава во твоея место главы. Ты же мною да избавлен буди и не забуди мене, егда будеши преже меня на Москве, пред самодержцем станеши, вспоманя мя ему и о себе». Күренә ки, Чура үзе дә Мәскәү ягына китәргә уйлый, ахрысы, ләкин бераз курка, ул бит Иван IV каршында казанлылар исеменнән элегрәк Шаһалине тәхеткә чакырып ант китергән булган. Шу-

лай да, Чура Нарыков, «Казанская история» авторы күрсәткәнчә, Шаһалигә үзен билгеле бер урында көтеп торырга кирәклеген искәртә һәм ун көннән соң байлыгы, гаиләсе, өй эчендәге хезмәткәрләре, 500 сугышчы колы, барысы 1000 чамасы сугышчылары белән хан артыннан чыгып китә, әмма тегесе аны билгеләнгән җирдә көтеп тормый. Казанлылар исә алар артыннан куа чыгып, бер урында Чура Нарыковның отряды белән бәрелешәләр, шулвакытта ул үзе, аның улы һәм бөтен «отрок»лары (сугышчы кабиләдәшләре булса кирәк) үтерелә, хатыннары һәм кол хатын-кызлары исә кире Казанга алып кителә [Казанская история: 1954. С. 80–82]. Әгәр дә Казан тәхетенә 1546-нчы елның 13 июнендә утыртылган Шаһалинең анда нәкъ бер ай утырганын истә тотсак, Чура Нарыковның үлеме шул елның июль урталарына туры килгәнлеге билгеле була.

Димәк, Чура (Чюра) Нарыков («Нарыкович») – затлы аксөяк татар, кенәз (би, бәк) статуслы тарихи шәхес, рус чыганаклары буенча Казан ханлыгында 1526–1546-нчы еллар арасында яшәп, ул андагы сәяси тормышта актив катнашкан кеше булган. Аның социаль статусы турында «Казанская история» тагы мондый мәгълүмат бирә: ул анда «большой князь», «волостель казанский», «храбрый воевода» дип тә атала (карагыз: [Казанская история: 1954. С. 80, 82]). Бу төшенчәләр барысы да эчтәлекле, алга таба ул турыда аерым тикшерү үткәрербез.

Хәзер инде төрки чыганакларга мөрәҗәгать итү кирәк булыр. Аларның иң эчтәлеклесе – «Чура батыр» дастаны, әмма Чура Нарыков турында башка төр чыганаклар да бар. Шуларның берсе – шәҗәрәләр. Алдан аларга мөрәҗәгать итәрбез, чөнки шәҗәрәләр аркылы Чура батырның нинди аксөяк нәсел белән бәйләнгән булуын чамаларга була. Чура батырның шәҗәрәләре Идел-Урал буенда сакланган. Алардан башка бу шәхеснең нәселе турындагы мәгълүматны тагы ике төркем шәҗәрәләр аркылы алып була: беренчесе – Кырым ханлыгындагы аргын кабиләсе бәйләренең шәҗәрәсе, икенчесе – нугайлардан язып алынган Чурага (Шорага) багышланган дастан эчендәге аның нәселенә караган берничә буынлы шәҗәрә. Чура (Шора) батырның нәселе турында кызыклы мәгълүмат казакъларда аңа һәм аның атасына багышланган эпик әсәрләр эчендә дә бар. Алар катлаулы структуралы һәм әлегә кадәр тулаем өйрәнелеп бетмәгән. Шулай да, ул әсәрләрдәге информацияне дә алга таба игътибарга алырга кирәк булачак.

Татарларда язып алынган Чура би шәҗәрәсенең берничә версиясе бар, әмма ахыр чиктә алар бер нигездә һәм бер үк төбәктә барлыкка килгәнгә охшый. Сүз Татарстандагы Зур Карауҗа, Кече Карауҗа һәм Кармыш авыллары (Яшел Үзән районы) турында бара (карагыз: [Әхмәтҗанов: 2011. Т. I. 33–34 бб.]). Шул авылларда язып алынган җирле тарих турындагы ле-

гендалар эчендә мондый информация бар: «...Караужаның атасы Кара би булган. [Ул] Казан ягында Каравай авылында ил тотып яшәгән. Аның улы Караужа, Кече Караужа урынына килеп, авыл корып утырган... Караужа ... өч улын чакырып ...: [укларыгыз] кая төшсә, шунда барып нигез корырсыз!» – дигән. ... Укларның берсе Каратмән авылы урынына килеп төшкән. Ул урынга Караужаның олы улы нигез корган. Аның исеме Кара Төмән икән. Икенче улының исеме Чура би... Аның угы хәзерге Зур Караужа авылындагы Чура би чокыры турысына килеп төшкән. Караужа Чура би исемле улы белән шул урынга нигез салган. Өченче улының угы Күлбәш авылы урынында бер күл башына төшкән, ул шул җиргә урнашкан. Караужа Иван Грозныйга каршы сугышта Казан ханына хыянәт итә... Аның кабере – Чура би чокыры дигән урында. Чура бинең улы Чура батыр була. Иван Грозный гаскәрләре Казанны алган вакытларда Чура батыр ... Караужа авылы җирләре өчен сугышып үлә» [Татар халык иҗаты: 1987. 160 б.].

Шушы ук легенданың тагы бер версиясендә Караужаның олы улының угы Җәке авылы урынына төшеп кадала, диелә. Анда да беренче чыганактагы төсле Чура батырның улы Ресмәт, аның улы Кадермәт, соңгысының улы Гыйззәтулла, дип бирелә [Әхмәтҗанов: 2011. Т. I. 109–110 бб.]. Әлегә бу легендар тарихның нечкәлекләренә кермичә, андагы шәҗәрәгә игътибар итик: Караби→Караужа→

1) ......

2) .....

3) Чура би → Чура батыр → Ресмәт → Кадермәт → Гыйззатулла һ.б. Бу шәҗәрәдәге Ресмәт (Рыстмөхәммәттән) башланган башка бер тулырак шәҗәрә дә бар һәм ул шул ук төбәк белән (Мәмдәл, Иябаш, Яңа Кенәр авыллары) бәйле [Әхмәтҗанов: 1995. 91–97 бб.]. М.И. Әхмәтҗанов бу шәҗәрәләрне тикшергәндә аларның тагы бер версиясенең Р. Фәхреддиннең «Асар» китабында булганлыгын да күрсәтә (Эстәрлетамак шәһәрендә 1858- нче елда вафат булган шәхестән калган ул версия). Менә бу шәҗәрәнең өске өлеше: Караужа би → Кармыш би → Карлыгач би → Мәрҗән бабай→ Рысай бабай һ.б. [Әхмәтҗанов: 2011. Т. I. 111 б.]. Ахрысы, бу шәҗәрә югарыда әйтелгән, әмма исемнәре аталмаган Караужаның ике өлкәнрәк улларының берсенеке һәм аның исеме Кармыш би булган булырга тиеш. Татарстанның көнчыгышында яшәгән (Ык тамагындагы Бикбау авылы белән бәйле булган алар), ләкин соңыннан хәзерге Башкортостанның төрле урыннарында яшәгән татарлар белән бәйле бу шәҗәрә түбәндәгечә: Күкәс → Нәрек → Чура → Уразбакты → Үзи → Кайбиш һ.б. [Әхмәтҗанов: 2002. 323–324 бб.].

Шулай итеп, Идел-Урал буе татарларында сакланган Чура батыр дастанының төп герое булган Чура Нарыковның һәм аның белән бәйле

башка шәхесләрнең безнең алда берничә версияле шәҗәрәсе барлыкка килә. Аның төп тамыры уртак булса да, аларда аермалыклар да бар (түбәндә карагыз):

Кара би → Карауҗа → Чура би → Чура батыр ...

... Күкәс → Нәрек → Чура → Уразбакты...

... → Карауҗа → Кармыш би → Карлыгач би ...

Күрсәтелгән шәҗәрәләрдәге мәгълүматларның асылына төшенү өчен безгә Чура батырның башка төбәкләрдә һәм бүтән милли версияләрдә сакланган шәҗәрәләрен дә карап үтү кирәк булыр.

Башта кырым татарларыннан язып алынган «Чорабатыр» дастаны эчендәге бер шәҗәрәгә игътибар итик. Менә ул: «...Чоранынъ бабасы Нарик, Нарикнинъ агъасы Арик...» [Къырымтатар: 1991. 57 б.]. Ул дастаннан күренгәнчә, кайбер очракларда Нарикка да «Чора» дип эндәшкәннәр [Шунда ук: 58 б.]. Бу исә татар ханлыкларында «чура» дигән төшенчәнең «кол»дан башка тагы бер мәгънәсе дә булганлыгы белән бәйле – аның икенче мәгънәсе «югары дәрәҗәле йомышлы хезмәтче, хан вассалы» [Валиханов: 1984. Т. 1. С. 284–285; Усманов: 1972. С. 94]. Шулай ук дастанны укыган вакытта Чораның (Чураның) шушы Нарикның улы икәнлеге бик ачык күренә [Къырымтатар: 1991. 61, 66–67 бб.]. Чора дастанда үзе дә әйтә:

*Атамнынъ адыны сорасанъ,*
*Нарик огълу Чораман, – дип* [Шунда ук: 69 б.].

Димәк, безгә кырым татарлары арасында язып алынган дастаннан Чора батырның Нарик улы икәнлеге билгеле була, ә Нарикның Арик атлы агасы булганлыгы ачыла. Бу мәгълүмат Кырым ханлыгында яшәгән бер төркем аксөякләрнең шәҗәрәләренә игътибарны юнәлтергә кирәклеген күрсәтә. Сүз Кырым ханлыгындагы дүрт карача бәкләр нәселенең берсе булган аргын кабиләсе бәкләрнең шәҗәрәсе турында бара [Лашков: 1895. С. 129].

Менә ул шәҗәрә: Кара Коджа бәк → Адил бәк ...

→ Али-Шукур бәк →

→ Аджи-Ямгурчы бәк (1551) → Джан-Мәмбәт бәк ...

→ Кара бәй (1585) → Тоган мирза

→ Батырша бәк (1682).

Монда турыдан-туры дастандагы Чора б. Нәрик белән бәйлелек күренмәсә дә, Идел-Урал буенда язып алынган Чура батыр шәҗәрәләрендә булган информация нигезендә Кырымдагы аргыннарның нәсел башы итеп күрсәтелгән «Кара Коджа» бәкнең Чура батыр шәҗәрәсендәге Карауҗа би белән бер үк шәхес икәнлеген чамаларга була.

Өйрәнелә торган мәсьәләне нугайлар һәм казакълар арасында язып алынган дастаннар нигезендә тагы да тикшерсәк, бу нәтиҗә ныграк нигезләнгән булачак.

Әйтик, нугайларның «Шора бьтир» дастанында аның герое үзенең кем икәнлеге турындагы сорауга мондый җавап бирә (җавапның икенче өлешен китерәбез, кабилә-ыруга нисбәтле алдагы өлешен соңрак тикшерербез):

*Аргы атамды сорасанъ*
*Астын улы Байгазы,*
*Онынъ улы эр Тоьлек,*
*Нарик улы Шораман, – дип белдерә Шора* [Ногай халк: 1969. 77 б.].

Беренчедән, монда Чураның (Шораның) Нарик улы икәнлеге раслана, икенчедән, аның шәҗәрәсе шактый озыная һәм XV-нче гасыр башларына барып җитә: Шора ← Нарик ← эр Тоьлек ← Байгазы ← Астын. Дөрес, Нарикның Төлек улы булуын мантыйк нигезендә генә торгызып була, шигъри юлларда ул туп-туры күрсәтелми. Әмма, моның шулай булуын Добруджа (Буджак) татарлары арасында сакланган Чура батыр турындагы дастаннан ачык күреп була. Анда әйтелә:

*Арыслан улы Байгазы,*
*Аның улы Ир-Түләк,*
*Аның улы Ир-Нарык*
*Чура улы Чурамын, – дип* [Чура Батыр: 1993. 39, 54–55 бб.]

Күренә ки, монда «чура» атамасы Ир-Нарыкка карата кулланыла, ләкин Чураның аның угълы икәнлеге дә күп тапкыр раслана [Шунда ук: 22, 27, 33, 38–39, 43, 53 бб.].

Алга таба казакъларда язып алынган дастан версияләре эчендә булган шәҗәрә вариантларын да карап китик. Әйтик, «Шора» дастанында, «Нәрік Шорага Акташның бие өстенә» яу белән барырга тәкъдим иткәндә, атасы Нәріккә әйтә: «Ата сіз», – дип [Батырлар жыры: 1989. Т. 5. 386 б.]. Шул ук эпизодта, атасы улына болай ди:

*Айналайын, Шоражан,*
*Туған балам сен болсаң,*
*Алпыс биді өлтеріп*
*Кесіп басын алып кел* [Шунда ук: 339 б.]

Һичшиксез, бу сүзләрдән һәм эпосның башка җирләреннән [Шунда ук: 340–341, 342, 350–351 бб.] Чураның (Шораның) Нәрик (Нарык) угълы икәнлеге күренә, бигрәк тә дастандагы мондый юллардан:

....................................
*Сонда Шора сөйледі*
*Менің елім сурасаң,*
*Ноғайлы деген ел деді,*
*Әкем атын сұрасаң,*
*Нәрік деген хан деді.*
*Өз атымды сұрасаң,*
*Шора батыр мен деді* [Шунда ук: 348 б.].

Ләкин, казакъ дастаннарындагы Чура (Шора) батырның шәҗәрәсенә бәйле мәгълүмат чынлыкта катлаулырак. Шуңа күрә ул информациянең башка якларын да барламыйча булмый. Беренче чиратта бу мәгълүмат аның кабилә-ыру бүленешенә кагылышлы өлешенә карый. Ул турыда «Нәрік» дастанындагы Шораның «Син кем?» дигән сорауга җавап итеп әйтелгән мондый юллар сөйли:

*Асылымды сұрасаң,*
*Асылым артык арғынмын.*
*Тегімді менің сұрасаң,*
*Кок Нарлы танамын,*
*Өз атымды сұрасаң,*
*Нәрікулы Шорамын* [Шунда ук. 328 б.].

«Шора» дастанында исә аның герое, инде күрсәтелгәнчә, үзе турында әйтә:

*– Менің елім сұрасаң,*
*Ноғайлы деген ел деді.*
*Әкем атын сұрасаң,*
*Нәрік деген хан деді.*
*Өз атымды сұрасаң,*
*Шора батыр мен деді* [Шунда ук: 348 б.].

Ләкин, Шора калмыклар башында торган Мусахан белән очрашканда, тегесе аннан: «Кай ногайсың син?» – дип сорагач, аңа мондый җавап бирә:

*– Ногайлының ішінде*
*Асылым артыі арғынмын.*
*Бергі атамды сұрасаң,*
*Көк нарлы танамын,*
*Атам аты қарт Нәрік,*
*Мен сонда туған Шорамын, – дип* [Шунда ук: 366 б.].

Димәк, казакълар арасында таралган Чура (Шора) батырга багышланган дастаннар циклында (алар өчәү) аның кабилә-ыру бүленешенә мөнәсәбәте дә чагыла. Ләкин бу мәсьәлә буенча казакълардагы һәм башка төркиләрдәге эпос вариантларында чагылган мәгълүматта каршылыклар бар.

Беренчедән, казакъларда таралган «Тана» дастанында (анда Нәрікнең бабалары турында сөйләнә) шул исемдәге хан дәрәҗәсендәге шәхеснең «ногайлы баласы» буларак Казанда яшәгәнлеге, аны саклауда катнашканлыгы турында сөйләнә дә, аның Баба Тукті Шашты Әзиз (ягъни, Әхмәт Ясәви) ярдәме белән баласы туып, ул балага «хан Нәрік» аты кушылу турында әйтелә [Шунда ук: 294–297 бб.]. Чынлап та, Тама кабиләсенең (тана~тама булса кирәк) шәҗәрәсендә Нәрыкның атасы Кара-бура, аның атасы Тама дип бирелә [Тынышпаев: 1925. С. 75]. Ә Чора Нарыков, М. Тынышпаев күрсәткәнчә, «күп тама кабиләдәшләренең бабасы» булып саналган [Шунда ук: 47 б.]. Мондый караш Казакъстан гуманитар фәнендә элек тә бар иде [Валиханов: 1984. Т. 1. С. 109], хәзер дә яшәп килә (карагыз: [Корғанбеков: 2014. 179–180, 214 бб.]). Казакъстан фольклорчылары йогынтысы аркылы бу фикер татар фольклорчылары эшләренә дә үтеп керде [Урманче: 1995. 133–134 бб.]. Чынлыкта, эш монда казакълар арасында таралган Чора (Шора) батырга кагылышлы дастаннардагы аның «тамалы» булуы турындагы мәгълүматта гына түгел, чөнки шуңа якын информация бу дастанның башка милли версияләрендә дә бар. Әйтик, нугайларның «Шора баьтир» эпосында аның төп герое үзен «асылы» буенча «ай тамгалы Тамаман», дип атый [Ногай халк: 1969. 76 б.]. Шул ук аңлатма Добруджа (Буджак) татарларыннан язып алынган «Чора батыр» дастанында да бар:

*Köyimniñ adin soracañ,*
*Kökişli Tama derler oğa* [Bozcigit kitabindan: 1988].

Ул юлларны хәзерге татар әдәби телендә мондый рәвештә биргәннәр:

*Каламның исемен сорасаң,*
*Көкешле Тамга, диерләр* [Чура Батыр: 1993. 53 б.].

Чынлыкта «көй» – авыл, торак пункты (шул исәптән, шәһәр/кала да була ала) дигән сүз. Бу очракта, димәк, казакъларда һәм нугайларда ыру/кабилә исеме булып йөргән «тама» төшенчәсе торак пункты мәгънәсендә бирелгән. Мондый мәгънә кырым татарларының «Чора Батыр» дастанында да бар. Мәсәлән, В.В. Радлов язып алган шушы дастанның бер версиясендә Чора батырның атасы Нарик карт турында, ул «Кокешлу Тама[да] мӓкан тикти, отурду», диелә ([Образцы: 1896. Ч. VII. С. 124]; тагы карагыз: [Къырымтатар: 1991. 69 б.]). Чора батырның үзе

турында да дастанның бу һәм башка версияләрендә аның «Кукушле Тама» яисә «Кокушле Кок Тама» дигән урында яшәгәнлеге турында сөйләнә [Образцы: 1896. Ч. VII. С. 127–129, 170; Къырымтатар: 1991. 61–62, 66–69 бб.]. Кырым татарлары вариантларының берсеннән күренгәнчә, сүз аларда да торак пункт – «көй» турында бара [Образцы: 1896. Ч. VII. С. 182].

Идел-Урал буе татарлары арасында таралган «Чура батыр» эпосында да Чураның мин – «Кукес углы Тамамән», дигән сүзләре бар [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б.]. Бу фраза Чура батырның дусты саналган Колынчак батырга багышланган бер «хикәят»тә дә китерелә [Татар эпосы: 2004. 396 б.]. Күренә ки, бу очракта Чура батырның Күкес угълы булып, Тама ыруына караганлыгы күз алдында тотыла булса кирәк. Чынлыкта, башкортларның тамьян-катай ыруы шәҗәрәсе дә шундый нәтиҗә бирә: анда «Нурек исемле морзаның Җагалбай нәселеннән, казакъ булганлыгы», аның «Бохара тамагыннан Уил елгасы буена күчкәнлеге» турында әйтелә [Хусаинов: 1985. С. 15–16] һәм Нурекнең угълы Сура (Чура) икәнлеге күрсәтелә дә алар шушы тамьян-катай ыруы белән бәйләнелә. Монда без «тамьян» терминына игътибар итәргә тиешбез, чөнки ул атама Чура батырның татарлар арасында язып алынган югарыда китерелгән шәҗәрәсендә дә чагыла – Карауҗаның олы улы булып исәпләнгән Кара Төмән исеме (авыл атамасында– «Каратмән») төмән / тӓмӓн / тамьян атамалары белән бәйле, дип уйларга урын бар һәм алга таба без бу фикерне аерым рәвештә нигезләрбез.

Шулай итеп, сорау туа: Чора батыр – Чура Нарыков, тама / тана / төмән (тамьян) ыруыннан булганмы яисә аның кабилә-ыруы башкача аталганмы? Бу сорау урынлы, чөнки Чура батырга багышланган дастаннарда без аның башка бер кабилә белән бәйләнгән булганлыгын да күрәбез. Ул турыда кайбер мәгълүматлар инде китерелде, аларга хәзер ныграк тукталырга тиешбез. Анализ ясау өчен безгә түбәндәге дастаннардан алынган юлларга мөрәҗәгать итәргә кирәк:

**I. Нугай варианты:**

а) *Мен аргынмын аргын ман,*
*Ак сункардай кыргый ман,*
*Асылымны сорасаң,*
*Ай тамгалы Тамаман* [Ногай халк: 1969. 76 б.].

б) *Тоьре тувыл караман,*
*Анадан эгиз тувмай дараман,*
*Асылымды сорасань,*
*Ноькис улы Тамаман* [Шунда ук: 1969. 74 б.].

**II. Добруджа татарлары варианты:**

а) *Мен arğinman, yorginman*
*………………………………*

б) *Asilimni sorasañ,*
*Qirimdaki Kökişli Tama'nin*
*Köyinden kvilgăn uliman.*

в) *Tőre tuvil, qaraman*
*Eqiz tuvil, daraman*
*Kőyimiñ adin soracañ*
*Kőkişli Tama derler oğa,*
*Ondan кelip baraman* [Bozcĭgĭt kitabindan: 1988].

**III. Кырым татарлары варианты:**

а) *Тёре дигиль, къараман,*
*Коюмнинъ адыны сорасанъ,*
*Кокушли кок Тамалыман* [Къырымтатар: 1991. 69 б].

б) *Ман торо тугул, караман,*
*Äкäу тугул, дараман,*
*Койумнун адын сурасан,*
*Кокушлу кой Тама* [Образцы: 1896. Ч. VII. С. 182].

**IV. Идел-Урал буе татарлары варианты:**

а) *Мән Чурамын, Чурамын,*
*Түрә түгел карамын,*
*Асылымны сорасаң –*
*Кукес углы Тамамән* [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б.;
Татар эпосы: 2004. 396 б.].

**V. Казакълар варианты:**

а) «*...в древние времена в г. Казань обитали в нем народы, носившие название «Тама». В числе их три брата ... Старшего звали Кариб-баем, среднего Нарикбаем, младшего Исым-бием… Скот [Нарика] ... пасли 40 юртовладельцев, таминцев. [Они] кочевали с ним, были его верными слугами…*» [Сборник: 1895. Т. IV. С. 2].

б) *Асылымды сұрасаң,*
*Асылым артык арѓынмын.*
*Тегімді менің сұрасаң,*
*Көк нарлы танамын* [Батырлар жыры: 1989. 328 б.].

в) *Ногайлының ішінде*
*Асылым артық арѓынмын.*
*Бергі атамды сұрасаң,*
*Көк нарлы Танамын* [Шунда ук: 366 б.].

Югарыда китерелгән мәгълүматлардан Чура батырның ике төрле «асылга» ия булганлыгы килеп чыга: бер яктан ул – аргын, икенче яктан – тана / тама (ай тамгалы, Көкеш (Ноькис) улы, Көкешле, Көк нарлы). Әгәр дә мантыйк нигезендә уйлап карасак, шәхес бер үк вакытта ике кабилә яисә ыру вәкиле була алмый. Шуңа күрә дә безнең элегрәк чыккан популяр язмабызда бу каршылыкны чишү өчен тама ыруын аргын кабиләсенең бер кисәге дип карарга тәкъдим ителгән иде [Исхаков: 1994; 1998]. Ләкин, хәзер без бу мәсьәләне башкача аңлатырга кирәк, дип уйлыйбыз һәм бу яңа чишелеш казакълар арасында таралган «Нәрік» дастанындагы бер билгеләмә аркылы табыла ала.

Әйтеп үтелгәнчә, казакълар арасында Чура батырның үзенә генә түгел, ә аның атасына багышланган «Нәрік» исемле дастан да бар. Ул эпостагы бер эпизодта Нәрик белән аның хатыны Меңди аруның илләреннән качып киткәч, калмыклар башлыгы Өгезханга барулары тасвирлана һәм Өгезханның Нәрикне башка җиргә җибәреп, аның хатынына кул сузуы сурәтләнә. Шулвакытта хезмәтчеләре белән бергә Меңди аруның каршысына килеп баскан «Төрехан», ягъни Өгезхан исеменнән аның бер хезмәтчесе тарафыннан Меңди аруга ясалган шушы ханга сөяркә булу турындагы тәкъдименә каршы Нәрикнең хатыны мондый сүзләр әйтә:

*Арғы атамды сұрасаң,*
*Карадөң сынды карт еді*
.....................................
*Онан туған Жұбаныш.*
.....................................
*Онан туған Сүйініші.*
....................................
*Онан туған Бегіс деп,*
....................................
*Бегістен туған Тама еді.*
...................................
*Таманың улы Тана еді,*
*Оның улы карт Нәрік...* [Батырлар жыры: 1989. 320 б.].

Кызыклы шәҗәрә килеп чыга: Нәрік ← Тана ← Тама ← Бегіс ← Суйініші ← Жубаныш ← Карадөң. Ә бит чынлыкта бу шәҗәрәдә сүз Чура батырның атасы турында түгел, ә аның анасы ягы турында бара, ул бит

үз нәселе, үз ыруы турында сөйли! Бу шәҗәрәнең тагы бер варианты казакъларның «Тана» исемле дастанында да бар. Анда «ак төре» һәм «хан» булган, «Астана халкының» башында торган Тана (аның баласы буларак Нәрік күрсәтелә) үзенең «аргы атасы» дип Карадөңне күрсәтә, аннан соң Жубаныш һәм Суйініші исемнәре атала [Батырлар жыры: 1989. 289, 291, 297, 300, 302 бб.]. Күренә ки, бу шул ук шәҗәрә һәм анда Нәрикнең исеме барлыкка килсә дә, әйтелгән нәсел җебенең аның хатыны ягыныкы икәнлеге ачык.

Гомумән алганда, тана (тама) кабиләсе (ыруы) ике (аргын-тама) бер-берсе белән туганлык мөнәсәбәтендә торган фратриаль бүленештәге берләшмәнең «хатын» ягы кабиләсе булып чыга һәм дөрестән дә ул якка – ана ягына, Чура (Шора) батырның мөнәсәбәте булмыйча булдыра алмый. Әмма, ирләр дөньясы беренче урында торган күчмә төркиләрдә – ә Нәрикнең үзен һәм аның улы Чураны дастаннар «токсан баулы ногай» (монда инде безгә билгеле булган Алтын Урда татарларының 90 кабилә-ыруга бүленеше күз алдында тотыла) белән бәйлиләр [Батырлар жыры: 1989. 321 б.] – әни ягының кабилә билгесенең беренче урынга чыгуы үзенчәлекле күренеш һәм ул аерым аңлатуны таләп итә. Беренче башка килгән фикер, билгеле, Чура батырның трагик үлеменнән соң аның нәселеннән булган исән калучыларның Казан ханлыгы җирләреннән ана ягы булган кабилә җирләүенә китеп, шунда «сеңүләре» нәтиҗәсе буларак, тама (тана) кабиләсенең дастаннарда өскә чыгуы. Ләкин бу аңлатма кайбер каршылыкка китерә. Әйтик, Казан арты татарларыннан язып алынган тарихи легендада сакланган «Чура батыр» дастанындагы Чураның «асылын» Күкес угълы Тамадан чыгару нәрсә турында сөйли? Кырым һәм Добруджа татарларындагы тикшерелә торган дастан версияләрендә «Көкешле кок (кой) Тама» атамасының торак пункты булып йөрүен истә тотсак та, ул исемнең нәрсә аңлатуы турындагы проблема кала. Безнең бу турыда бер гипотезабыз бар, әмма аның эчтәлегенә кереп киткәнче аргын кабиләсенә бәйләнгән кайбер генеалогик һәм тарихи мәгълүматка тукталып китү кирәк.

Алда әйтелгәнчә, Казан янындагы авыллардан язып алынган тарихи легендаларда Кара бинең улы Карауҗа искә алына. Кырым татарларында исә Кара Коджа бәк аргыннарның бабасы саналган. Бу уңайдан игътибар итик: казакъларның Урта Урдасы (Йөзе) составына кергән аргын кабиләсенең ике ораны булып (Акжол һәм Кара Ходжа) [Тынышпаев: 1925. С. 29], аның икенчесендә Кара Хуҗа исеме чагыла. Искә төшерик, бу исем «Идегәй» дастанында да бар – анда «Аргыннарның башы идең, Кара Куҗа батырым», – дигән Туктамыш хан тарафыннан әйтелгән сүзләр китерелә [Идегәй: 1988. 47 б.]. Эпоста ул башка урыннарда да «Аргылның углы Кара Куҗа» [Шунда ук: 205 б.], «Кара Куҗа Аргын би» [Шунда

ук: 141 б.] буларак инде безгә таныш булган Туктамыш ханның «тугыз батыры / бие» исемлегендә күренә. Чынлыкта, Кара Кужа / Хужа – тарихи шәхес. Шәрәф әд-дин Йездинең «Зафәр-наме» (1424/1425 елны тәгәлләнгән) әсәреннән күренгәнчә – ә ул автор Тимурид Шахрухка һәм аның улы Ибраһим солтанга хезмәт иткән – Тимур янына ул үләсе елны «берникадәр вакыт начар хәлдә далаларда йөргән» Туктамыш хан исеменнән аның «борынгыдан килгән нукерларыннан» булган Кара-ходжа илче буларак килә һәм ханы исеменнән гафу үтенә, нәтиҗәдә аны Тимур, «Җучи Олысын» алга таба Туктамышка кайтарып бирүне вәгъдә итеп, Отрар шәһәреннән походка киткәндә бүләкләр белән кире кайтарып җибәрә [История Казахстана в персидских источниках: 2006. Т. IV. С. 350–351]. Бу вакыйга Тимурның 1405-нче елның 18 февралендә үлүе алдыннан була. Шулай итеп, аргын кабиләсенең бие Кара-хуҗа (Караҗау / Кара Коджа) 1405-нче елны ханы янына китеп бара һәм соңыннан берьюлы ике ханлыкта – Кырым һәм Казан ханлыкларында, аргыннарның нәсел башы булып санала башлый, ә казакъ далаларында ул заманалар үтү белән аргын кабиләсенә һәм кайбер башка (тама / тана, каратамыр) ыруларга нисбәтле буларак искә алына. Бу мәгълүмат нәрсә турында сөйли соң?

Моны аңлау өчен Алтын Урда таркалу алдыннан булган вакыйгаларга кыскача күзәтү кирәк.

Инде алда әйтелгәнчә, таралып бетә язган дәүләтне кире «җыеп» алган Туктамыш хан (1377/78–1406) Алтын Урданың үзәк өлешенә аның сул канаты җирләреннән килеп керә (бабаларының биләмәләре – Мангышлак якларында булганлыгы билгеле) һәм үзе белән борынгыдан бу нәселгә буйсынган дүрт кабиләне (шырын, барын, аргын һәм кыпчак) дә алып килә. Аларның берсенең – шырын кабиләсенең – шул дәвердә Кырымда урнашуы (аның элекке хөкемдары кыйат кабиләсе бәге темник Мамайның биләмәсен алып) төгәл билгеле [Исхаков, Измайлов: 2007. С. 154–155]. Бәлки, башка Туктамыш ханга бәйле кабиләләр дә шул тирәләрдә яшәгәннәрдер. Һәрхәлдә, 1399-нчы елдан соң бүтән Алтын Урда тәхетенә якын килә алмаган (ул тәхетне алдагы елларда Идегәй тәхеткә утырткан ханнар билиләр) Туктамыш хан янында, әле 1405-нче елны да, бу хан качып йөргән вакытларда, «искедән калган нукерларыннан» саналган аргын кабиләсенең бие Кара-Хуҗа булуы күп нәрсә турында сөйли, ахрысы, искә алынган 4 кабилә хан тирәсендә калуларын дәвам иткәннәр. Соңрак чорга караган тарихи материаллар күрсәткәнчә, Туктамыш ханның уллары һәм туганнары тирәсендә (хан үзе 1406-нчы елны Шадибәк хан һәм Идегәй тарафыннан Себердә, Төмән / Чимги-Тура тирәләрендә үтерелә [Миргалеев: 2003. С. 148]) бу кабиләләрнең барысы да диярлек искә алына. Димәк, алар чыннан да бу хан нәселе янында калганнар.

Билгеле булганча, инде картайган (аңа үләр алдыннан 55–60 яшьләр чамасы була) һәм авыр хәлгә калган Туктамыш хан һәлак булганнан соң аның уллары (билгелеләре бишәү) төрле якларга таралалар, ләкин Алтын Урда тәхете өчен көрәшләрен туктатмыйлар. Бу канкойгыч сугышларда – каршы якны озак вакыт сул канатның башында торган Идегәй җитәкли – Туктамыш ханның уллары берсе артыннан берсе тәхеткә күтәрелеп, юкка чыгалар. Идегәй дә 1419/1420-нче елны бер җиңелүдән соң, Туктамышның кече улы Кадыйрбирде хан боерыгы буенча, инде әйтелгәнчә, баарын (барын) кабиләсе бәге Сарай тарафыннан үтерелә (бу заман турында тулырак карагыз: [Миргалеев: 2003; Гулевич: 2018]). Ләкин сәяси вакыйгалар агымы тукталмый һәм аларда Туктамыш хан нәселе вәкилләре катнашуларын дәвам итәләр. Безгә аларны бераз барлау кирәк, чөнки Чура батырның бабаларының тарихын шуннан башка бөтен тирәнлеге белән аңлап булмый.

1418-нче елны Алтын Урда җирләрендә төрле татар төркемнәре арасында үзара көрәш кызган вакытта, Туктамыш ханның кече улы Кадыйрбирде (аны 1407/1408-нче елны ук Идегәйдә кияүдә булган Җаникә исемле апасы Кырымга озата) Кырым белән бәйле бәкләр тарафыннан тәхеткә күтәрелә һәм ул Идегәйгә каршы яу белән китә. Аның гаскәрләрендә төп рольне уйнаучылар ширын кабиләсенең бәге Тегинә һәм конграт кабиләсенең бәге Айдар (Хәйдәр) булганнар. Идегәй бу төркем белән (алар кулында, ким дигәндә, 100 мең кешелек гаскәр булган) килешергә тырышып караса да, ахыр чиктә 1419-нчы елны җиңелә һәм, инде сөйләнгәнчә, үтерелә. Төрле мәгълүматлар буенча, аны үтерүгә барын кабиләсен җитәкләгән Сарай бәктән башка ширын кабиләсе бәге Тегинә һәм тиздән хан буласы Олуг-Мөхәммәднең атасы Ичкиле Хәсән углан да катнашкан (тулырак итеп карый аласыз: [Гулевич: 2018. С. 129–145]). Элегерәк тасвирланганча, нәкъ шушы бәрелеш вакытында каты яраланган Кадыйрбирде хан да үлә һәм аның урынына ширын бәге Тегинә һәм конграт кабиләсе бәге Айдар тырышлыгы белән Туктамыш хан нәселеннән булган Олуг-Мөхәммәд утыртыла. Бу дәвердә ул җитәкләгән гаскәрләр составында барын кабиләсе һәм кыпчак кабиләсе дә, һичшиксез, булганнар. Аргын кабиләсе турыдан-туры искә алынмаса да, ул да Олуг-Мөхәммәд тирәсендә булган, дип уйларга урын бар (алга таба бу фикер тулырак итеп нигезләнер).

Чура батырның бабасы Кара-Хуҗаның 1405-нче елдан соңгы язмышын күзаллау өчен Олуг-Мөхәммәднең ханлыгы дәверенә бераз тукталып китү кирәк, чөнки ул Болгар / Казан вилайәте җирләренә килеп урнашканчы, шактый катлаулы сәяси юл үтә.

Иң башлап, шуны әйтергә кирәк: 1419-нчы елны Олуг-Мөхәммәд ханлыкка күтәрелгәндә ул Олуг Урда ханы (генуэзлылар аны «Урда импера-

торы», «бөек император» / «imperatoris de Lordo» дип атаганнар) буларак, ягъни Сарай ханы дәрәҗәсендә тәхеткә утыртыла. Шул ук вакытта аның кайбер якын туганнары Кырым биләмәсендә (=олысында, төмәнендә) утыралар һәм алар да «император», «Солхат императоры» (хан яки солтан) титулына ия булалар [Гулевич: 2018. С. 149–162]. Олуг-Мөхәммәд шушы шартларга – истә тотыйк, Алтын Урда таралып килгән заман бу– риза булса да, 1423-нче елның язында Олуг Урданың зур өлеше көндәше Мөхәммәт-Барак хан кулына күчкәч, Кырым тирәсенә чигенә, нәтиҗәдә Солхатта 1424-нче елның башында аның вәкиле булып безгә таныш булган шырын бәге Тегинә урнаша, берничә айдан соң хан үзе дә анда килеп, элекке хөкемдар булган туганы Дәүләт-Бирдене ул урыннан бушата яисә, аны, үз урынбасары Тегинә бәкне янына куеп, ныграк контрольга ала. Ахыр чиктә, Олуг-Мөхәммәд Кырымда төпләнә, ә Дәүләт-Бирде аннан качып китә. Ләкин, 1424–1425-нче елларның чикләрендә Дәүләт-Бирде үзенең биләмәсен кире кайтаруга ирешә, ә Олуг-Мөхәммәд, үз чиратында, Бөек Литва кенәзлегенә кача. Витовтның ярдәме белән, ул тиз арада үз хәлен яхшырта һәм Кырымны яңадан контроль астына ала, әмма үзе 1425–1426-нчы елның кышын Түбән Днепр җирләрендә, далада, үткәрә дә, 1426-нчы елның язында Мөхәммәт-Барак ханга һәм аңа хезмәт иткән Идегәйнең улы Мансурга каршы һөҗүм башлый. Олуг-Мөхәммәд көнчыгышта походта булганда Дәүләт-Бирде Кырымда үз хөкемлеген яңадан торгыза. Олуг-Мөхәммәд исә Сарай шәһәрен кире кайтара, ә Мөхәммәт-Баракны Урта Азияга кысрыклап чыгара. Ахрысы, алга таба Дәүләт-Бирде берникадәр уңышларга ирешеп, Сарайны да ала (һәрхәлдә, анда аның исеменннән 831 х. е./1427/1428-нче елда сугылган акчалары билгеле). Әмма, чынлыкта ул 1427-нче елдан соң чыганакларда башка искә алынмый, Олуг-Мөхәммәд исә Бөек Литва кенәзе Витовт ярдәме белән Кырымны кире кайтаруга ирешә.

Бу вакыйгаларда шырын кабиләсе бәге Тегинә актив роль уйный. Гомумән алганда, Олуг-Мөхәммәдкә буйсынган Олуг Урдада бу дәвердә Тегинә бәктән башка тагы конграт бәге Айдар һәм мангыт кабиләсе башлыгы Идегәйнең улы Нәүрүз көчле лидерлардан саналган. Әмма, соңгысы атасы дәрәҗәсенә ирешә алмаган һәм ханнан шуңа күрә риза булмаган. Тегинә (аның Кырымдагы ставкасы Солхат / Иске Кырым шәһәрендә була) исә 1431–1432-нче елның кышында Идел буеннан үзенең Кырымдагы ставкасына кышлауга киткәндә, Олуг-Мөхәммәд белән арасын боза (Мәскәү бөек кенәзлегенә кемне утырту мәсьәләсе буенча ханның һәм аның ягында хәрәкәт иткән конграт бәге Айдарның фикере белән шырын кабиләсе бәге фикере туры килмәү аркасында). Башка сәяси вакыйгалар белән бергә, бу, сарай эчендәге конфликт, Олуг-Мөхәм-

мәд өчен начар бетә – 1433-нче елның көзендә аның кияүе булган Айдар бәк тәхеткә Сәйед-Әхмәтне (ягъни Дәүләт-Бирденең энесен) ханлыкка күтәрә, ә Олуг-Мөхәммәд кулында Олуг Урданың бер өлеше генә (Кырым, Днепр-Дон елгалары арасы) кала. Шуның өстенә, 1436-нчы елны мангыт Нәүрүз бәй Иделнең Хаҗитархан шәһәре тирәләрендә хөкем иткән Кече-Мөхәммәд хан ягына чыга, ә бу, үз чиратында, Сәйед-Әхмәткә Кырымны яулап алу мөмкинлеген тудыра (карагыз: [Гулевич: 2018. С. 159–182]). Олуг-Мөхәммәд үзенең якыннары һәм зур булмаган гаскәре белән (барысы – 3500 кеше чамасы) төньякка – рус җирләренең чикләренә, Белев шәһәре янына чигенә һәм озак та үтмәстән Болгар / Казан вилайәте җирләренә килеп кереп, шунда кала. Бу әһәмиятле сәяси вакыйга турында – ул бит, ахыр чиктә, Казан ханлыгына нигез салуга китерә – аерым зур сөйләшү кирәк, монда андый бурыч куелмый, шуның өстенә бу мәсьәлә инде бераз тикшерелде. Ләкин бер сорауга җавап бирү таләп ителә: Олуг-Мөхәммәд белән аңа электән хезмәт иткән кабиләләр (шырын, барын, аргын, кыпчак) тулаем киткәннәрме, әллә аларның бер өлеше генә төньякка юл тотканмы?

Бу сорауга тулы җавап бирү мөмкин түгел, шулай булса да, Олуг-Мөхәммәд белән аның нәселенең «иске нукерларының» бер өлешенең үз кешеләре белән күчеп киткәнлеген расларга була. Әйтик, Казан шәһәреннән ерак булмаган ике авылның (Зур Карауҗа һәм Кече Карауҗа) һәм алар белән бәйле (хәзер Казан эчендә калган) «Каравай» / «Караби» исемле бистәнең булуы, бу торак пунктларга нигез салучыларның шәҗәрәләренең Чура би Нарыков белән тоташуы, безнең фикер буенча, бер төркем аргын кабиләсе вәкилләренең Кара-хуҗа би җитәкчелегендә монда килеп утыруларын раслый. Бу күчеп утыру, аргын кабиләсе бәге Кара-хуҗаның тарихи чыганакта соңгы тапкыр 1405-нче елны күрсәтелүен (ул, илче буларак килгәч, бик яшь булмагандыр) дә искә алсак, фәкать тик Олуг-Мөхәммәд һәм аның улы Мәхмүтәк заманында гына була ала. Шушындый күчешнең чынлап та булганлыгын, инде алда әйтелгәнчә, Казан ханлыгында 1455-нче елны күрсәтелгән Шаптяк Сараевич исеме дә раслый. Әгәр дә ул барын кабиләсе бәге Сарай белән бәйле булса – ә бу бик мөмкин – барыннар да шул ук дәвердә Олуг-Мөхәммәд белән Казан җирлегенә күчкән булып чыгалар.

Чура батыр белән бәйле авыллар XVI–XVII-нче йөзләрдә Казан өязенең төньяк-көнбатышындагы «Галич юлында» (Галицкая даруга) булганлыктан [Исхаков: 2002. С. 348–353], шушы территорияне Казан ханлыгындагы аргын кабиләсе бәкләре биләмәсе, дип санарга кирәк. Бу мәсьәләне без әле аерым тикшербез, аңарчы башка бер проблемага тукталыйк. Ул–Кырымда калган безгә инде таныш булган дүрт кабилә

турындагы мәсьәлә. Аның төп эчтәлеге шунда: Олуг-Мөхәммәд үзенә буйсынган Олуг Урданы (аңа, әйтелгәнчә, Кырым биләмәсе дә караган) ташлап китәргә мәҗбүр булгач, Кырымда элеккеге Туктамыш ханның бабаларыннан килгән кабиләләрнең бер өлеше калу мәсьәләсе. Бу калу исә тарихи чыганаклар тарафыннан раслана. Аларны карап үтик, чөнки Чура Нарыковның Кырымдагы «эзләренә» шулай гына төшәргә мөмкин.

Безнең өчен әһәмиятле бер мәгълүмат кырымлы тарихчы Реммал хуҗаның (Кайсуни-заде Мехмед Нидаи) «Тарих-и Сахиб-Гәрәй хан» исемле хезмәтендә сакланган. Бу, XVI-нчы йөзнең беренче яртысына караган чыганакта, сүз 1538–1551-нче еллар арасындагы Кырым ханлыгының хәрби походларын тасвирлаганда, аның авторы 1543-нче елга караган армиядә булган кабилә гаскәрләре турында информация биреп, безгә таныш булган дүрт карачы бәкләргә буйсынган кабиләләрнең өчесенең (дүртенче булып бу очракта 1502-нче елдан соң Кырымда көчәйгән мангыт кабиләсе атала) хәрби потенциалын күрсәтә: ул елда ширыннар – 5 мең, аргын һәм кыпчак кабиләләре 3 мең сугышчы чыгарганнар [Инальчик: 1995. С. 76]. Безгә XVI-нчы йөз башларындагы ширын кабиләсе вәкилләренең гомуми саны билгеле – 20 мең кеше [Исхаков: 2009-а. С. 41]. Шушы саннан чыгып карасаң, Кырымда төпләнеп калган кабиләләрдәге гомуми халык саны белән аның сугыш эшләрендә катнашучыларының пропорциясе 4:1 булып чыга. Шулай булганда, аргын һәм кыпчак кабиләләре кабиләдәшләренең гомуми саннары XVI-нчы йөзнең беренче яртысында якынча 12 мең чамасы булган, дип уйлый алабыз. Дөрес, аерым рәвештә аргын кабиләсенең кеше саны безгә билгеле түгел. Һәрхәлдә, ул сан әллә ни зур булмаган. Ләкин, барыбер Кырым ханлыгында аргын кабиләсенең бер өлеше Олы-Мөхәммәдтән соң да калган һәм анда әһәмиятле роль уйнаган, дип раслый алабыз. Бу фикерне өстәмә рәвештә дәлилләүче тагы берничә факт китерә алабыз. Әйтик, 1501-нче елны, Иван III Кырымга затлы татарларга бүләкләр җибәргәндә, алар арасында ширын, барын һ. б кабиләләрнең җитәкчеләре белән бергә «Мардан Аргын» дигән шәхес тә искә алына [Сборник: 1884. Т. 41. С. 352]. Ул чынлыкта бәк булган, чөнки икенче тапкыр ул 1508-нче елны Кырым ханы Меңгли-Гәрәй хатында башка бәкләр белән (алар ике өлештән торалар: беренче төркем – Кырым ханлыгына 1502-нче елдан соң кушылган Олуг Урда бәкләре – кыйат, мангыт, салҗигут, конграт кабиләләренең лидерлары; икенче төркем – ширын, барын, аргын, кыпчак кабиләләре лидерлары) бергә «Аргын Мардан князь», дип искә алына [Сборник: 1895. Т. 95. С. 20]. Күренә ки, бу очракта да күрсәтелгән ике төркем (бәлки ул икегә бүленү Кырым ханлыгы гаскәрләренең уң һәм сул канатка бүленүе белән бәйледер) бәкләре (кнәзләре) дәүләттәге төп кабиләләрне чагыл-

дырганнар. Һичшиксез, Мардан бәк артында Кырым ханлыгындагы аргын кабиләсе торган.

Аргын кабиләсенең бәкләре Кырым ханлыгына караган документларда алга таба да искә алыналар: Кырым ханы Меңгли-Гәрәйнең 1515-нче елга краган «Сүзендә» аргын Манташ «князь» (чыганак рус телендә сакланган) башка аксөякләр исемлегендә күренә, Баһадир-Гәрәй солтанның «яхшы хезмәтчеләре» арасында 1519-нчы елны аргын Али-Шукур «князь» булганлыгы билгеле [Сборник: 1895. Т. 95. С. 161, 610]. Шулай ук, 1517-нче елны Кырым ханы Махмед-Гәрәй Мәскәү бөек кенәзе Василий Иванович белән килешү төзү турында сөйләшкәндә, шартнамәгә ризалык бирергә тиешле карачы бәкләр арасында без белгән дүрт кабилә аталып, алар арасында аргын кабиләсе дә саналып кителә [Сборник: 1895. Т. 95. С. 388]. Ниһаять, 1519-нчы елгы Мәскәү белән Кырым арасында килешүгә кул кую өчен төзелгән Кырым ханлыгының аксөякләре исемлегендә кыпчак, конграт, кыят кабиләләренең бәкләре белән бергә ике аргын кабиләсе вәкиле дә күренә – берсе инде безгә таныш Али-Шукур «князь», икенчесе – Корбан-Али «князь» [Малиновский: 1863. С. 415]. Чынлыкта бу исемлектә кабилә лидерларының ике төркеме булып, аның беренчесе ширын кабиләсе башлыгы Мемеш «князь»дан башланса, икенчесе (аргын кабиләсе бәкләре шунда күрсәтелгән) кыпчак кабиләсе лидеры Исмаил «князь»дан башлана. Инде әйтелгәнчә, бу Кырым ханлыгындагы кабиләләрнең уң һәм сул кул кабиләләренә бүленүе белән бәйле булып, аргыннар һәм кыпчаклар, башка кайбер кабиләләр белән (конграт, кыят) бергә, бу дәүләтнең сул канатын тәшкил иткәннәр булса кирәк. Бу нәтиҗәне истә тотыйк, чөнки ул безгә әле кирәк булачак. Хәзергә исә без тагы бер тапкыр тулы ышаныч белән аргын кабиләсенең бер өлешенең Кырым ханлыгында инде XV-нче йөздән үк яшәгәнлеген раслый алабыз.

Шушы нәтиҗә нигезендә яңадан Чура Нарыковның Казан ханлыгындагы социаль статусы мәсьәләсенә кире кайтыйк.

## § 3. Чура Нарыков – «волостель», «воевода», «большой князь»

Югарыда Чура Нарыковның затлы аксөякләрдән булганлыгы һәм Казан ханлыгында 1526–1546-нчы еллар арасында «князь», ягъни бәк (би/бәй) титулы йөрткәнлеге инде ачыкланган иде. Ләкин аның социаль статусын билгеләгәндә дастаннарда чагылган кайбер каршылыкларны аңлатырга һәм бу турыда тәгаен генә бер фикергә килергә кирәк булачак. Эш шунда ки, дастаннарда, бер яктан, Чура батырның югары социаль статусы турында әйтелсә, икенче яктан ул «кара» кеше буларак билгеләнә. Мәсәлән, Идел-Урал буенда язылган дастан версияләрендә Чура үзе турында әйтә:

*Мән Чурамын, Чурамын,*
*Түрә түгел карамын,–дип* [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б.].

Шул ук хәл Добруджа (Буджак) татарларындагы эпос вариантларында да күренә:

*Töre tuvil, qaraman.*
*Egiz tuvil, daraman* [Bozcigit: 1988; Чура Батыр: 1993. 53 б.]

Кырым татарлары версияләрендә дә шул ук хәл – аларда әйтелә:

*Тёре дегиль, къараманман, – дип* [Къырымтатар: 1991. 69 б.]

Нугайлардагы «Шора баьтир» дастанында Чураның атасы Нарик улының Али бийне үтерүе турында сөйләгәндә, әйтә:

*Хан казагын (ягъни, Али бийне – Д.И.) оьтирген,*
*Кадемсез бизим Шора увыл ды.*
.....................................................
*Тоьре тувыл, кара оьлтирген кутылмас,*
*Меним улым эр Шора, – дип* [Ногай халк: 1969. 71 б.].

Фәкать тик казакъларда гына Чура батырга багышланган эпик әсәрләр циклында аның анасы Меңди ару Чура турында син: «Асыл тұған Шорасың», «Ақ сұйек туған төресін», дип белдерә [Батырлар жыры: 1989. 344, 351 бб.], ә Әделшә исемле хан (Казан ханы буларак телгә алына) аның турында «Ақ сүйек туган баласың», дип кенә түгел, ә «Атаң Нәрік хан еді», дип тә әйтә [Батырлар жыры: 1989. 354–355 бб.]. Чынлыкта бу очракларда дастанның казакъ версияләре дөреслеккә якынырак, чөнки Чура Нарыков «асыл туган» һәм «аксөяк» буларак аталырга хаклы. Ә менә аның «кара» буларак искә алынуы һәм «түрә» булмаганлыгы турындагы информация барыбер игътибарга лаек, чөнки бу төшенчәләр артында кайбер тарихи яктан әһәмиятле булган чынбарлык ята. Беренчедән, кабилә бәкләре нәселеннән булган Чура кабиләдәшләреннән югары торса да, кабилә лидерлары арасыннан иң бөек дәрәҗәләргә күтәрелгән (императорлар статусына җиткән) Чыңгызхан нәселе вәкилләре каршында (аларның нәселен юкка гына «Алтын ыру / уруг» дип атамаганнар) барыбер «кара халык» (борынгы төркиләрдә – «будун») арасында саналган. Икенчедән, инде алда күрсәтелгәнчә, «чура» төшенчәсенең «вассал», «хезмәттәге төркем вәкиле» дигән мәгънәсе булуы да дастандагы Чура Нарыков фигурасына бераз «кара төс» өсти булса кирәк (өстәмә рәвештә ул тенденцияне «чура» атамасының «кол» дигән мәгънәсе булу да көчәйтә, дип уйлый алабыз). Бу ике сәбәптән тыш Чура батырның үзенчәлекле социаль

статусының тагы бер аңлатмасы бар, әмма аның «төбенә төшү» бик үк җиңел түгел. Сүз менә нәрсә турында бара.

Чура батырга багышланган казакъларда язып алынган дастан вариантларында аның төп герое турында бер билгеләмә бирелә: «артык туган Шора», «артык туган төре», «артык туган султан», «артык аргын» [Батырлар жыры: 1989. 328, 334, 338, 344–345, 354, 366 бб.]. Ни өчен соң бу дастаннарда «аргын» дип билгеләнгән Чура (түрә буларакмы, солтан буларакмы) «артык» буларак искә алына? Ул кайсы яктан «артык» булган? Бу сорауларга җавап дастан эченнән эзләнергә һәм табылырга тиеш. Моның өчен яңадан аларның төрле версияләренең эчтәлегенә керәсе була.

Инде әйтелә башлаганча, Чура батыр Идел-Урал буйларында язып алынган дастан версияләре буенча атасы белән анасы Хаҗитархан шәһәреннән (аңарчы атасы Нарәң батыр «Дагыстан йортында» яши ахрысы) күчеп барганда туа һәм ул туган җир Кырымга якын яисә Кырымда ук була. Үсеп җиткән дәвердә дастан герое «Идел тарафына» да сәяхәт ясый һәм аннан кире Кырымга кайта, чөнки дастанда атасының «үз йорты» шунда, дип күрсәтелә. Аннан соң, Кырымда Гали бине үтереп, Нарәң улы Чура батыр Казанга килә һәм гомере беткәнче шунда кала (дөрес, бер тапкыр Кырымга кайтып килә аннан) (карагыз: [Татар халык иҗаты: 1984. 108–109, 111, 113, 115–118 бб.]). Игътибар итик: төрле күчешләргә карамастан, Идел-Урал буйларында таралган дастан вариантларында Чура батырның атасының биләмәсе «Кырымда», дип күрсәтелә, «Казанга», ягъни, Казан ханлыгына да, дастанның төп герое Кырымнан килә. Тагы бер мөһим әйбер – Чура батыр Казан ханлыгында хезмәт иткәндә (бәлки, ахырга кадәр түгелдер) аның атасы әле исән була һәм үзенең Кырымдагы биләмәсен җитәкли, аннан бер тапкыр Казанга килеп тә китә.

Әгәр дә без Добруджа (Буджак) татарларыннан язып алынган дастанга килсәк, анда Чура батыр Казанга шулай ук Кырымнан килә, аның атасы да анда яши һәм Нарыкның җирләре «Көкешле Тамга» исемле кала янында булып, бу биләмәнең Кырым ханлыгы белән Казан ханлыгы чикләренә якын икәнлеге беленә. Алай гына да түгел, Чураның атасы Нарык үз вакытында Көкешле Тамгадагы биләмәгә «Казан ханлыгыннан» күчеп килгән, дип белдерелә дастанның тикшерелә торган версиясендә. Шуңа күрә дә Чура Али (Гали) бәйне үтереп «Казан дигән илгә» китәргә карар кылгач, ул үзенең «атасы йортына», дөресрәге, элегрәк дәвердә аныкы булган биләмәгә киткән булып чыга [Чура Батыр: 1993. 23, 28, 30, 32–33, 44–45, 50, 53–56, 59–60 бб.]. Бу очракта да Чура батыр Кырымнан Казанга күчкәндә аның атасы әле исән була.

«Чора батыр» дастанының кырым татарлары арасында язып алынган вариантларында да Чураның атасы Нарик Кырымда, Көкешле Тамгада

яшәде, дип белдерелә, ә дастанның герое «Казанга казак булып» чыгып китәргә мәҗбүр булганда, аның атасы Көкешле Тамгада кала. Чура батыр Кырымнан китү өчен юлга чыкканда яңа биләмәдә, ягъни Казан ханлыгында, «хан итсәләр, һич булмам, бәй итсәләр дә, анда һич тормам», дип белдерә [Кърымтатар: 1991. 61–62, 66–67, 69 бб.]. Күренә ки, кырым татарлары версиясендә Добруджа татарлары версиясе белән кайбер каршылыклар бар, ләкин бер ягы белән алар охшаш – Чура б. Нарык Казанга Кырымнан килә һәм ул Кырымны ташлап чыкканда аның атасының биләмәсе Көкешле Тамгада булып, Нарик батыр әле исән була.

Эposның нугай версиясендә шул ук күренеш: Шора батыр Кырымда Али бийне үтергәч, Казанга килә, ләкин ул башта бу юнәлешкә китүне төшендә күрә. Улы Казанда яшәгәндә, Нарик аның янына килеп китә. Нарик әле улы Казанга җыенганда ук, аңа әйтә: «Казан элдә хан болсанъ», – дип. Бу илгә чыгып китүне дастан «казак шыгу» буларак кабул итә [Ногай халк: 1969. 71–72, 74, 78–79 бб.]. Кызыгы шунда, дастанның шушы версиясендә Али бийне үтереп, Казанга җыенганда, дастан герое үзен «Нарик улы мен Шора», дип атаганнан соң, өстәп куя: «Анамнан арам тувган болайым», – дип [Ногай халк: 1969. 68 б.]. Бу җөмләнең мәгънәсе инде безгә таныш булган «артык туган» төшенчәсенә якын булса кирәк.

Хәзер безгә дастанның казакъларда сакланган вариантларын күзәтү кирәк, чөнки аларда башка милли версияләр белән туры килмәүче аерымлыклар сакланган. Беренчедән, бу эпик әсәрнең казакъ вариантларында Нәрик (Нарык) турында аның «туган җире» Казан шәһәрендә иде, ул анда хәтта «хан» да булып торган, дигән фикер әйтелә, ә аның әлеге төбәктән читкә (далага) китүе Али бийне үтерүе белән бәйләнелә (карагыз: [Батырлар жыры: 1989. 306–307, 313, 327, 334, 354 бб.]). Кайбер дастан вариантларында исә бу бийне үтерүче дип Шора үзе күрсәтелә [Шунда ук: 333 б.]. Икенчедән, өйрәнелә торган дастан версияләрендә Шора (Ер-Шора) инде атасы каядыр «далада», аерым бер «төбәдә» хан булып утырган җирдән Казанга юнәлә. Аның анда китүенең дастанның казакъ вариантларында берничә сәбәбе күрсәтелә: 1) Шора Казанны «кяферләр алмасын», атасының «алтын тагы» – бу безгә таныш «алтын тәхет» инде – «яу кулында калмасын», дип бара анда; 2) Ул Казан ханы булган Әдилшәнең Ханҗан атлы кызын хатынлыкка алу өчен дә китә бу җиргә [Шунда ук, 332–334, 352 бб.]. Шушы тарафка юнәлгәндә, Шора «Казанга хан боламын», дип бара. Аны Казан җирендә каршы алган Әдилшә хан «Шора» дастанында Шораның атасы Нәрикнең анда туганлыгын һәм Казанда элек хан булып торганлыгын таный [Шунда ук, 354 б.].

Шулай итеп, Чура батырга багышланган дастаннарда аның атасының ватаны турында берничә аңлатма табабыз: ул башта Кырымнан тышта

(Дагыстанда, Хаҗи-Тарханда, Казанда яисә далада) яши, аннан соң гына Кырымга килеп төпләнә. Күпчелек очракта аның улы Чура батыр Казанга Кырымнан килә. Ләкин, аның каяндыр Кырымнан читтә булган дала җирләреннән чыгып, Казанга бару мөмкинлеген дә күрсәтә «Чура батыр» дастаны. Димәк, дастан героеның Казанга ике төбәктән килү мөмкинлеге бар: берсе – Кырым, икенчесе – конкретлаштырылмаган «дала җирләре». Соңгысы әһәмиятле, чөнки Чура батырның Кырымнан чыгуын алга чыгарган Идел-Урал буе татарлары арасында язып алынган дастан версияләрендә дә аның «Идел тарафында» йөреп кайтуы турында әйтелә. Ахрысы, Чура Нарыков Казанга туп-туры Кырымнан килеп урнашмаган, ә берникадәр вакыт «казак булып» яшәп анда барып җирләшкән. Ни өчен соң барлап чыгылган детальләр әһәмиятле? Чөнки алардан башка Чура батырның «артык туган» булуы турындагы мәгълүматны аңлатып булмый. Хәзер инде ул мәсьәләгә аерым рәвештә тукталу кирәк.

Башлап шуны искәртик: Алтын Урда таралганнан соң барлыкка килгән татар ханлыкларында аларның сәяси нигезен тәшкил иткән карачы бәкләр бирүче 4 кабилә системасында һәр кабилә аерым биләмә (бәйлек) тәшкил иткән һәм ул биләмәләрне шул кабиләләрнең лидерлары (титуллары – бий, бәй, бәк) җитәкләгән. Билгеле, кабилә лидеры берәү генә була ала. Шуның өстенә, һәрбер кабиләдә аны җитәкләүче затлы нәселнең тарихы, ким дигәндә, Чыңгызхан дәвереннән башланып (карагыз: [Дәфтәре: 2011]), башка нәсел вәкилләре белән алмаштырыла алмаган. Моның шулай икәнлеген Идегәй нәселенең, ягъни, мангыт кабиләсе лидерларының дәвамлы һәм шактый яхшы билгеле булган тарихы бик ачык күрсәтә. Әмма, нәсел дәвамчылыгы мәсьәләсенең бер нечкәлеге бар – әгәр дә кабилә бүленеп төрле дәүләтләргә таралса (Алтын Урда җирлегендә бу еш кына шулай булган да), хөкем итүче бәкләр нәселе дә шул кабилә кисәкләре белән бүленеп чыгып, яңа урыннарда аерылган төркемнәрнең башларына басканнар. Аргын кабиләсе мисалында без мондый хәлне инде күрдек – Туктамыш ханнан һәм аның улларыннан соң тәхеткә килгән Олуг-Мөхәммәд дәверендә ул кабиләнең бер өлеше Кырымда кала, ә икенче бер төркеме элекке кабилә лидеры Кара-хуҗа бәк җитәкчелегендә Казан якларына күчә. Билгеле, мондый бүленгән нәсел аксөякләре арасында туганлык җепләре сакланган һәм аларның шәҗәрәләре, дәүләт чикләреннән чыга торган үзара элемтәләре аркылы, бу нәсел вәкилләре әлеге туганлык турында хәбәрдар булганнар. Шуңа күрә дә аерым ханлыкта хөкем итүче карачы бәкләр белән бәйле кабиләләрдәге лидерларның нәселе өзелсә (мәсәлән, ир җенесеннән булган балалары калмаса), шул ук нәселдән һәм кабиләдән булган аксөякне башка ханлыктан китереп бәклеккә билгели алганнар (моның өчен ханнарның карары

кирәк булган). Билгеле, мондый очракта карачы бәкләр бирүче кабилә лидерының төп варислары түгел, ә улларының яисә башка туганнарының балалары арасыннан берсен сайлап алып читкә җибәргәннәр. Ягъни, бу шәхескә чынлыкта үзләрендә «урын» биләү – бәклек статусын алу – мөмкинлеге булмагач, ул «артык» аксөяккә әйләнгән. Моңа тагы өстәп әйтергә кирәк – Кырым ханлыгы тарихыннан безгә мәгълүм: һәрбер солтанның үз сарае һәм аңа бәйле аксөякләре булган, шул исәптән, карачы бәкләр нәселеннән дә. Алар бу солтан белән ул тәхеткә килсә, югарырак дәрәҗәгә дә күтәрелә алганнар. Әгәр дә ул солтан башка дәүләткә китеп хан дәрәҗәсенә ирешсә, аның янындагы аксөякләр аның белән бергә китеп тә бара алганнар. Мондый үзгәрешләр хан алмашкан вакытта да була алган. Онытмыйк: Алтын Урданың варислары булган барлык татар ханлыкларының җирләре «Алтын урук» вәкилләренең, ягъни Чыңгызыйларның, һәм аларга «беркетелгән» карачы бәкләр бирүче кабиләләрнең уртак биләмәләре саналган. Бигрәк тә бу уртаклык Кырым, Касыйм һәм Казан ханлыкларына карый, чөнки нәкъ менә шуларда бер үк нәсел Чыңгызыйлар (Туктамыш хан нәселе) һәм бер үк төркем кабиләләр (аргын, барын, шырын, кыпчак) хөкем иткәннәр.

Әйткәннәрдән чыгып, без шундый гипотеза формалаштыра алабыз: Чура батырның «артыклыгы», бәлки, аның Али (Гали) бәйне үтерүе белән генә бәйле булмагандыр. Чөнки дастан буенча ул аңарчы да Идел тарафына китеп йөри, аның атасы да каядыр далада казак булып ала. Бу мәгълүмат Нарык батырның һәм аның улы Чура батырның аргын кабиләсе лидерлары нәселенә бәйле булсалар да, бәлки аларның «өлкән» тармагыннан булмыйча, яисә, сәяси сәбәпләр нәтиҗәсендә (мәсәлән, хан алмашудан) ул статусларын югалткан булулары турында сөйләми микән? Шундыйрак юнәлештә фикерләү өчен берничә нигез бар. Беренчедән, Чура батырның Идел-Урал буйларында язып алынган һәм алда китерелгән шәҗәрәләрендә аның башка ир туганнары да булганлыгы күренә. Икенчедән, Кырымда язып алынган «Чорабатыр» дастанында Нарикның Арик исемле агасы булуы турында әйтелә [Къырымтатар: 1991. 57 б.]. Ә бу бит – «өлкәнрәк» буын вәкиле. Кырымдагы аргын кабиләсе бәкләренең башка тармагы булганлыгы турында Кырым ханлыгы җирлегендә яшәгән, инде китерелгән Кара-Коджа бәктән башланган шәҗәрә дә сөйли. Казакълар арасында язып алынган һәм русчага тәрҗемәдә сакланган «Тама» төркеменә багышланган дастанда да бертуган өч шәхес атала: өлкәне – Кариббай (Кара би?), уртанчысы – Нарикбай (Нарик би), кечесе – Исым бий [Сборник. Т. IV: 1895. С. 2]. Күренә ки, монда да Чура батырның атасының ике ир туганы (берсе олырак, икенчесе кечерәк) атала. Әмма, башка бер казакъ телендә сакланган шул ук «Тама» даста-

нында бу исемнәр, нишләптер, искә алынмыйлар (карагыз: [Батырлар жыры: 1989. 271–285 бб.]). Шуңа да карамастан, без югарыда китерелгән информацияне, шул исәптән, Кырым ханлыгы буенча билгеле тарихи чыганаклардан чыгып та, алга таба кулланырга тиешбез. Мәсәлән, инде әйтелеп үтелгәнчә, 1519-нчы елны Кырымда берьюлы ике аргын кабиләсеннән булган аксөяк – Али-Шукур һәм Корбан-Али «князь» титулы белән билгеләнә. Шулар ук 1524-нче елга караган Кырым ханлыгы аксөякләре исемлегендә дә күренәләр [Малиновский: 1863. С. 115]. Ә бит аларның берсенең – Али Шукур бәкнең – исеме Кырымдагы аргын кабиләсе бәкләренең Кара Коджа бәктән башланган шәҗәрәләрендә бар. Димәк, бу очракта сүз 1519, 1524-нче еллардагы документларда шушы кабилә лидеры турында бара. Әгәр дә мондый нәтиҗәдән чыгып эш итсәк, ул вакытка кабилә лидеры Али-Шукурның замандашы Корбан-Али бәкнең («князьнең») статусын ничек билгеләргә соң, аны бит аргын кабиләсенең башлыгы дип карап булмый, чөнки берьюлы ике шәхес кабилә бәге урынында утыра алмый. Ахрысы, Корбан-Али «бәк» титулын башка юл белән алган. Әйтик, ул үзе яисә аның атасы Кырымга башка ханлыктан инде «князь» (бәк) титулы алганнан соң килеп төпләнгән була ала. Һәрхәлдә, мондый гипотезага урын бар. Әйтергә кирәк, ул ханлыклар астында Казан, яисә Касыйм биләмәләре күз алдында тотылырга мөмкин. Ничек кенә булмасын, безгә яңадан Кырым һәм Казан ханлыклары җирлегенә кире кайтканда китерелгән фикерләрне истә тотарга кирәк. Сүзне Казан ханлыгыннан башларга туры килә, чөнки инде алда әйтелеп үткәнчә, нәкъ шушы биләмәдә 1521-нче елдан башлап тәхеткә Гәрәйләр династиясе вәкилләре утыртыла: 1521–1524-нче елларда анда хан тәхетен Сәхиб-Гәрәй, аннан соң аның энесе Сафа-Гәрәй 1524–1531, 1533–1546, 1546–1549-нчы елларда аерым өзеклекләр белән билиләр. Бу уңайдан мондый фикер туа: беренче тапкыр Казан ханлыгы җирләрендә 1526-нчы елны күренгән Чура б. Нарык шушы Гәрәй династиясе вәкилләре белән килеп чыкмаган микән монда? Бик мөмкин, бигрәк тә ул Кырымда «артык» булган булса һәм аның атасының (яисә бабаларының) Казан йортында электән дә биләмәләре яшәп килсә. Чура батырга караган дастанның кайбер урыннары моңа ишарә ясыйлар. Әйтик, Чура батырга багышланган Добруджа (Буджак) татарларында һәм казакъларда язып алынган дастан версияләрендә геройның атасының биләмәсе итеп «Казан» күрсәтелә. Дөрес, соңыннан ул, ниндидер сәбәпләр аркасында, Кырымга килеп төпләнә (бу версия казакъларда күренми). Менә бу Нарык батырның бер дәвер «Казанда» яшәгәнлеге турындагы информацияне без игътибардан читтә калдыра алмыйбыз. Дөрес, конкретлаштырылмаган мондый сюжет артында Казан ханлыгы җирлегендә аргын кабиләсенең

аерым биләмәсе (бәклеге) булуы турындагы гомумиләштерелгән информация да ятарга мөмкин. Ә андый биләмә бар икән, аның башына Казанда династия алмашынганда (Гәрәйләр тәхеткә килеп утырганда) Кырым ханлыгыннан андагы аргыннар арасыннан чыккан затлы аксөяк тә китереп куела алган, моны истә тотарга кирәк. Шуны да онытмыйк: 1487–1518-нче еллар арасында Казанда тәхет өчен барган көрәшләрдә (анда 1496-нчы елны Шибанид Мамук та катнаша) төрле ханнар белән бәйле төп кабилә лидерлары «урынсыз» калган булырга бик тә мөмкиннәр. Бәлки шул дәвердә Чура батырның атасы Нарык яисә аның бабасы Казан ханлыгыннан читкә китеп барырга мәҗбүр булгандыр. Әйе, бу бер фараз гына, ләкин буш урында ясалган гипотеза түгел. Тагы бер тарихи фактны истән чыгармыйк – 1515-нче елны Кырым ханлыгы тәхетендә озак еллар утырган Меңгли-Гәрәй үлгәч властька килгән аның улы Мөхәммәд-Гәрәй, 1523-нче елны Хаҗитарханда зур җиңүләрдән соң мангыт кабиләсе аксөякләре тарафыннан көтелмәгәндә үтерелгәч (карагыз: [Смирнов: 2005. Т. I. С. 299–300]), Кырымда сәяси тотрыксызлык килеп чыга. Бәлки, кайбер мондагы аксөякләрнең читкә китүләре өчен дә бу вакыйгалар сәбәп булгандыр. Һәрхәлдә, Чура батырның атасы Нарыкның бер дәвердә «Хаҗитархан шәһәренә» килүе турындагы дастандагы хәбәр юкка гына булмас.

Шулай итеп, Чура б. Нарык Казан ханлыгында төпләнә һәм «Казанская история» исемле рус чыганагы аның турында ул «волостель», «воевода» һәм «большой князь» иде, дип белдерә. Хәзер без бу төшенчәләрнең чын мәгънәләрен ачып сала алабыз.

«Волостель» – һичшиксез, бу термин артында төрки телдәге «олыс / улыс / улус» сүзе ята (әйтелгәнчә, русчадагы «волость» сүзе дә шуннан ясалган булыр). Аңлашыладыр, «волостель» ул «улыс биләүче» булып чыга. Димәк, чынлыкта нәкъ шушы төшенчә Чура батырның Казан ханлыгында булган бер олысны, ягъни бәйлекне (бәклекне) биләгәнлеген күрсәтә. XVI–XVII-нче йөзләрдә, инде руслар Казан ханлыгын буйсындыргач, ул биләмә «Галицкая дорога (даруга)» дип аталган. Аның сәяси үзәге чиратлап Казаннан ерак булмаган Караби (Караваево) һәм Кара-Хуҗа, Җәке авылларында булган, дип уйлый алабыз. Иделнең сул ягында (уң ягындагы чикләрен әлегә төгәл билгеләп булмый) бу биләмәнең чикләрен якынча чамаларга була [Исхаков: 1998. С. 42–56].

«Большой князь» – төшенчәсе турыдан-туры төрки-татар теленнән алынган «олы / олуг бәк / бий», яисә Кырым ханлыгы өчен хас «баш карачы [бәк]» [Inalcik: 1979–80. P. 447] терминыннан калька булып тора. Димәк, бу атама Чура б. Нарыкның Казан ханлыгында карачы бәк булганлыгын раслый. Тагы шунысы да читтә калмасын: Кырымда ике кабилә

бәкләре – Шырын һәм Барын лидерлары, калган икесеннән (аргын һәм кыпчак кабиләләреннән) өстенрәк саналган [Сыроечковский: 1940. С. 29; Manz: 1987. P. 286]. Бу исә борынгы традиция белән бәйле булса кирәк. Казан ханлыгында да шул ук хәл күзәтелгәнме – бусы билгеле түгел. Әмма, Чура Нарыков кул астында булган гаскәриләр саныннан чыгып карасаң (алга таба сөйләнәчәк ул турыда), монда да аргыннар икенчел дәрәҗәдә булганнар, дип уйлый алабыз.

«Воевода» – безнең фикеребезчә, бу төшенчәнең төрки эквиваленты – «батыр» дигән сүз. Ләкин аның шулай икәнлеген раслау өчен безгә кайбер Кырым ханлыгына кагылган тарихи чыганакларга күз салу кирәк. Иң башлап, игътибарны үзенә җәлеп иткән мондый информация бар: 1508-нче елны Кырым ханы Меңгли-Гәрәйнең Мәскәүгә җибәрелгән хатында (ул рус теленә тәрҗемәдә генә сакланган) 4 «князь», ягъни, карачы бәкләр турында (Ширин Агиш, Барын Давлет, Аргын Мардан һәм Кыпчак Магмуд), «воеводы князи» дигән аңлатма бар [Малиновский: 1863. С. 185]. Китерелгән төшенчә «Идегәй» дастанындагы «Орыш бие Шырын» [Идегәй: 1988. 221 б.] сүзтезмәсенә мәгънәви яктан туры килә һәм бу бер дә юкка гына түгел, чөнки карачы бәкләр җитәкчелегендәге «кабилә гаскәрләре» татар ханлыкларында гвардия ролен үтәгәннәр һәм дәүләтнең хәрби көченең үзәген тәшкил иткәннәр. Шуңа күрә дә карачы бәкләр белән аларның кабиләдәшләреннән (гадәттә, 10–12 мең профессиональ сугышчылардан) торган гаскәри төркем ниндидер сәбәпләр аркасында ханга каршы чыкса, ул хөкемдар бернәрсә дә эшли алмаган (карагыз: [Инальчик: 1995. С. 76–77]). Чура батырга багышланган дастаннардан да мондый үзенчәлек бик ачык күренә – бу затлы татарның төп «һөнәре» сугыш белән шөгыльләнү булган. Сакланып калган рус чыганаклары да шул турыда сөйлиләр. Алардагы бер хәбәрдән (1540-нчы елга карый) Чура Нарыковның 8 мең кешелек гаскәр башында торганлыгы күренә, ләкин ул яуда татарлардан башка марилар һәм чувашлар да катнашкан, шунлыктан, аның татар өлешенең саны азрак булган булса кирәк. Кайбер Чура батырга багышланган казакъларда язып алынган дастан версияләрендә аның герое һәм атасының кече энесе Исым бий, шулай ук безгә билгесез Тосан мурза, җитәкләгән гаскәрнең саны 6 мең сугышчыдан тора иде дип билгеләнә [Сборник материалов: 1895. Т. IV. С. 86]. Чынлыкта исә реаль Чура бәкнең сугышчылары саны ул кадәр үк күп булмаган дип уйларга урын бар, чөнки «Казанская история» аның Казаннан качып китү эпизодын сурәтләгәндә аның белән 1000 «сугышчы» һәм 500 «хезмәтче коллары», ягъни, тулаем 1500 кешелек хәрби берләшмәсе булуы турында сөйли [Казанская история: 1954. С. 81]. Алда Кырым ханлыгы буенча да шуңа охшаган сан күренгән иде – 1543-нче

елны берләштерелгән аргын һәм кыпчак кабиләләренең яуда катнашкан гаскәриләре саны 3000 кеше булганлыгы турында әйтелде. Әгәр дә без фараз буларак бу ике кабиләдән бертигез санда сугышчылар чыгарылган дип уйласак, Чура батыр гаскәренең Казан ханлыгындагы саны килеп чыгачак.

Шулай итеп, Чура Нарыков чынлап та «воевода» – «батыр», булып чыга. Аның «ир» дип аталуы да шул ук мәгънәгә ия, чөнки бу төшенчәнең дә эчтәлеге шундый ук (карагыз: [Орлов: 1945. С. 8]).

Чура батыр турында тупланган яңа мәгълүматка таянып, хәзер аның якты дөньядан китүе эпизодына да кире кайта алабыз. Әйтелгәнчә, бу мәсьәләне тикшергәндә без тарихи чынбарлык белән легендар (эпик) тасвирлау арасындагы аермалык белән очрашачакбыз. Әгәр дә шушы аермалыкның асылына төшенә алсак, без Казан ханлыгы егылу дәверендәге татар җәмгыятенең этник аңын, тарихи фикерләүен күзаллый алачакбыз. Нәкъ менә шулвакытта «Чура батыр» дастанына салынган киләчәк буыннарны «кисәтүнең» төп мәгънәсе дә аңлашылачак.

### § 4. Чура батырның үлеме һәм киләчәк буыннарны кисәтү

Чура Нарыковның үлүе мәсьәләсе тирәсендәге легендар һәм мифологик катламнардан арынып тарихи чынбарлыкны торгызу өчен башта яңадан рус чыганакларына мөрәҗәгать итү кирәк булачак. Ләкин бу очракта ул чыганакларны, алдарак ясалган анализлардан аермалы буларак, бик конкрет тикшерергә кирәк. Ә бу тикшерү исә Чура батырга багышланган дастан версияләреннән һәм тарихи легендалардан башка мөмкин түгел, чөнки бүгенгә билгеле булган рус чыганакларының безне кызыксындырган проблема буенча информацион мөмкинлекләре бик чикле.

Алдарак без Чура Нарыковның үлүе турында хәбәр иткән ике рус чыганагына – «Патриарх (Никон) елъязмасына» һәм «Казанская история» («Казанский летописец») исеме астында билгеле булган «тарихи повесть» жанрына кагылган, 1564–1565-нче елларда язылган әсәргә игътибар иткән идек инде. Хәзер исә алардагы мәгълүматка әйләнеп кайтып, элегрәк читтәрәк калган мәсьәләләргә дә тукталу кирәк.

Әйтик, аларны тикшергәндә ясалган беренче нәтиҗә – Чура Нарыковның үлеменең 1546-нчы елның июль ае урталарына (бусы безнең фараз иде, ул алга таба бераз төзәтелергә тиеш) туры килүе һәм аның Казан ханлыгы тәхетенә кире кайткан Сафа-Гәрәй тарафыннан үтерелүе турында иде. Бу информациянең «Патриарх (Никон) елъязмасына» килеп керүе, андагы хәбәрдән күренгәнчә, 1547-нче елның 20 сентябренә карый һәм ул хәбәр Мәскәү Бөек кенәзлегенә Казан ханлыгыннан эмиграциягә киткән бер төркем (76 кеше) татарлар тарафыннан алып киленә. Ягъни, хәбәрнең елъязма битләренә эләгүе белән реаль вакыйга арасында инде

бераз вакыт үткән булган. Әмма, хәбәрне җиткерүчеләр арасында Чура Нарыковның энеләре дә булуын истә тотсак, аның Сафа-Гәрәй хан карары белән үтерелүенә (күргәнебезчә, ул вакытта башка затлы татарлар да җәзалана) шөбһә калмый, чөнки аларның мәскәүлеләрне бу мәсьәлә буенча алдаулары өчен бернинди объектив сәбәп тә күренми.

Шулай булса да, «Казанская история» әсәрендә беркадәр уйландыра торган башка бер информация бар. Нәрсә күз алдында тотыла соң бу очракта? Әйтелгән чыганактан күренгәнчә, Шаһали качып киткәндә (исегезгә төшерик, аңа нәкъ шулчакта Чура Нарыков ярдәм итә), аның боерыгы буенча оештырылган зур бәйрәм (җыен булса кирәк) вакытында исереп, йоклап яткан «казанлыларның» 20 аксөяге («большие вельможи») үтерелә, ә 20 шундый ук дәрәҗәле аксөякне ул үзе белән бәйләп-богаулап алып китә [Казанская история: 1954. С. 81]. Иртәгесен, хан сараена килгән татарлар анда үлеп ятучыларны күргәч, ханның качып китәнлеген аңлап алып, Шаһали артыннан куа чыгалар, аны тота алмагач, үзара каршылыкка килеп, бер-берсе белән сугышалар һәм, ахыр чиктә, килеп чыккан хәлдә Чура Нарыковны гаепле башлыйлар, әмма, аның батырлыгын һәм акылын танучылар да Казанда әле җитәрлек була [Казанская история: 1954. С. 82]. Шушы вакыйгалар барганда, бу чыганак буенча, ул Шаһали ханнан соң 10 көн үткәч, үзенең биләмәсендәге авылларына ялга китәм, дигән булып (җәй көннәре бит!), Мәскәү ягына зур төркем белән кача һәм алдан сөйләшенгәнчә, билгеләнгән урында Шаһалине көтә башлый. Менә шул вакытта Чура Нарыковның качканлыгын аңлап алып, аны куа чыккан казанлылар бу бәкнең лагерена барып җитәләр. «Казанская история» алга таба сөйли: «...казанцы ...догнавше (Чураны – Д. И.). Он же, обострожася в месте крепце, чаяхся отбити от них; и бившеся с ними долго. И убиша храброго своего воеводу Чюру Нарыковича с сыном его, и со всеми отроки его...» [Казанская история: 1954. С. 82]. Игътибар итегез, тасвирланган эпизодта Сафа-Гәрәй турында бер сүз дә юк, әмма казанлылар гаскәренең аз санлы булмаганлыгы ачык. Әгәр дә «Казанская история» авторы бу дәвердә Казан ханлыгында яшәгән булса, ни өчен ул Чура Нарыковның үлеме турында сөйләгәндә Сафа-Гәрәй турында бер сүз дә әйтми? Гомумән, Сафа-Гәрәй Чура батырның гаскәре белән сугышта катнашканмы соң?

Бирелгән сорауларга җавап бирү җиңел түгел. Әгәр дә «Патриарх (Никон) елъязмасына» мөрәҗәгать итсәк, 1546-нчы елның 13 июнендә Казанда тәхеткә китерелгән Шаһали анда бер ай гына утырган булгач, аның качып китүе, инде әйтелгәнчә, июль аеның урталарына туры киләчәк [ПСРЛ: 1965. Т. 13. С. 148] һәм ул качканда казанлылар инде Сафа-Гәрәйне «Кама елгасы буена» кайтарган булганнар [Шунда ук]. Әйт-

кәнебезчә, «Казанская история» буенча, Чура батыр Шаһалидән 10 көн соңга калып юлга чыга. Аңлашыла ки, ул 10 көн эчендә Сафа-Гәрәй Казанга кереп урнашырга тиеш булган – тәхет бит буш, ә «казанлылар» исә бу ханны үзләре кире тәхеткә чакырганнар. Димәк, вакыйганың гомуми агышын истә тотсак, Чура Нарыков һәм аның тарафдарлары Шаһалине тәхеткә китергән өчен кире әйләнеп кайткан хан каршында җавап бирергә тиеш булып чыгалар. Шунлыктан, «Казанская история» әсәрендәге бу безне кызыксындырган затлы татарның үлеменә багышланган эпизодны, игътибарга лаеклы аерым детальләре булса да, тулы түгел дип санарга туры килә, һәрхәлдә, анда тасвирланган вакыйгаларда Сафа-Гәрәйнең бер роле да булмауы шөбһәле.

Чынлыкта менә шул тулы булмаган информациягә өстәмә, татарларда сакланган кайбер тарихи легендалар эчендә бар. Әйтик, Карауҗа авылы белән бәйле югарыда карап үтелгән шәҗәрәле тарихта «Чура би» турында мондый юллар бар: «...Чура бине Казан ханына хыянәте өчен (игътибар! – Д. И.) авызына эретелгән көмеш (алтын) салып үтерәләр. «Менә сиңа җитмәгән иде байлык, ал!» – дип. Чура би Мәскәү патшасына серләрне саткан була. Аның кабере Зур Караужа авылының яңа зиратында» (карагыз: [Әхмәтҗанов: 1995. 34 б.; Татар халык иҗаты: 1987. 160 б.]). Күренә ки, монда исеме аталмаган «Казан ханы» турыдан-туры булмаса да Чура бинең үлеменә сәбәпче булып тора. Ахрысы, «Казанская история» әсәрендәге вакыйгаларда Сафа-Гәрәй катнашкан булса кирәк. «Патриарх (Никон) елъязмасындагы» Чура Нарыковның үлеме турындагы эпизодта да игътибарга лаек бер деталь бар: аның белән бер үк вакытта «Казанда» хан (ягъни, Сафа-Гәрәй) Баубек һәм Кадыш исемле «князьләрне» генә түгел, ә «күп кенә башкаларны да» («иныхъ многихъ») үтерә («побилъ») [ПСРЛ: 1965. Т. 13. С. 149]. Ә бу исә «Казанская история» әсәрендәге бер урынга туры килә, чөнки качып киткән Чура Нарыков белән аның үз кешеләре (1500 сугышчы) генә түгел, ә башка затлы татарлар да искә алына: «...и присталых к нему – со всем богатством князеи, з женами и з детми» [Казанская история: 1954. С. 82]. Димәк, Казаннан читкә китеп баручылар арасында Чура батырдан тыш башка аксөякләр дә булган һәм алар «Казанская история» артыннан барсак, Казанда түгел, ә аннан читтә, аларны Сафа-Гәрәй җитәкчелегендәге гаскәр куып җитеп, сугышкан вакытта үтерелгәннәр булса кирәк.

Шулай итеп, Чура батыр улы белән бергә 1546-нчы елның июлендә (ахрысы, аның урталарында түгел, ә бераз соңрак, айның егерменче көннәрендә) Казаннан читтә, бәлки, үзенең резиденциясе булган Караужа авылы тирәләрендә, хан гаскәре белән бәрелеш вакытында һәлак була. Реаль тарихи вакыйга менә шулай барган.

Ә нәрсә сөйли соң бу турыда Чура батырга багышланган дастаннар? Аларда дастан героеның үлеме эпизоды бөтенләй башкача сурәтләнә (югарыда карагыз). Ул турыда инде сөйләнгәнлектән, безгә хәзер Чура батырның үлүенә багышланаган төрле версияле дастанның кайбер нюансларына гына тукталып китү кирәк.

Идел-Урал буе татарларына хас «Чура батыр» дастанында аның герое рус гаскәрләре һәм аларның эчендә булган үз улы белән сугышта үлә (төгәлрәге, шул сугыш вакытында суга бата). Ягъни, монда Чура батыр героик рәвештә Казанны саклап мәрхүм була. Кырым татарларында язып алынган «Чорабатыр» дастанында да аның герое «Казан ханының сараена» кайткач, анда «Сары ханымга» өйләнә, тегесе бераздан аннан аерыла һәм дошманнар ягына чыга, аннан туган бала үсеп житкәч, ул Чура батыр белән сугышта катнаша һәм алар икесе бергә алышкан вакытта суга батып үләләр [Къырымтатар: 1991. 72 б.]. Бу дошман гаскәренең кемлеге, аның этник йөзе бу очракта дастанда ачык күренми, әмма әсәрнең ахырында әйтелә: «Чорабатыр сувгъга баткъан сонъ, Къазанны рус чары ала», – дип [Къырымтатар: 1991. 72 б.; Образцы: 1896. Ч. VII. С. 132]. Димәк, бу очракта да Чура батыр рус гаскәрләре һәм үз улы белән сугышта үлә, дип уйлый алабыз. Добруджа (Буджак) татарларыннан язып алынган дастанда Чураның турыдан-туры кем белән сугышып үлгәне әйтелми, ләкин ул Казанга китеп барганда аны «казаклардан», димәк, беренче чиратта, кырым татарларының һәм нугайларның православ динле дошманнарыннан, саклау өчен барганлыгы әйтелә [Чура Батыр: 1993. 54 б.], аннан соң бик зур яуның Казан каласының астына дары салып, аны шартлатуы турында сөйләнә дә, ялгыз калып дошман белән кылычка-кылыч килеп аңа каршы торган батырның бу гаскәргә әсирлеккә эләкмәс өчен текә ярдан аты белән Иделгә сикерүе тасвирлана. [Шунда ук. 60 б.]. Күренә ки, монда да Чура батырның рус яуы белән сугышта үлүе турында бара бит сүз. Нугайларның «Шора бaьтир» дастанында да әйтелә: «... Казан уьстине яв келди. Бу согыста Шора бaьтир йигитлерше согысып, Карагер аты ман Эдил сувына батып оьледи», – дип [Ногай халк: 1969. 79 б.]. Бу версия Добруджа (Буджак) татарлары версиясе белән тулаем туры килә, шулай булгач, монда да Чура батыр «егетләрчә» сугышып үлгән. Дошман, ул турыда дастанада ачык әйтелмәсә дә, рус яуы булып чыга.

Ә менә казакъларда таралган «Шора» дастанында эш башкачарак тора: «Казан ханы кызын хатынлыкка алгач, Чура үзенең дусты Колыншак белән калмыкларга каршы сугыша һәм бер бәрелештән соң алар үзара сөйләшеп утырганда Чураның әрвахы турында сүз чыгып, ул аждаһа (айдаһар) елан кыяфәтендә килеп чыгып, аңа Колыншак (Колынчак) батыр кылычы белән кизәнгәч, ул юк булды һәм шул ук вакытта Чура-

ны җир йотты, ул шулай югалды», – дип әйтелә бу дастанда [Батырлар жыры: 1989. 368–369 бб.]. Димәк, казакъларда Чура батырның дошман белән сугышулары турында әйтелсә дә, ул дошманнар заманында казакъларга зур зыян китергән калмыклар белән бәйләнелә, ә дастан героеның үлеменә героик төсмер бирелми. Әмма монда да бер уйландыра торган мифологик «эз» бар төсле – озак яшәгән елан – ә мифологик аждаһа елан шундый җан иясе була да инде ул: кайбер борынгы ышанулар буенча, хатын-кыз затына әйләнә алган (татарларда – юха еланга). Шуңа күрә дә казакъларда сакланган бу Чура батыр белән бәйләнгән мифологик образ аның хатын-кыз аркылы үлгәнлегенә ишарә түгел микән, дигән уй килә башка. Дөрес, бу бер фараз гына, моны исбат итеп булмый, шуның өстенә казакълардагы дастан вариантларында Чураның улы турында бер сүз дә юк. Әмма барыбер әйтелгән фикергә урын бар төсле.

Шулай итеп, Чура батырга багышланган дастаннарның күбесендә аларның төп герое дошманнар (беренче чиратта, руслар) белән бик нык Ватан өчен көрәшеп, трагик рәвештә һәлак була. Нәкъ менә шушы бәяләү аркылы без урта гасыр татарларының Казан ханлыгын руслар тарафыннан яулап алулары алдыннан яшәп килгән этник аңнарына реконструкция ясый алабыз: безнең ерак бабаларыбыз татарлар арасындагы үзара каршылыкларны күрергә, аларны таныргa теләмәгәннәр, хәтта Чура Нарыковның үлеменә дә дастанда бөтенләй тарихи вакыйгаларга туры килмәгән, әмма ул вакытның төп рухын чагылдырган төсмер биргәннәр һәм ул дәвер өчен мондый карашлар, кайбер документаль чыганаклардан күренгәнчә, чынлап та хас булган. Мәсәлән, Казан ханлыгының соңгы бөек сәййеде булган Кол-Шәрифнең (Шәриф Хаҗитарханиның) «Зафәрнамәи вилаяте Казан» исеме астында билгеле булган 1550-нче елда язылган һәм төрек солтанына юллаган хатында мондый сүзләр бар:

*Шәрифи, китмә бу йирдән, газа өмидегәр булса,*
*Бу көндин соң дигәйләр кем, будыр сахиб Казан шәһре*
[Кол Шәриф: 1997. 80 б.].

Бу, кәферләргә каршылык күрсәтергә кирәк, дигән сүзләрне раслап, Кол Шәриф, руслар 1552-нче елны Казанны алганда, үзенең яраннарын җитәкләп, ахыргача яулап алучылар белән сугыша, мәдрәсә түбәсендә булган соңгы алышуда үтерелә, аның гәүдәсе шуннан җиргә килеп төшә (Казанда аның мәетен соңыннан кенәз Андрей Курбский күрә). Югарыда әйтелгән карашлар хәтта «Казанская история» эченә дә үтеп кергән, чөнки Чура Нарыков турында ул әсәрдә мондый юллар бар: «...Инии же почиташе Чюру за храбрость его и за высокоумие его во всем граде» [Казанская история: 1954. С. 82]. Шуны әйткәннән соң, бу әсәрнең

авторы, Чура батырның ни өчен үлгәнлеген бик яхшы аңлап, өстәп куя: «...И несть болши сея любви ничтоже, аще кто за друга (димәк, Шаһали өчен – Д. И.) душу свою положит или за господина» [Шунда ук].

Әмма, халык чынлыкта Чура Нарыковның ничек үлгәнен белгән – ул турыда алда китергән Караужа авылы белән бәйле легендар тарих бик ачык сөйли. Димәк, аргын кабиләсе бәге Чура б. Нарыкны дастанда геройлаштыру XVI-нчы йөз урталарындагы татар җәмгыятенең төп психологик халәтенә туры китерелеп тудырылган. Ә бу исә данлы тарихка ия булган татарларның соңгы героик образларын тудырулары иде. Шул заманнардан соң татарларда үзәгендә мондый «батырлар», ягъни карачы бәкләр нәселеннән булган кабиләләр белән бәйле хәрби җитәкчеләргә багышланган башка дастаннар инде бүтән тумаган, чөнки заманалар да үзгәргән, ханлыклар юкка чыккач, андагы исән калган аксөякләр дә «йомышлылар» рәтенә кереп, элекке дошманнарына хезмәт итә башлаганнар. Шуңа күрә дә татарларда (казакъларда һәм нугайларда эш башкачарак торган) алдагы дәвердә урта гасыр өчен хас «батырлыкларга» урын калмаган.

Инде «Чура батыр» дастаны эченә салынган киләчәк буыннарны «кисәтү» мәсьәләсенә дә килеп җиттек. Чынлыкта, мондый «кисәтү» бу дастанның кайбер вариантларында гына бар һәм ул, безнең фикер буенча, Идел-Урал буйларындагы тарихи чынбарлык белән нык бәйле. Язмабызның алдагы өлешендә күрсәтелгәнчә, Чура батырның үлеме аның башка милләт (рус) хатыныннан туган улы аркылы булган, дип сөйләнә «Чура батыр» дастанында. Ләкин, Идел-Урал буе татарларыннан тыш яшәгән дастанның башка милли версияләрендә бу сюжет юк. Кырым татарларында гына исеме әйтелмәгән «Казан ханының» кызы Сары ханым (ул «Сарыкани» буларак Идел-Урал буе татарлары вариантларында Шаһали кызы булып та йөри [Татар халык иҗаты: 1984. 115 б.]), инде әйтелгәнчә, Чурага иргә чыгып, аннан соң аннан аерылып, дошман ягына күчә һәм аның үсеп җиткән улы дошманнар арасында үсеп, бер «батыр» буларак, әтисе белән сугыша [Къырымтатар: 1991. 72 б.]. Ахрысы, бу очракны да без Шаһалинең руслар белән союзда булганлыгын чагылдыру дип кабул итәргә тиешбез. Ләкин башка очракларда Чура батырның үз хатыны (Сылубикә, Алтын) я Кырымда кала [Татар халык иҗаты: 1984. 118 б; Чура Батыр: 1993. 51 б.; Ногай халк: 1969. 74 б.], яисә бу батыр Казанга барып, анда Әделшә исемле ханның Ханжан атлы кызын хатынлыкка алуны планлаштыра гына [Батырлар жыры: 1989. Т. 5. 352 б.]. Ничек кенә булмасын, беренче чиратта без Идел-Урал буе һәм беркадәр Кырым ханлыгының варислары арасында таралган Чура батырның үлемен рус хатыныннан яки руслар белән бәйле татар ханы кызыннан туган, атасына дошманга әйләнгән оглан аркылы күрүне алга чыгарырга тиешбез.

Чынлыкта бу сюжет Казан ханлыгы егылгач килеп туган актуаль хәлләргә татар җәмгыяте ягыннан барлыкка килгән бер реакция булса кирәк, чөнки нәкъ шул дәвердә затлы татарлар күпләп руслар ягына чыгалар, аларга әсирлеккә төшәләр һәм тиз арада чукындырылып (беренче чиратта христианлаштыру сәясәте карачы бәкләргә һәм Чыңгызыйларга карата алып барыла [Исхаков: 1998. С. 233–234]), рус хатыннарына өйләнделәләр, димәк, гаиләгә чит күзәтүчеләр һәм башка дин тоткан кяферләр кертелә. Тикшерелә торган дастан шул турыда кисәтә дә – катнаш гаиләдә туган бала Ватанның сагында торган батыр атасының башына җитеп, илне яклаучысыз калдыра ала, дигән фикер үткәрелә «Чура батыр» эпосында. Бу – безнең урта гасырда яшәгән бабаларыбыздан киләчәк буыннарга җибәрелгән бик әһәмиятле, хәзерге дәвергә кадәр килеп җиткән хәбәр [Paksoy: 1986]). Аның турында татарларга һич кенә дә онытырга ярамый икәнлеге XXI-нче гасыр биеклегеннән бигрәк тә яхшы күренә.

## § 5. «Чура батыр» дастанының ачыкланмый калган яклары

Сезнең алдыгызда яткан язма өстендә эшләгәндә күпме генә тырышсак та, тикшерелгән дастанның барлык тарихи серләрен дә ачып бетереп булмады. Беренче чиратта моны, билгеле, ышанычлы чыганаклар җитәрлек булмау белән аңлатырга кирәк. Шуңа күрә дә без язмабызның соңгы өлешендә «Чура батыр» эпосындагы кайбер, әлегә томан астында калган, тарихка кагылышлы мәсьәләләрне күрсәтеп китәргә булдык. Бәлки алар турында башка тикшерүчеләр дә уйланырлар һәм фәнни эзләнүләре вакытында ул сорауларга да җаваплар табарга тырышырлар, дигән ышаныч белән яздык хезмәтебезнең бу өлешен.

1. Чура батырның атасы Нарык (Нәрик, Нәррән) батырның шәҗәрәсен тикшерү эшен дәвам итәргә кирәк булачак, чөнки XV-нче гасыр башында яшәгән Кара-хуҗа бәк белән Нарык арасында ким дигәндә 3–4 буын булырга тиеш, алар исә фәкать тик нугай һәм Добруджа (Буджак) татарларының дастаннарында гына сакланган: Чура ← Ир-Нарык (Чура би) ← Ир-Түләк ← Байгазы ← Астын (Арслан).

Нугайларның «Шора баьтир» дастанының бер урынында Нарикның атасының исеме «Эсебий» дип тә бирелә [Ногай халк: 1969. 68 б.]. Бәлки ул «Гайса / Иса» бий дигән исемдер. Ләкин Казан арты авылларында сакланган шәҗәрәләр башка төрлерәк: Чура батыр ← Чура би (Нарик) ← Караужа ← Кара би. Аңлашыла булса кирәк, икенче шәҗәрәнең Карауҗадан Чура бигә (Нарыкка) кадәрге XV-нче йөзгә караган өлешендә буыннар җитешми. Алар беренче шәҗәрәдә бар, ләкин ул шәҗәрә әлегә Кара-хуҗа бәк белән тоташмый. Шуңа күрә дә соңгы шәҗәрәдә саналган шәхесләр турында документаль чыганаклар эзләү таләп ителә. Бу Чураның атасы

Нарык батырның үзенә дә кагыла, аның турында да тарихи чыганаклар булырга тиеш.

Мондый тарихи чыганаклар табылып, югарыда китерелгән нугай версиясе дип аталырга хаклы шәҗәрәнең дөреслеге расланса, Чура Нарыковның нәселе турындагы информация тагы да байрак булачак.

2. Чура батырга багышланган барлык дастан версияләрендә дә аның атасының һәм үзенең дошманы итеп «Акташлы» (Акътачлы) Али (Гали) бәй атала. Үз вакытында бу шәхес турында Чокан Вәлиханов бер Чорага багышланган казакъ «поэмасыннан», ягъни дастаннан чыгып, аны «Урал» (Җаек елгасы булса кирәк) һәм «Сарайчык» тирәләрендә яшәгән нугайларның «актачи бүлеме» башында торган «ыру башлыгы» буларак күрсәткән иде. Шулай ук аның фикере буенча, Али бийның исеме Кырым ханы Саадат-Гәрәйнең хиҗри белән 930-нчы елга (1524-нче ел) караган ярлык астында булып, ул «конюший» (хан атлары өчен җаваплы) дәрәҗәсенә ия булган ([Вәлиханов: 1984. Т. 1. С. 109]. Ярлыкны карагыз: [Тарханные: 1851. С. 22]). Бәлки, бу фикер белән килешергә кирәктер, ни дисәң дә, Али (Гали) бәк Чураның атасы Нарык (Нарәң) батырдан аның Карагир атлы «сөйгән атын» алып киткәч башлана бит конфликт [Татар халык иҗаты: 1984. 113 б.; Къырымтатар: 1991. 63 б.; Чура Батыр: 1993. 37 б.; Ногай халк: 1969. 67 б.]. Әмма бу затлы татар турында өстәмә мәгълүмат кирәк әле. Аның бер өлеше рус телендә сакланган казакъларда язып алынган «Шура-Батыр» дастанында бар: анда Али бий «Ак калада» хөкем итә һәм 10 мең «нугае» булган Тимер хан угълы Кара ханга хезмәт итеп, аның бие була һәм 40 меңлек «айракты» дип исемләнгән төркем башында тора [Сборник материалов: 1895. Т. IV. С. 8]. Бу кабилә исеме түгел микән? Шулай ук, «Ак-кала» атамасы «Ак таш / Акташ / Акътачи» исеменең варианты дип карала аламы? Кайда урнашкан була соң бу «кала»? Бирелгән сорауларга әле җаваплар табасы бар. Шулай да, «айракты» атамасы хәзерге көнчыгыш Татарстан (Ык буйлары) һәм төньяк-көнбатыш Башкортостан белән Пермь төбәгенең көньягы җирләрендә билгеле булган «иректе» ыруының исеме белән охшаш. Ә бу төркем исә Көнбатыш Себер (Миасс елгасы һәм Тобол-Иртыш буйларыннан) якларыннан күчеп килгән табын (кара-табын) кабиләсе белән бәйле булган [Исхаков: 1993]. Ләкин Ык тирәләрендә урнашкан «иректе» төркеменең саны әллә ни зур булмаган, ә Али бийның кул астында 4 төмән күләмендәге зур масса гаскәри күренә. Шуның өстенә онытмыйк: «иректе» термины төрки «ирәк», ягъни, «ныгытма, крепость» сүзеннән ясалган, димәк, ул төшенчәнең «ныгытмада хезмәт итүчеләр» дигән мәгънәсе дә булырга мөмкин һәм ул очракта бу термин кабилә-ыру атамасы булмый. Ә менә «Ак ташлы / Ак-кала» дигән урынны, ахрысы, Кырымда яисә аннан якын

җирдә эзләргә кирәк, чөнки «Чорабатыр» дастанында (кырым татарлары версиясе) «Ак ташлы Али бий» явыз ният белән «Кокушле Кок Тама» дигән урынга килә [Образцы: 1896. Ч. VII: С. 170]. Димәк, бу ике урын бер-берсеннән бик ерак урнашмаган булганнар һәм ул төбәк Кырым ханлыгына караган җирләрдә булырга тиеш. Ничек кенә булмасын, бу мәсьәләләргә алга таба ачыклык кертергә кирәк булачак.

3. Дастаннарның кайбер казакъларда сакланган версияләрендә Нарикны «хан» дип, аның улы Чура (Шора)ны «солтан» дип атау күзәтелә, ә ул Казанга киткәндә анда «хан боламын», дип бара. Сорау туа: ни өчен Нарыкка һәм Чура батырга мондый титуллар бирелә, алар бит Алтын Урданың сәяси варисларында фәкать тик Чыңгызыйларга гына бирелгәннәр? Чынлап та, монда чишелмәгән проблема бар – тарихи чыганаклардан Чура Нарыковның «князь» (бәк, бий, бәй) дәрәҗәсе ачык күренә, аның нәселендә күренгән башка шәхесләр дә, шәҗәрә башында торган Кара-хуҗа үзе дә «бәк» титулын йөрткәннәр. Шуңа да карамастан, безгә казакъларда язып алынган дастан версияләрендәге күрсәтелгән бәяләүләрне анализдан төшереп калдырырга ярамый, чөнки Казан ханлыгында Арча бәкләре булган көнчыгыш кыпчаклар (кимаклар) арасыннан чыккан албыр (олбыр) кабиләсе лидеры Бачман солтан нәселе вәкилләре шәҗәрәләрендә дә «хан» титулы очрый [Исхаков: 2010. С. 101–104, 206]. Безнең фикеребезчә, китерелгән фактлар игътибарга лаек. Кайбер мәгълүматлар буенча (ул турыда тулырак карагыз: [Исхаков: 2018-в]), бу очракларда без карачы бәкләр кабиләләренең борынгы (монголларга кадәр булган) тарихлары белән бәйле күренешне күзәтәбез (мәсәлән, XII–XIII-нче йөз башларында Хәрәзмшахлар дәүләтендә 10 меңлек кабилә гаскәрләре башында торган хәрби юлбашчыларның «хан» титуллары булган). Күренә ки, бу мәсьәлә дә тикшерүне сорый.

4. Тагы бер шундый проблема Чура батырның анасы ягы кабиләсе белән бәйле. Инде әйтелгәнчә, аның атамасының төрле вариантлары бар: тама / тана, төмән / тамйан. Беренче карашка, бу кабилә-ыруның аргын кабиләсенә фратриаль (туганлык мөнәсәбәтендә торган) каршы торучы хатын ягы буларак, ата ягына турыдан-туры мөнәсәбәте юк кебек. Ләкин бу мәсьәлә без уйлаганга караганда катлаулырак булса кирәк, чөнки «Шура-Батыр» дастанында бер кызыклы мәгълүмат сакланган. Дастан буенча, «40 юрта биләүче тамалылар» Нарикның (Нарикбайның) «сансыз көтүләрен көткәннәр» һәм аның «ышанычлы хезмәтчеләре» булганнар [Сборник материалов: 1895. Т. IV. С. 1]. Шулай ук Али бий Чурадан (Шорадан): «Син тамалы түгелме?», – дип сорагач, ул җавабында әйтә: «Мин тамалылар баласы, дип әйтмәгез, ә Аллаһ (Тәңре) улы дип атагыз», – дип [Шунда ук: 44 б.]. Вакыт-вакыт дастанның казакъ версияләрендә тама-

Социальный состав деревни был пёстрый: имелись кулаки, середняки, бедняки, батраки. Большинство составляли бедные крестьянские хозяйства. Дома бедных в основном были четырёхстенные. Обычно у них не было ни домашнего скота, ни построек.

Дома располагались беспорядочно, между ними не было ни заборов, ни плетней. Для хождения, общения зимой прокладывались узкие тропинки. Летом то же положение. Только в это время картину оживляли то движущиеся по селу, то лежащие на одном месте, коровы, то табуны скачущих лошадей. В большинстве случаев детей оберегали от них. Как бы лошади не стоптали, коровы не забодали.

Почему лошадей пускали не стреножив, без поводьев? Ответ, видимо в том, что в деревне, кроме кулаков и некоторых зажиточных, никто не сажал картошку и овощи. Ни у кого не было огорода. Оттого образовывались обширные свободные площади. А проблема картофеля решалась через русских, т.е. картошку население осенью разными путями привозило из русских деревень. Например, наших обеспечивали картошкой «русские знакомые» из Домниной Гаврила, из Мечатной Игнатий. Наличие русского знакомого играло для каждого важную роль. Здесь не надо

терять из виду и клюкву (*торнакуз*). Она для тукузцев была большим козырем.

### Культурная революция на селе

В Тукуз первыми учителями новой советской школы прибыли Гали Рагачурин и Камиля апа. Гали абый был из местных. Родился и вырос в д. Картавыл (ныне д. Одинарские – ред.) у Большого озера (Уватское). Активный коммунист, участвовавший в борьбе за установление советской власти в наших краях, он учился в татаро-башкирском педтехникуме Троицка и, окончив его, вернулся в родные края. Камиля апа училась в том же техникуме вместе с Гали абый. Перед отправкой на работу они стали мужем и женой.

Вот эти молодые учителя стали начинателями советского просвещения и воспитания молодёжи распространителями культуры среди населения в одном из глухих уголков Сибири – Тукузе.

Вместе с советской школой вскоре в деревне открылась первая «изба-читальня». Первым избачом в Тукуз приехал Шайхи Маннур, ставший впоследствии известным татарским поэтом и писателем. В автобиографической повести «Агымсуларга карап», в одной из её глав, озаглавленной «Өркемәгән кошлар илендә», он вспоминает и описывает свой приезд в Тукуз, свою трудовую деятельность здесь.

В те годы в нашей деревне в подлинном смысле начинается культурная революция. Энергичные молодые просветители засучив рукава принимаются за работу.

Изба-читальня стоит в центре внимания всей деревни. Она была оборудована столами, накрытыми красными скатертями, стульями, книжными шкафами. На столах лежали изданные на татарском языке газета «*Сабан һәм чүкеч*», сатирический журнал «*Шәпи агай*», другие газеты и журналы. На стенах – разные плакаты. Здесь перед каждым были открыты двери. Проводилась громкая читка газет и журналов, давалось объяснение плакатам, ответы на интересующее население вопросы.

Избач... Это слово сегодня понятно не каждому. В те времена избач в деревне был личностью. Его можно было бы назвать полпредом революции. Зарплата небольшая, но избач никогда никому не жалуется. Он только ищет выход из трудного положения. Он знает: карманы пролетарского государства неглубокие, много и прорех... Избач с утра до вечера на ногах. Он везде успевает, он знает всё. Он и агроном, и врач, и судья. Он – «ходячая энциклопедия», может дать консультацию по всем вопросам. Избач хорошо знает и сегодняшние формы работы: кружковую деятельность, ликвидацию неграмотности, политическое просвещение и др. Самым важным Шайхи Маннур, например, считал антирелигиозный

атеистический кружок. За ним ещё драмкружок и хоровой кружок. Вечерами при свете семилинейной керосиновой лампы он проводил в избе-читальне свои кружковые занятия.

Изба-читальня была единственным местом обучения сельского населения навыкам культурного поведения. Здесь, например, был установлен ящик с песком, заменяющий плевательницу. Молодёжь здесь учили не курить, не плевать, не щелкать орехи. На дверях избы-читальни висело такое объявление: «Хочешь курить – кури на улице, домой заходи только после курения!»

Думаю, что будет к месту написать и о моём отце. Говоря правду, мой отец в эти излагаемые мной годы был одним из видных людей в деревне.

**Мой отец**

Видя смышлёность и выражая большие надежды на будущее, то есть имея ввиду, что станет муллой, родители, после окончания сельской школы, отправили его на учёбу в д. Янаул около Тюмени.

Он, с большими трудностями обучаясь несколько лет в медресе, получил знания в объёме примерно восьми классов. В те времена среди бедняков получение такого образования было редким явлением. Правда, выучившись он не стал муллой. Однако, полученные в своё время знания в последующей жизни стали ему очень нужны.

Октябрьскую революцию и Советскую власть он встретил сознательно, с большим подъёмом и радостью, активно участвуя в установлении советской власти и её укреплении на селе. Одним из первых записался в ячейку волостной партийной организации, организованной в Тукузе.

В 1920 г. отца отправили на краткосрочные партийные курсы в Тобольск. По окончании курсов его оставили там же для работы в милиции. В те годы, конечно, для работы в партийных и советских органах нужны были достойные люди. Но ему не пришлось здесь долго работать. В начале 1921 г. начался мятеж кулацких банд. В конце февраля мятежники вступили в Тобольск. Из-за нехватки оружия и сил коммунисты города были вынуждены временно оставить город.

Моему отцу пришлось полностью участвовать в этих событиях. По историческим сведениям и по рассказам отца, на долю тобольских коммунистов выпали суровые испытания. После оставления города, они, соединившись с отрядом коммунистов г. Тары, отступали в направлении Загваздино-Карагай. Личный состав двух отрядов составлял 700 человек, было 4 пулемёта, бандиты превосходили числом в два раза и по оружию превосходство было на их стороне...

Только после прибытия из Тобольска «сборного красноармейского отряда» силы с обеих сторон несколько уравновесились. Началась под-

готовка к наступлению на силы бандитов, сосредоточенных в с. Аксурка. Бои за Аксурку продолжались непрерывно более суток (28 часов). Наступлению препятствовал выпавший глубокий снег. К тому же мятежники соорудили ледяные препятствия, прятались в глубоких окопах. Но наступление нельзя было переносить. Утром, примкнув к винтовкам штыки, коммунисты и красные воины поднялись в атаку. Бандиты не смогли остановить их яростную атаку, вынуждены были оставить селение. 250–300 бандитов были взяты в плен. Несмотря на большое поражение в боях возле Аксурки, бандиты не сложили оружия. Теперь они, оставляя большие населённые пункты, такие как Дубровное и Вагай без боя, строили укрепления возле Второвагая (Татарских Вагай). Но и здесь битва, хотя и носила ожесточённый характер, была непродолжительной. 29 марта отряд бандитов был окончательно разгромлен, открылся беспрепятственный путь на Тобольск. Но, к сожалению, в этом бою были и большие потери: комиссар отряда Александр Васильевич Семаков героически погиб, друг Семакова, командир роты коммунистов Иван Васильевич Ческидов, умер от тяжёлого ранения (мой отец был в роте Ческидова).

...Кулацко-эсеровский мятеж не обошёл стороной и нашу деревню. По подстрекательству деревенских богачей Рахимовых, бандиты, как семью коммуниста, преследовали наших. Первым в наш дом пришёл с визитом кулацкий подпевала Кинчагул абышка (старик). Он, остановившись у дверей, обратив на себя внимание всех, подняв одну руку вверх объявил:

– Вам теперь смерть, кунец!

То есть нам теперь пришла смерть, конец. Тут же в дом явились ещё 2–3 бандита.

– Кто из вас жена коммуниста Алиша? – спрашивают. Все домашние, смутившись, замолкли. Мама вся побелела, от испуга дрожала как осиновый лист. Тот противный Кинчагул спокойно показывает на маму:

– Вот она.

Бандиты тотчас набросились на маму, за руки выволокли её на улицу. Тут, во дворе, полуголую, безжалостно избивали плетью. Она долго лежала без сознания. Мы, дети, от испуга громко плакали. Каждый из домашних был испуган, они тоже плакали и ждали какое-то страшное дело. Такие коснувшиеся глубоких чувств трагические события никогда не забываются...

В те дни дома из мужчин никого не было. Оставшемуся дома Зульфукар бабаю пришлось бежать из деревни. С собой он увёл и любимую серую лошадь, чтобы она не досталась бандитам. Ему пришлось долго прятаться в дальнем лесу в сторожке охотника. Там он отморозил ноги. По возвращении домой, при снятии обуви, пальцы обоих ног отпали…

Наконец, в апреле месяце мятеж везде был подавлен. И в наших краях снова началась работа по укреплению советской власти. В конце лета 1921 г. и отец вернулся домой. Его на селе ждали большие дела. Активно боровшегося за Советскую власть молодого коммуниста избрали председателем волисполкома, позже, по ликвидации волости и образовании сельского Совета, он был избран первым председателем Тукузского сельского совета.

В 1922–23 гг., по историческим документам, большое внимание уделяли образованию ростков социалистического хозяйства на селе – строительству коммун. Например, в 1922 г. в д. Митькино образовалась коммуна «Искра». 8 апреля 1923 г. собрание коммунистов Тукузской волости вынесло решение об образовании коммуны в деревне. Коммуне дали название «Кызыл игенче». Председателем правления был избран Садыков Алиш, секретарём – Кутков Нурмухамет. Коммуне выделили 50 десятин земли. Но посевного зерна не было. Коммунары решили просить у государства ссуду на 600 пудов зерновых и 50 пудов картошки (Эти сведения взяты из истории Вагайского района).

Таким образом, по своему, с большими трудностями, сельские коммунисты решили взяться за строительство социализма. Но то, что это дело невозможно наскоком решить, они поняли позднее…

Теперь вернёмся к вопросам культурной революции.

Как было отмечено выше, после возвращения в Тукуз учителем Гали Рагачурина, первого избача Шайхи Маннура, мой отец, будучи председателем сельского совета, вместе с ними продвигал вперёд культурную революцию на селе. Они друг с другом тесно взаимодействовали. Гали абый и отца связывали годы борьбы за новую власть. А Шайхи Маннур по приезду в Тукуз попал под крыло нашего отца, ему пришлось жить с нами в одном доме, питаться с нами за одним столом.

Таким образом, я с детства был близко знаком с Шайхи Маннуром. Но очень сожалею, что с этим человеком не пришлось встретиться ещё раз при его жизни. Хотя были возможности для встречи. Возможно, при встрече он вспомнил бы меня. Ведь мы с ним летними ночами вместе спали на сеновале сарая. Рыбачили вместе, купались в Агитке… За столом, когда обедали, он передавал головы карасей мне, шутя при этом говорил: «Пусть их ест Султангали, ему рыбьи головы очень полезны, они развивают его умственные способности». Не знаю, то ли он не умел есть рыбьи головы, то ли не любил. Я старательно со вкусом ел передаваемые им рыбьи головы.

…Видя укрепление Советской власти на селе и зная свою вину перед властью во время кулацкого мятежа, один из деревенских богачей, род-

ственник Рахимовых, богач Фатых бай, оставив большой дом, флигель во дворе и другие хозяйственные постройки, куда-то сбежал из деревни. Всё его имущество перешло в распоряжение волисполкома.

Как известно, в нашем доме проживало много душ. Поэтому, отец со своей семьей переехал в одну из освободившихся комнат этого дома. Новую школу открыли в большой крайней комнате. По приезду, Шайхи Маннура поселили в соседней с нами комнате. А во флигеле устроили избу-читальню.

Вот так оставленное Фатых баем «наследство» помогло наладить жизнь, работу этих людей и крепко связал их взаимными отношениями.

Ежедневно Шайхи Маннур и отец встречались за обеденным столом, обсуждали мировые новости, обменивались мнением о текущих делах, строили планы. Временами к трапезе присоединялся и Гали абый. И в таком случае рассматривались не только мировые проблемы, но и обсуждались вопросы школы, клуба, говорили о лампах, керосине и др. Я к таким беседам с интересом прислушивался. Для меня всё было ново, интересно, только понимать суть было почти невозможно...

Культурная революция на селе продолжала своё всестороннее наступление. На второй учебный год здание новой мечети Олы авыл (одна из слобод д. Тукуз – ред.) было передано школе, привели туда новые парты. Поверхность парт была с наклоном, они оказались очень удобными. Возросло число учащихся: в школу начали ходить не только дети младшего, но и старшего возраста. В одной руке учащихся была сумка (букча), в другой – чернильница (тәвәт). Чернила каждый делал сам. Мои хождения в школу, письмо, макая перо в чернила, усвоение чтения, письма и счёта остались в памяти самыми яркими воспоминаниями детства...

Вскоре силами общественности села был построен большой клуб. Он мог вместить 200–300 человек. На сцене клуба были осуществлены первые татарские драматические постановки: «*Казан сөлгесе*», «*Сүнгән йолдызлар*» Карима Тинчурина, «*Галиябану*» Мирхайдара Файзи и др. Все они готовились силами артистов самодеятельного драматического кружка Шайхи Маннура. Успешно исполняла роль Галиябану, например, прибывшая тогда недавно в деревню учительница Рабига апа Гиззатуллина.

В клуб из районного центра привезли новый музыкальный инструмент называемый фисгармонией. На ней быстро научились играть в четыре руки. Работа клуба закипела ещё больше. На сцене начал давать первые концерты и действовал хоровой кружок. Революционные праздники, демонстрации, торжественные заседания стали сопровождаться докладами. Были сделаны первые шаги по замене старых традиций и

обычаев на новые ритуалы. Например, после рождения первенца у Гали абый и Камиля апа было проведено торжественное имянаречение ребёнку в клубе. Клуб был по-праздничному убран. На сцене – покрытый красной скатертью стол, стулья. Зал был полон народу. Все с интересом ждали... Вот из задних дверей, неся завёрнутого в белое младенца, завязанного красной лентой, показалась Камиля апа. За ней шли Гали абый, председатель сельского совета Садыков Алиш, Шайхи Маннур и ещё несколько человек. Они не спеша прошли через зал, поднялись на сцену. Присутствующие стоя приветствовали аплодисментами малыша.

Первым выступил председатель сельского совета. Он рассказал о рождении молодого гражанина Советской страны, от имени партячейки и сельского совета поздравил молодых родителей с рождением первенца, пожелал им счастья и успехов в похвальном труде. После этого объявили о наречении младенца Маратом и о занесении имени в книгу ЗАГСа сельского совета, вручили счастливым родителям под аплодисменты зала соответствующее свидетельство. Шайхи Маннур обратился к друзьям с тёплыми словами и прочитал свои стихи, посвящённые Марату. На присутствующих стихи оказали сильное воздействие. Ещё несколько человек выступили с поздравлениями. Заключительное слово взял Гали абый: «Дорогие товарищи, друзья, односельчане, – говорил он. – Всем выражаю благодарность за сегодняшнее торжество, внимание, тёплые слова в наш адрес и добрые пожелания. С супругой Камилей даём слово вырастить Марата здоровым, воспитать борцом за Советскую власть, достойным нового времени коммунистом-ленинцем».

Впоследствии проведение таких же торжественных свадеб стал традиционным. Вот так старая, тёмная деревня как бы просыпалась от сна, начала шумную новую жизнь.

***Рәшит Минһаҗ***

# ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ УРТАЛЫКНЫ ЭЗЛӘҮ

*«Берәү белән дус булсаң, дошман булырга җир калдыр,*
*Берәү белән дошман булсаң, дус булырга җир калдыр»*
*Татар халык мәкале*

Кешелек дөньясы барлыкка килгәннән бирле адәм баласы үз-үзен, башкаларны аңларга, әйләнә-тирә мохитне танып белергә, үз ишләре белән аралашып, дөнья моделе булдырырга тырышкан. Әмма гомум танылган, кабул ителгән тәртип-кысаларны саклау ансат түгел. Еш кына тормыш-көнкүрештә күп дәлил китерүне, озаклап аңлатып торуны таләп иткән вәзгыятьләр була. Кечкенә генә проблемаларны күпертү, җитдиләрен күрмәмешкә салышу очраклары да аз түгел. Шул рәвешле аңлашылмаучылыклар килеп чыга, каршылыклар арта. Мондый вакытта ярдәмгә мәкальләр килә [Исәнбәт: 2010]. Яшәеш барышында килеп чыга торган һәр вәзгыятьне, минуты, секунды белән шәрехләп, бәяләп бирә алар. Халыкның дөньяга карашын чагылдыруы, җәмгыятебездә күзәтелгән чатаклыкларны бәян итүе, аңлашырга, урталыкны табарга чакыруы белән дә мәкальләр зур әһәмияткә ия.

Халык акылының, меңәр еллар дәвам итеп килгән тормыш тәҗрибәсенең сыгынтысы алар. Мәкальләрнең бер ише, «кеше ышанмаслык сүзне дөрес булса да сөйләмә», яки, «яңа ярлар табак белән аш китерә, иске ярлар ике күздән яшь китерә», дип турыдан-туры үгетләсә; шактые, «таяк ике башлы», «алма агачыннан ерак төшми», «карга күзен карга чукымый», «утсыз төтен чыкмый», дип искәртү, кисәтү, сак булырга чакыруларны сурәтле фикерләүгә төреп бирә [Исәнбәт: 2010. Т. I. Б. 10].

Шул ук вакытта кайбер мәкальләр аптырашта калдыра, шуңа күрә аларның яшерен мәгънәсен эзләргә туры килә [Яхин: 2012]. Әйтик, «Агыйделнең аръягында бер инәгә – бер сыер», дигәне бик гади һәм зурны вәгъдә итә кебек. Яхшылабрак игътибар итсәң, монда киная яшерелгән, сүз уйнату бар. Хикмәт шунда: «инә» сүзе борынгы төрки-татар телендә «сыер» мәгънәсендә кулланылган. Төрки теллә рдән булган чуаш телендә хәзер дә сыерга «энә» дип әйтәләр. Хәзерге төрек телендә исә сыерны «инәк» дип йөртәләр. Кайбер татар сөйләшләрендә тегү коралын «инә» дип йөртсәләр дә, хәзерге татар әдәби телендә әлеге җисем «энә» дип атала һәм языла. Шуңа күрә дә сөйләүче, бер инәгә – бер сыер, дип әйткәндә нәкъ менә телебезне яхшы аңлаганнарны, борынгы төрки те-

лебезне онытмаганнарны, ягъни Агыйделнең аръягында бернинди аерма юклыгын күз алдында тота. Аңламаганнар, билгеле, алдана. Ләкин сөйләүчене гаепли алмыйсың. Ул бит, «бер энәгә – бер сыер», дип әйтмәде... Телебезне тоймыйсың, монда берәр хикмәт юкмы дип уйлап тормыйсың, ашыгасың икән, үзең гаепле.

«Инә дә – бүләк, дөя дә – бүләк», дигән мәкаль шулай ук сүз уйнатуга корылган. Монда да тегү коралы түгел, сыер турында сүз бара. Билгеле, аңламаганнар, аңларга теләмәгәннәр, тегесе дә, бусы да бүләк инде, дип уйларга мөмкин. Әмма аңлаганнар өчен монда сүз сыер турында бара. Чынлап та, дөя белән сыер – бер чамадагы бүләк, икесе дә – эре хайван. Инде башкалар дөя бүләк иткәндә син энә белән чикләнсәң, аңлашыла ки, мондый хәл көлке тудырачак. Шуңа күрә татар баласы телен яхшы белергә, инә белән энәнең мәгънәсен аера алырга тиеш.

Кинаяләп, читләтеп әйтүнең татарда әле тагын бер формасы бар. Каршы тарафларда торган төшенчә-мәгънәләрне кушарга, берләштерергә тырышу омтылышы көлке тудыра. Әйтик, бик озак кыз күзләп, өйләнә алмый аптыраган бер егет, «кыз да булсын, буаз да булсын», дип әйткән ди. Билгеле, тормышта мондый хәл була алмый. Балаларын сөтле итәм дип, ашыгып, базардан үгез сатып алып кайткан агай исә, «үгез булмагае, чорт булсын, савып эчәргә сөт булсын», дип тә четерекле хәлдән чыкмакчы булган. Тик үгез сөт бирә алмый шул.

Халык язылган һәм язылмаган кануннар, әхлакый кагыйдәләр нигезендә яши, җәмгыятьтә урнашкан гармония-татулыкны сакларга тырыша. Әмма вакытлар узу белән вәзгыять үзгәрә, тотрыклылык тоткарлыкка әверелә. Әле кичә генә «картлар сүзен капчыкка, яшьләр сүзен янчыкка» салырга чакырган алтмыш яшәрләр юлдан кайткан алты яшәрләр белән көрешергә килә. Һич уйламаганда, көтмәгәндә каршылыклар, конфликтлар туа. Мондый вакытта каршы тарафларны тынычландырырлык, ике якны да килештерерлек карар тәкъдим итә алган уртача кешеләргә ихтыяҗ арта. Уртача кешеләр нинди була соң? «Усал булсаң – асарлар, юаш булсаң – басарлар, уртача кеше булсаң – ил агасы ясарлар», дип сабак бирә мәкаль. «Ак матур – чак матур, кара матур – урта матур, шадра матур – бик матур», дигәненде дә киная бар-барын. Әмма гашыйк булсаң, «шандра – йөрәк яндыра»; «пәлтә дә бер, бишмәт тә бер кигәнгә, йәмсез дә бер, матур да бер сөйгәнгә», «мәхәббәтең бакага төшсә, күл буеннан китмәссең», дип тә гашыйкларны тигезләп куя сөю-гыйшык хикмәтләре. Күз төшү, гыйшык хикмәтләре кайчак һич көтелмәгәнчә аңлатыла. «Мондый матур хатынның миңа яртысы да җитәр иде», дип әйтте ди бер агай. Шул ук вакытта, гаилә корганда үз тиңеңне эзләргә киңәш итә мәкаль: «бай

кешенең кызын алсаң, атасы белән мактаныр, ярлы кеше кызын алсаң, өстәл астын актарыр». Дөрес, ярлылык та ерак йөрми. Шуның өчен, «баймын дип мактанма, ярлылык бар; күпмен дип мактанма, ялгызлык бар», дип искәрткән борынгылар.

Икенче бер очракта, урта кеше нинди була соң, дигән сорауга, «җаның сау булса, авырумын димә; тәнең сау булса, ярлымын димә», дип юата мәкаль.

Металлар белән чагыштырганда татарда урталык көмеш белән аңлатылган. Алтын белән бакырның уртасында көмеш торган. Дөрес, «хатын – алтын, кыз – көмеш, карчык – бакыр», дигәндә бу раслау туры килеп бетми шикелле. Әмма, «өлешемә тигән – көмешем», дигәндә алтын инде көмешкә әйләнә. Шулай итеп, ярыңа тугрылык саклауны, гаилә иминлеген кайгыртуга, хәләлеңнән канәгать булырга чакыра мәкаль. «Артка карап шөкер ит, алга карап фикер йөрт», дигәндә дә шул ук мәгънә – канәгать булу алга сөрелә.

Еш кына адәм баласы яхшыны яманнан аера алмаска мөмкин. «Яхшы-яман үзеңә күренми, кеше әйтмәсә, күзеңә күренми», дип искәртә мәкаль. Ягъни үзеңә чын бәяне башкалардан ишетерсең. Шул ук вакытта борынгылар, «үзеңә теләмәгәнне кешегә дә теләмә; үзен генә уйлаган – яманлыкның билгесе, үзгәне дә уйлаган – әдәмлекнең билгесе», дип нәсихәт бирә. «Изгелек итәргә булдыра алмасаң, яманлык итмә, яманлык итмәү дә – изгелек», дип хәер хаһлы булырга чакыра, «изге эшне вакытында тотмасаң, явыз эшкә; явыз эшне вакытында тотмасаң, изге эшкә әйләнер», дип изгелек-явызлык дигәннең вакыт-вакыт шартлы булуын да онытмаска кушкан элгәреләребез.

Дус-дошман мөнәсәбәтләрен көйли торган мәкальләр дә шактый күп татарда. Аларда гадәттә уртача булу кирәклеге турыдан-туры әйтелми, ул сүз сөрешеннән килеп чыга. «Берәү белән дус булсаң, дошман була торган җир калдыр; берәү белән дошман булсаң, дус була торган җир калдыр», «актык сереңне дустыңа да әйтмә, дустың бервакыт дошманың булыр», дип кисәтә, икенче очракта, «буш торганчы, дошманың белән таш ташы», «яхшы холык дошманыңны дус итәр», дип килешү ихтималын да искәртә борынгыларыбыз.

Дуска түгел, дошманга да теләмим аерылуны, дип җырлый халкыбыз. Бу гыйбарә соңгы вакытта мәкаль булып та йөри башлады. Билгеле, монда да ил дошманнары турында түгел, шәхси дошманнар хакында сүз бара.

Халык нигездә язылмаган кануннар белән яши. Мәкаль – язылмаган канун ул. Чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, вәзгыятенә күрә җавабын бирүе, тиешле хөкемен чыгаруы – меңнәрчә еллар буе дәвам иткән ха-

лык тәҗрибәсен дәвам итүе, узмышыбызны булмышыбызга, бүгенгә тоташтыруы һәм, әлбәттә, урталыкны табарга булышуы белән кыйммәт ул безнең өчен мәкальләребез.

**Әдәбият**

1. Нәкый Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. Мәкальләр җыелмасы. Өч томда. Икенче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.
2. Альберт Яхин. Система татарского фольклора. Набережные Челны, НИСПТР, 2012.

# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ ХӘДИСЛӘРЕНДӘГЕ ХАКЫЙКАТЬ

## «АЛЛАҺНЫҢ СӨЙГӘННӘРЕН СИН ДӘ СӨЙ» ХӘДИСЕ

Аллаһы Тәгалә берәр колын сөйсә, фәрештәләренә нәрсә әйтер?

***Аллаһның сөйгәннәрен сөю хакындагы хәдис...***

Әбү Хөрәйрадан радыйаллаһу ганһе риваять ителгәнчә, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай дип әйтте:

«Аллаһы Тәгалә берәр колын сөйсә, Җәбраилгә:

«Аллаһ фәлән колны сөя, аны син дә сөй!» – дип боера. Җәбраил да ул колны сөя башлый, аннары күктәге затларга:

«Аллаһ фәлән колны сөйде, аны сез дә сөегез!» – дип аваз салыр.

Күктәгеләр дә ул бәндәне сөя башлар. Ахырдан җирдәгеләрнең күңелендә дә ул кешегә карата мәхәббәт хисе уяныр» (Бохари, Бәд-үл-хальк 6, Әдәб 41, Тәүхид 33; Мөслим, Бирр 157. Шулай ук карагыз: Тирмизи, Мәрьям сүрәсенең тәфсире, 7).

Мөслим риваять иткән бер хәдистә (Бирр 157) Аллаһның илчесе (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын) шулай ук әйтелгән:

«Аллаһы Тәгалә бер колын сөйсә, Җәбраилгә: «Мин шул кешене сөйдем, аны син дә сөй!» – дип әмер бирер. Җәбраил дә ул кешене сөя башлар һәм күктәге затларга:

«Аллаһ шундый-шундый кешене сөйде, аны сез дә сөегез», – дип аваз салыр. Күктәге затлар да ул кешене сөя башлар, ахырдан җирдәгеләрнең дә ул кешегә карата сөю хисе уяныр.

Аллаһы Тәгалә берәр кемне нәфрәт итсә, Җәбраилгә: «Мин шул кешене яратмыйм, аны син дә яратма!» – дип әмер бирер. Җәбраил дә ул кешене яратмый башлар.

Соңыннан Җәбраил күктәге затларга: «Аллаһ шундый-шундый кешене яратмый, аны сез дә яратмагыз!» – дип боерыр. Күктәгеләр дә ул кешене яратмый башлар. Ахырда җирдәгеләрдә дә ул кешегә карата нәфрәт уяныр».

***Әбү Хөрәйра (Аллаһ аңардан разый булсын) кем ул?***

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын) аны «песи атасы» дип атаган, Мәдинә шәһәрендә урнашкан пәйгамбәр мәчетеннән кала, йокларлык бүтән урыны булмаган һәм Әсхәб әс-Суффә буларак танылган фәкыйрь мөселманнарның берсе – Әбү Хөрәйраның тормыш хикәясе...

Мөселман булганчыга хәтле аның исеме Габдешшәмс (кояш колы, бәндәсе) иде. Мөселман булганнан соң Габдеррахман (мәрхәмәт һәм шәфкать иясе булган Аллаһның колы) исемен алды. Көннәрдән беркөнне киемнәре эченә бер мәче баласын төреп күтәреп килгәндә, аны Аллаһның илчесе күрә дә: «Ни бу?» – дип сорый. Әбү Хөрәйра: «Мәче», – дип җавап кайтара. Моннан соң пәйгамбәребез аңа «песи атасы» мәгънәсенә туры килгән Әбү Һүрайра кушаматын бирә һәм кайда гына очратса да, «әй, Әбү Хөрһйра!» дип эндәшә башлый. Моннан соң Әбү Хөрәйраның үз исеме онытыла. Әбү Хөрәйра Аллаһның илчесе үзенә шул кушаматы белән эндәшүен бик ярата иде.

***Көне-төне пәйгамбәребез яныннан китми иде.***

Әбү Хөрәйра һиҗрәтнең җиденче елында мөселман булды. Пәйгамбәр мәчетеннән кала бүтән барыр һәм йоклар урыны булмаган, һәм Әсхаб әс-Суффә буларак танылган фәкыйрь мөселманнарның берсе иде. Көне-төне пәйгамбәребез янында булып, аңардан ишеткән хәдисләрнең мәгънәсенә төшенергә тырыша иде. Тормышының соңгы өч елында пәйгамбәребезнең үзеннән һәм башка олы сәхабәләрдән ишеткән хәдисләрнең саны 5374кә җитә. Шулай итеп, пәйгамбәр әсхабе арасында иң күп хәдис җиткерүчесе абруен казанды. Әбү Хөрәйра риваять иткән хәдисләрнең 609ы имам Бохари һәм имам Мөслим җыентыкларында урын алды.

Шуның хәтле күп хәдис риваять итә алуына гаҗәпләнүчеләргә ул шулай дип җавап кайтара иде: «Мөһаҗирләрдән (Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт итүчеләрдән) булган кардәшләребезне сәүдә һәм базардагы сату-алу эшләре, әнсар (Мәдинәдә исламны кабул итүче сәхабәләр) булган кардәшләребезне игенчелек һәм хөрмә бакчалары эшләре мәшгуль итте. Мин исә тамагым тук булган вакытларымда пәйгамбәрнең яныннан һич аерылмыйча, башкалар анда булмаганда, рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында идем, алар ишетмәгән һәм күрмәгәннәрне ятлый, хәтеремдә калдырырга тырыша идем».

***Мәдинәдә яшәде.***

Әбү Хөрәйраның үзеннән сигез йөздән артык сәхабә һәм тәбигыйн (сәхабәләр заманында исламны кабул иткән буын), хәдис ишетеп, риваять итте.

Хәлифә Гомәр (Аллаһ аңардан разый булсын) вакытында берара Бахрәйн белән идарә итәргә билгеләнгән Әбү Хөрәйра, моннан соң берниндиидарә эшләрендә эшләргә ризалык бирмичә, гомеренең калган елларын Мәдинә-и Мөнәвварәдә үткәрде. Һиҗрәтнең 59 елында Мәдинәдә 78 яшендә Аллаһның рәхмәтенә күчте. Аллаһ аннан разый булсын.

***Бу хәдисне без ничек аңларга тиешбез?***

Иң башта шуны ачыкларга тиешбез ки, Аллаһның бер колны яратуы – аңа хәерле нәрсәләр теләвендә, аңа дөрес юл күрсәтүендә һәм ни-

гъмәтләреннән аермавында чагыла. Аллаһы Тәгаләнең яратуыннан ерагаюны исә, азгынлыгын арттырып, колның үз нәфесенә ирек бирүе итеп аңларга кирәк.

Күктәге затлар – алар фәрештәләр. Күктәгеләрнең кешене сөюләрен исә Җәбраилдән башлап, бүтән барча фәрештәләрнең дә шул кеше өчен дога кылулары һәм аның өчен гафу сораулары итеп аңларга кирәк.

Хәдиснең икенче өлеше, – ягъни Аллаһ сөюеннән мәхрүм булып, аның нәфрәтенә дучар булу турындагы өлеше, – имам Бохари риваять иткән хәдистә юк. Бу сәбәптән, имам Нәвави дә җыентыгында башта имам Бохари белән имам Мөслимдәге хәдиснең уртак өлешләрен китерә һәм ахырдан гына имам Мөслимдәге хәдиснең соңгы өлешен зикер кыла.

Бу хәдистән без шуны аңларга тиешбез ки, Аллаһы Тәгалә берәр колны ятратса, ул колны фәрештәләргә дә, кешеләргә дә яраттыра. Шул ук вакытта Аллаһы Тәгалә бер кешене сөйсә, Җәбраил һәм кешеләрнең аны сөймәүләре мөһим булмый башлый. Әмма үзе сөйгән колына карата булган мәхәббәтен һәм аеруча игътибарын күрсәтү өчен, Аллаһ аны фәрештәләренә һәм игелекле кешеләргә дә яраттырыр. Коръән-Кәримнең «Мәрьям» сүрәсенең 96-нчы аятендә дә әйтелгәнчә: «Иман китереп, изге эшләр кылучыларны Рахман (мәрхәмәт, шәфкать иясе) булучы Аллаһ аеруча мәхәббәт белән бүләкләр». Аятьтәге «мәхәббәт белән бүләкләү»-не Габдуллаһ ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмә (Аллаһ алардан разый булсын) «Аллаһның һәм башкаларның мәхәббәтенә лаек булу» итеп тәфсирләгән (аңлаткан). Шулай итеп, аять белән хәдис мәгънәләре уртаклык таба.

Үзенең мәхәббәтеннән ерагайган кешене Аллаһы Тәгалә фәрештәләр һәм кешеләр мәхәббәтеннән дә ерагайтачагы турында өйрәндек. Аллаһның моны ничек итеп башкарганлыгы турында хәдисебездә аңлатыла. Болардан шушындый нәтиҗәләр чыгарырга тиешбез: мөселманнар арасында мәхәббәт казанган кеше Аллаһ каршында да сөекле бер кол икәнлеген күрсәтә. Шулай ук, изге кешеләрнең һәм мөселманнарның нәфрәтенә дучар булганнарның Аллаһ каршындагы хәлләре дә шундый, – Аллаһ андыйларны яратмас, андыйлардан нәфрәт итәр.

Димәк ки, кешене кемнәр ярата һәм кемнәр яратмый – безнең өчен мөһим бер күрсәткеч булып тора.

***Хәдистән без аңларга тиешле нәрсәләр.***

1. Аллаһның колын сөюе яшерен калмас.

2 . Аллаһы Тәгалә сөекле колын фәрештәләргә һәм изге кешеләргә дә сөйдерер.

3. Кешеләр, җәмгыятьтәге үзләренә карата булган мөнәсәбәттән, Аллаһ каршындагы урыннарын да белә алалар.

## ҖИҺАДЛАРНЫҢ ИҢ ФАЗЫЙЛӘТЛЕСЕ (ӨСТЕНЕ) КАЙСЫСЫ?

«Залим идарәче (түрә) алдында дөреслекне сөйләп, гаделлеккә өндәү – җиһадларның иң фазыйләтлесе» хәдисен ничек итеп аңларга тиешле?

Әбү Сәгыйд әл-Ходридән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять ителгәнчә, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай дип әйтте: «Залим идарәче алдында дөреслекне сөйләп, гаделлеккә өндәү – җиһадларның иң фазыйләтлесе » (Әбү Дәүд, Мәлахим 17; Тирмизи, Фитән 13. Шулай ук карагыз Нәсаи, Бәйгать 37; Ибне Маҗә, Фитән 20).

Әбү Габдуллаһ Тарик Ибне Шиһаб әл-Бәҗәли әл-Ахмәси (Аллаһ аннан разый булсын) риваять итүенчә, беркөнне пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм өзәңгедә басып торган чагында, бер кеше аңардан: «Җиһадларның иң фазыйләтлесе кайсысы», – дип сорады? Пәйгамбәребез: «Залим идарәче алдында әйтелгән хак сүз», – диде. (Нәсаи, Бәйгать 37).

***Әбү Сәгыйд әл-Ходринең (Аллаһ аннан разый булсын) тормышы.***

Мәдинә шәһәренең Хазрәҗ кабиләсеннән чыккан, күбесенчә кушаматыннан танылган Әбү Сәгйд әл-Ходринең (Аллаһ аннан разый булсын) кыскача тәрҗемаи хәле…

Аның тулы исеме Сәгд Ибне Малик Ибне Синан әл-Ходри иде. Мәдинәдә бер мөселман гаиләсендә үсте. Бала чагында ук ислам белән нигъмәтләнде. Мәсҗед эн-Нәбәвинең (Мәдинәдә урнашкан Пәйгамбәр мәчете) төзелешендә катнашты. Өхед сугышында катнашырга теләк белдерсә дә, әле бала гына булганы өчен, Аллаһның илчесе аңа рөхсәт бирмәде.

Атасы Өхедтә сугышта шәһит булганнан соң, гаиләсе авыр хәлдә кала. Әбү Сәгыйд ачлыктан хәтта эченә таш бастырып бәйләп куя торган була. Беркөнне улының шулай ачлыктан тилмергәнен күргән әнисе, аңа Пәйгамбәр янына барып, ярдәм сорарга үгетли. Аллаһның илчесе аңа, мохтаҗ хәлдә дә теләнүгә бармаган кешенең холкын Аллаһ тыйнаклык белән бизәячәген, кешеләрдән берни көтмичә, кулындагылары белән канәгать була белгәннәрне Аллаһ бай итәчәге, һәм сабыр итәргә теләүчене Аллаһ сабырлы итәчәге турында сөйләде. Шул көннән соң Әбү Сәгыйднең бүтән беркемнән дә берни сораганы булмады. Эшләре төзәлде һәм ул Мәдинә мөселманнары арасында бай кешеләрнең берсенә әверелде.

Аллаһның илчесе җитәкчелегендәге Хәндәк сугышында һәм тагы унике сугышта катнашты. Кайбер яуларны үзе дә җитәкләде.

Сәхабәләр арасында динне иң яхшы аңлаганга, Аллаһның илчесе (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын) вафатыннан соң, ул Мәдинәдә фәтвалар чыгару һәм дин өйрәтү белән мәшгуль булды. Әбү Сәгыйд

әл-Ходри меңнән артык хәдис риваять иткән һәм «муксирун» буларак танылган җиде сәхабәләрнең берсе.

Көннәрдән бер көнне Мәдинә шәһәре белән идарә иткән Мәрван Ибне Хәким утырып торганда, аның алдыннан җәназага алып барган бер табут узды. Мәрван моны күрсә дә, аякка басмады. Моңа Әбү Сәгыйд: «Без Аллаһның илчесе (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын) белән утырып торганда алдыбыздан бер табут узды, моны күргән Пәйгамбәр аякка торып басты», – дигәч, Мәрван да торып басарга мәҗбүр булды.

Аңа дингә кагылышлы берәр сорау белән мөрәҗәгать иткәндә, Әбү Сәгыйд Пәйгамбәрдән ишеткән хәдис яки аннан күргән гамәл белән җавап бирә иде. Шулай итеп ул, пәйгамбәр сөннәтен сүздә һәм гамәлдә тормышка ашыру һәм мөселман өммәте эчендә тергезү өчен зур өлеш кертте.

Әбү Сәгыйд дөреслек тарафдары булуы белән беррәттән, кыю, сабыр һәм фидакяр бер кеше иде. Мохтаҗларга һәм ятимнәргә ул гел ярдәм итә иде, карауга мохтаҗ булган балаларны, үз өенә алып, ашатып, үстереп, тәрбияли иде. Һиҗри 74 (694) елында, сиксән яшьләрендә җомга көнне вафат булды.

Аллаһ аңа разый булсын.

***Бу хәдисне без ничек аңларга тиеш?***

Залимнәр – башкаларның хакларын санга сукмыйча, кешеләргә авырлык һәм мәшәкатьләр тудырып торган һәм гаделлек кебек зур фазыйләттән мәхрүм булган бәндәләр алар. Золымның һәр төре, залим булган һәркем ямьсез, күңел этәргеч һәм начар. Ләкин идарәчеләр һәм идарә урыннарында утыручылар залим булса, эшчәнлекләренең тискәре йогынтылары җәмгыятьтә тагы да ныграк сизелә. Золым кешелек тарихының һәр дәверендә булган. Тарих та күп кенә залимнең ахырына шаһит булды. Ләкин алай да золымлык әле бар, ул юкка чыкмады. Пәйгамбәрләр җир йөзендә ширекне, көферне һәм боларның икесеннән килеп чыккан золымны юк итү өчен килде. Тарих дәвамында килгән пәйгамбәрләрнең һәрберсе, тиңе булмаган гаделлек мисалларын күрсәтеп китте. Әмма кешеләр, үз асылларыннан, дөреслек һәм гаделлектән, Аллаһ күрсәткән юлдан тайпылып, яңадан золымга юнәлде. Коръәни Кәрим боларның тере гыйбрәтләрен кешеләргә күз алларында күрсәтә. Пәйгамбәребез хәдисләрендә дә золымның нинди бөек бер бәла булганлыгы турында гел сөйләнә.

Коръән белән Пәйгамбәр сөннәте дөрес юл һәм күркәм үрнәкләр күрсәтеп калдырса да, золым һәм залимнәр мөселман җәмгыятендә дә тарихның төрле дәверләрендә гел була килде. Боларның ахырлары элеккегеләрнең ахырларыннан артык бернәрсәсе белән аерылмады һәм үзләреннән соң калганнар өчен гыйбрәт булды. Чөнки золым һичкай-

чан озак яшәмәде. Залимнәрнең ахыры бер-берләренә гел охшаш булды, нәтиҗәдә мәзлүмнәр җиңүчеләр булды, чөнки Аллаһ залимгә түгел – мәзлүмнәргә ярдәм итәр.

Берәр җәмгыятькә бәя биргәндә, иң беренче итеп игътибар итәргә тиешле нәрсә – ул шул җәмгыятьтә хөкем сөргән һәм идарә иткән системаның гаделлек яки золымлык принципларына корылган булуында. Идарә итүдә төп вазифаны кеше уйнаганга, җәмгыять эшчәнлеген юнәлтүче һәр системаны кешедәге баш мие белән чагыштырырга була. Кеше мие үз функцияләрен үтәмәгәндә, бөтен тән эшчәнлеге бозылган кебек үк, җәмгыять эшчәнлеген идарә итүчеләр дә аларга йөкләнгән вазифаларны тиешенчә башкармасалар, – җәмгыятьнең барлык катламнары да бозылып, юньләп эшләми башлый. Шулай булгач, һәрнәрсә идарәдән тора. Идарә эшчәнлеген төзәтергә тырышу ничек авыр булса, җәмгыять тормышы өчен ул шуның хәтле мөһим дә.

***Җиһадларның иң бөеге.***

Югарыда кыскача аңлатылган сәбәпләр аркасында, залим идарәче алдында дөреслекне сөйләү – җиһадларның иң бөеге булып санала. Чөнки бу эштә уңышка ирешү, залимне дә коткарып, Аллаһка коллыкка юнәлтә, җәмгыятьне дә залимнең золымыннан коткарып, иң бөек фазыйләткә – гаделлеккә ирештерә. Җир йөзендә Аллаһ исеме яңгырап, диннең хакимияте урнаша һәм шулай итеп җиһадның асыл мәгънәсе уртага чыга. Идарәченең хаксызлыгы турында сөйләүчеләр иң башта галимнәр булса, гади халык та залимнең золымы белән килешмичә, кылган золымында катнашмаска, моны йөрәге белән кире кагарга һәм хаксызлыгын начар гамәл итеп күрергә тырышырга тиеш.

***Залимнең золымына каршы чыгу.***

Сугыш кырына җиһадка чыккан кеше курку белән өмет арасындагы бер хис белән яши. Җиңәчәкме, җиңеләчәкме? Моны ул белми, ләкин алай да җиңүе өчен тырыша. Залим идарәчегә каршы чыгарга күтәрелгән кеше бөтен тормышын куркыныч астына куйганы өчен дә сугыш кырында җиһад иткән кебек санала. Моны күз алдында тотучылар – иң бөек каһарманнар, чөнки алар үлемне күз алдында тотып, үлемгә таба адым атларлар. Тарихтан күренгәнчә, залимнәргә каршы чыгучылар тормышларын фида кылсалар да, аларның китергән фидалары җәмгыятьне һәм кешелекне коткарыр.

Залим идарәчеләр җир йөзен гел канга гына батырып торыр. Аларның золымнарын туктату максаты белән яхшылыкка өндәү һәм начарлыктан тыю вазифасын җиренә җиткерүчеләр, иң башта, үзләрен җаваплылыктан азат итәләр. Әгәр идарәче төзәлсә, үзе белән берлектә бүтән кешеләр дә котылыр. Исламда җиһадның максаты моннан гыйбарәт. Мөселманның

җиһадында, бүгенге көн мәрхәмәтсез, аяусыз, кешелексез сугышлардагы кебек, кеше җанын санга алмыйча, каршыга чыккан һәркемне үтерүләр юк. Моның каршысы буларак, җиһад – кешенең үзен һәм җәмгыятьне дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирештерәчәк; гаделлеккә корылган бер низам корып, җир йөзендә ышанучы һәм ышанмаучы һәркемнең Аллаһ хакимияте (идарәсе) астына керүләре өчен шартлар тудырган, залимнәрнең золымыннан котылу өчен эшләнгән бер гыйбадәт ул. Җиһадның төп принцибы шундый: бер кешене мөэмин итү – мең кяферне үтереп юк итүдән өстенрәктер. Исламның асыл максаты кешеләрне үтерү түгел – яшәтүдер. Золым яклылар белән исә, әлбәттә, сугышу тиешле, моның шартларын да ислам билгеләгән.

***Хәдистән без аңларга тиешле нәрсәләр.***

1. Җиһад – сугыш кырында гына кылына торган бер гыйбадәт төре булмыйча, төрле мәртәбәләрдән һәм дәрәҗәләрдән гыйбарәт.

2. Яхшылыкка өндәү һәм начарлыктан тыю да җиһадның бер төре.

3. Гадел булмаган залим идарәчеләр алдында дөреслекне сөйләү – җиһадның иң өстен мәртәбәседер.

4. Идарәчеләрне кисәтеп, аларга үгет-нәсыйхәт бирү – галимнәрнең бурычы.

*Әбдеррәуф хәзрәт Зәбиров*

## Төбәк тарихы буенча конференцияләр һәм очрашулар. Хатлар һәм кайтавазлар

## Краеведческие конференции и встречи. Письма и отклики

### ХРОНИКА

4 августа 2022 г. главный редактор журнала «Туган җир. Родной край» доктор исторических наук Д.М. Исхаков принял участие в качестве модератора в работе Международной конференции «Эпическая константа современной культуры: проблемы сохранения и популяризации национальных эпосов», проходившей в Казани в рамках Года культурного наследия народов России и II Международного этно-fashion фестиваля «Стиль жизни – культурный код».

В ходе проведения мероприятия были заслушаны доклады о татарских народных эпосах и их роли в сохранении исторической памяти.

* * *

В рамках XXIII Международного фестиваля «Көзге Иртыш моңнары» и I Международного Прииртышского Сабантуя в г. Семей (Семипалатинск) Республики Казахстан, 9 сентября 2022 г. прошла Международная научно-практическая конференция на тему «Татары Прииртышья: история и современность (вклад татар Прииртышских регионов Казахстана и Сибири в историю и культуру татарского и казахского народов»). В работе данного мероприятия принимали участие с докладами ученые из Татарстана д.и.н. Д.М. Исхаков, кандидаты филологических наук А.М. Ахунов, И.Г. Гумеров (ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АНТ), Р.Г. Галиуллин (гл. редактор журнала «Казан утлары») и кандидаты исторических наук А.А. Бурханов и Ф.А. Байрамова. Главным редактором краеведческого журнала «Туган җир. Родной край» был предложен доклад на тему «Сибирско-татарский дастан «Ак Күбәк», предок казахов рода кара-кыпшак Аккобік и этническая история тюркского населения домонгольского времени бассейна Иртыша и сопредельных территорий». Остальные выступления татарстанских ученых отражали проблемы исследования духовного наследия татар данного региона, изучения истории отдельных личностей, а также творчество классика казахской литературы Абая Кунанбаева во взаимосвязи с татарской литературой. Работа конференции получила положительный отклик как среди её участников, так и местной казахской общественности.

* * *

2022 елның 11 сентябрендә аенда Новосибирски шәһәрендә язучы, тарих фәннәре кандидаты, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова белән очрашу булды. Очрашуны Новосибирски өлкәсенең «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы уздырды. Оешма җитәкчесе Рәшидә Хәмзина төбәктә татар тарихын өйрәнү буенча башкарасы эшләр белән таныштырды. Теманы дәвам итеп, Фәүзия Бәйрәмова Себердә татар тарихын милләт һәм дөнья тарихы яссылыгында өйрәнергә кирәклеген әйтте. Новосибирски һәм Томски өлкәләрендә яшәгән, фәндә «чат татарлары» дип аталган милләттәшләребез турында Фәүзия Бәйрәмова күп язды, аларны дөньяга танытырга ярдәм итте. Ул шулай ук Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына, Себердә ислам тарихына да җентекләп тукталды, бу теманың иҗатында зур чагылыш табуын сөйләде. Милли хәрәкәт активисты, биология фәннәре кандидаты Равил Бәдретдинов Новосибирски уртасындагы Чат шәһәрлеген себер татарларының тарихи мирасы буларак торгызырга кирәклеген сөйләде. Шунысын да әйтергә кирәк, Чат шәһәрлеге узган гасыр башында галимнәр тарафыннан өйрәнелгән булган, аннан табылган кыйммәтле ядкарьләр хәзер Петербургта, Эрмитажда саклана. Милли активистлар Равил Бәдретдинов, Рәшидә Хәмзина, Навил Шаһабетдинов Новосибирски уртасындагы борынгы Чат шәһәрлеген торгызу буенча зур эшләр алып баралар. Чат шәһәрлеге буенча фикер алышу шактый дәвам итте, чөнки ул Күчем ханның, Себер ханлыгының соңгы башкаласы буларак кабул ителә. Аны тарихи яктан өйрәнү, торгызу, туристлар маршрутына кертү өчен җәмәгатьчелек белән бергә, хакимиятнең, шул исәптән Казанның да ярдәме кирәк булачак. Шул нисбәттән, татар төбәк тарихчыларының җирле оешмасын төзү дә өлгергән мәсьәлә, җыелышта ул хакта да сүз булды.

Очрашу эшлекле тәкъдимнәр, фикер алышулар белән дәвам итте, анда шәһәр зыялылары, милли активистлар катнашты. Шунысын да әйтергә кирәк, Фәүзия Бәйрәмова белән очрашу «Ак калфак» оешмасының Новосибирски уртасындагы яңа офисында үтте, ул киләчәктә татарларның милли үзәге буласына шик юк.

*«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге*

* * *

16–18 сентября 2022 г. состоялась экспедиция по сбору экспонатов для формирования фонда Музейно-просветительского центра «Чимги-Тура – врата Сибири». В ходе экспедиции её участники к.и.н. З.А. Тычинских и к.и.н. Г.И. Зиннатуллина посетили населенные пункты Тюменского района с. Муллаши, д. Аманадское. Собрано 60 различных предметов

историко-этнографического характера (орудия охоты, рыболовства, утварь, бытовые, культовые предметы и т.д.).

* * *

20–21 сентября 2022 г. в Челябинске прошла 1-я Международная научно-практическая конференция на тему «Служилые и ясачные люди в России XV–XIX в.: особенности землевладения, сословные номинации». В работе конференции приняли участие ученые из Татарстана: доктора исторических наук Д.М. Исхаков, И.Л. Измайлов, Р.Р. Исхаков и кандидаты исторических наук А.В. Аксанов, заочно – А.И. Ногманов, Р.Р. Аминов. Из других регионов – татарские ученые З.А. Тычинских (к.и.н.), И.Р. Атнагулов (д.и.н.). Научный форум прошел на высоком уровне и сопровождался оживленными дискуссиями. В рамках данного мероприятия состоялись публичные лекции участников конференции, в ходе которых были затронуты многие интересные проблемы, связанные с историей татарского народа.

* * *

24 сентября 2022 г. в Троицке Челябинской области прошла III-я Международная и XI Всероссийская научно-практическая конференция на тему «Расулевские чтения: ислам в современной жизни России». На данном научном форуме состоялись 5 секций, в числе которых и секция №4 «Ислам и христианство между Европой и Азией в исторической перспективе», где с докладами выступили казанские исследователи А.В. Аксанов, А.А. Гатин, Д.М. Исхаков, И.Л. Измайлов, из других российских регионов – Т.Р. Салихов, З.А. Тычинских, Р.Ш. Хакимов, Р.Н. Гизатуллин и др. В докладах были затронуты разные аспекты проблемы исследования роли ислама в России.

* * *

26 сентябрь–5 октябрьдә Урал төбәгенең шәһәр һәм авылларында VII Бөтенроссия төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумы оештырылды. Анда Россиянең төрле төбәкләреннән барлыгы 40тан артык җирле тарихны өйрәнүчеләр җыелды. Шул кысада Серов шәһәрендә шәхесләрнең татар мәдәниятенә керткән өлешләре турында «түгәрәк өстәл» үткәрелде. Монда һәм Екатеринбург шәһәрләрендә бер төркем татар җәмәгатьчелеге Муса Җәлилнең бюстына һәм һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Екатеринбургның шәһәр мәдәнияте үзәгендә төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең форумы узды. Шуннан соң форум делегатлары һәм кунаклары Чиләбе өлкәсенең Бәгәрәк Тамак авылында мәктәпнең йөз еллыгы уңаеннан оештырылган тантанада катнашты. Мәктәп диварына аның беренче директоры Җамалетдин Камаловка мемориаль такта ачылды. Биредә уздырылган конференциядә Альберт Борһановның «Татары Уральского региона: история и современность» дигән китабы тәкъдим ителде.

Алга таба Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр Троицк шәһәрендә борынгы мөселман зиратына бардылар, анда Зәйнулла Рәсүлев кабере янында җирләнгән олуг шәхесләр рухына дога кылдылар. Троицк шәһәре мәчете имамы Данис Әхмәтшин шәхесләр җирләнгән урыннарны күрсәтте, аларның эшчәнлеге хакында сөйләде. Монда XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар тормышы кайнап торган. Шәһәрдә 1911 елда сәүдәгәр Яушевлар төзеткән биналар әле дә саклан-ган. Кызганыч, Яушевларның сәүдә йорты ташландык хәлдә. Делегация Троицк шәһәрендә «Рәсүлия» мәдрәсәсендә дә булды. Заманында бу шәһәргә сәламәтлеген ныгыту өчен Габдулла Тукай да килгән була, монда бөек шагыйрьгә һәйкәл дә куелган. Соңыннан конференциядә татар зыялылары эшчәнлегенә багышланган чыгышлар ясалды.

Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумы Чиләбе шәһәренең Муса Җәлил исемендәге 81 мәктәбендә төгәлләнде. Анда Урал төбәгендә булган конференциядә чыгыш ясаучыларга рәхмәт хатлары, медальләр тапшырылды.

* * *

2020 елның 9–10 сентябрендә Казахстанның Семей-Җидепулат шәһәрендә милләт тарихы һәм татар тормышы белән бәйле гаять мөһим фәнни-мәдәни чаралар булып үтте – халыкара конференция һәм фестиваль, Татар сәнгать мәктәбенең яңа бинасын ачу, Иртыш буенда беренче халыкара сабантуй... Шулар арасында «Иртыш буе татарлары: тарих һәм хәзерге заман», дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция аерата зур әһәмияткә ия. Бу конференция Казахстандагы һәм Себердәге татарларның татар һәм казах халыклары тарихына керткән өлешен барлау максатын куйган иде, ул аны өлешчә башкарып чыкты. Җыенның резолюциясенә «Казахстанда мондый фәнни конференцияләрне даими рәвештә уздырырга, бу теманы Евразия киңлекләре контекстында өйрәнергә», дигән тәкъдим кертелде.

Ә инде «Иртыш буе татарлары: тарих һәм хәзерге заман», дип аталган фәнни җыенга килгәндә, анда Татарстаннан һәм Казахстаннан, Себердән галимнәр һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләр катнашты. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре моннан берничә ел элек Семейда һәм ул тирәдәге татар авылларында булып, 2017 елда, «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясеннән «Казахстан татарлары. Семей» дип аталган җыентык чыгарганнар иде, фәнни конференциядә аның презентациясе булды. Институт галимнәре Илһам Гомәров һәм Азат Ахунов шушы китапка таянып, халыкка Семей татарларының кыскача тарихы, тел үзенчәлекләре, халык иҗаты, күренекле шәхесләре турында сөйләделәр. «Туган җир. Родной край» журналы баш редакторы,

тарих фәннәре докторы Дамир Исхаковның чыгышы тагы да борынгырак заманнарга – Иртыш буенда монголларга хәтле чорга һәм анда яшәгән төрки халыкларның этник тарихына багышланган иде. Язучы, тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмова исә «Семей шәһәрендә Чыңгыз Айтматовның татар тамырлары», дип аталган темага чыгыш ясады. Ул танылган язучының әбисе Газизәбануның шушы шәһәрдән булуын, аның турында яңа һәм кызыклы мәгълүматлар җиткерде. БТКның татар краеведлары белән эшләү комитеты җитәкчесе, галим Альберт Борһанов Көнбатыш Казахстан, Себер һәм Иртыш буе төбәге тарихын өйрәнү, бу нисбәттән татар краеведлары алдында торган бурычлар турында сөйләде. Семей татарларының рухи һәм мәгънәви лидеры, Семейда Татар сәнгать мәктәбе ачып, шуны 30 ел буе җитәкләгән, дистәләгән халыкара фестивальләр уздырган Габделхак Ахунҗанов Семей татарларының тарихи-мәдәни мирасы турында сөйләде, анда эшмәкәрлек тә, мәгариф тә, дин дә, үзенчәлекле архитектура да чагылыш тапты. «Казан утлары» журналының баш редакторы, язучы Рөстәм Галиуллин казах әдәбияты классигы Абай Кунанбаевның бай иҗаты, әсәрләренең татар теленә тәрҗемәсе, татар-казах әдәбиятларының бәйләнешы турында кызыклы чыгыш ясады. Шулай ук җирле краеведларның, Татарстаннан һәм Себердән килгән татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең чыгышлары да бай мәгълүматлы булды, кайберәүләр онлайн да чыгыш ясадылар.

Семейда үткән фәнни конференция шуны күрсәтте – галимнәрдә дә, төбәк тарихын өйрәнүчеләрдә дә үткәннәр белән кызыксыну зур. Семейның махсус өйрәнерлек татарлар белән бәйле зур тарихы бар. Тарихчылар бу төбәктә татарларның Алтын Урда чорларыннан ук дәүләт тотып яшәүләрен яза, алар Евразиянең төп халкы була, ә Европа карталарында бу җирләр ул вакытларда ук «Tartaria» – «Татар даласы», дип күрсәтелгән. Миллер һәм Паллас кебек күренекле галимнәрнең язуынча, Җидепулат-Семипалатински атамасы да «Таш мәчетләр», «Татар-Монгол йортлары» дигәнне аңлаткан. Семейга да татар сәүдәгәр-купецлары нигез салган. XX гасыр башында биредә гөрләп эшләүче 13 мәчет, 7 мәдрәсә булган, мәчетләрнең уникесен, мәдрәсәләрнең барысын да татарлар тоткан. Сан ягыннан да монда татарлар күпчелекне тәшкил иткән. XIX–XX гасырның башында Җидепулат каласы Җидесу (Семиречье) төбәгенең дин, мәгърифәт һәм сәүдә үзәге булганлыгы билгеле.

Узган гасырларда Семейда яшәгән бертуган Мусиннар үзләренең исемнәрен шәһәр тарихына чын мәгънәсендә ташлар белән язганнар – биредә алар төзеп калдырган таш мәчетләр һәм йортлар һаман халыкка хезмәт итә, Садыйк Мусин салдырган пар тегермәне бинасы бүген завод ролен үти. Заманында Мусиннарның Иртыш елгасын тутырып

пароходлары, баржалары йөзгән, алар бiредә елга флотилиясенә нигез салган. Семейда ачык һавадагы музейны хәтерләткән Татар бистәсе бар, мондагы таш һәм карагай йортларга кимендә 150 ел, урамнарның берсе бертуган Мусиннар исемен йөртә. Кызганыч, Семейның татар тарихы хәзергә бик аз өйрәнелгән, шуңа күрә, мондый фәнни конференцияләр бик мөһим. Әмма бу тарихны шушы җирлектә яшәүче татарлар үзләре башлап өйрәнергә тиеш, чөнки алар тарихның өстендә утыралар.

*«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге*

* * *

2 октябрь көнне Чирмешән районының Кармыш авылы мәдәният йортында милләт тарихы турында мәгънәле сөйләшү булды. Бу чарада төбәк тарихчысы Дамир Таҗиевның «Кармыш мөселман мәхәлләсе (XIII–XXI гасыр)» дип аталган китабын халыкка тәкъдим итү булды. Тарих фәннәре кандидатлары Фәүзия Бәйрәмова, Рәфыйк Насыйров, Чирмешән районы башкарма комитеты рәисе Илфат Шәйдуллин, районның имам-мөхтәсибе Рамил Ибраһимов, Кармыш авылы мулласы Камил Минһаҗев, Питрәч бистәсе имамы Вәгыйз Гатин, борынгы кулъязмалар белгече Илфат Сөләйманов һ.б. китапка зур бәя бирделәр. «Дамир Таҗиевның бу китабы бер авыл турында гына түгел, ә милләт язмышы һәм тарихы турында, – диде Фәүзия Бәйрәмова. – Анда татарның бөеклеге дә, фаҗигасе дә чагыла. Милләт үз тарихында нәрсә күргән – бу авыл да үз башыннан шуларны кичергән. Башка төбәкчеләрдән аермалы буларак, автор төп игътибарын колхоз-совхоз төзелешенә түгел, ә мәчет-мәдрәсәләр, мәхәлләләр тарихына юнәлдергән, бу төбәк имамнарының язмышын ачыклауга зур игътибар биргән. Ул моны профессиональ журналист каләме белән, галимнәрчә архив материалларына таянып, милли идеологиягә нигезләп башкарып чыккан. Бу китап башка төбәк тарихчыларына да таяныч булып торачак, чөнки анда бик күп мәгълүмат бирелгән, шактый тарихи документлар беренче тапкыр халыкка тәкъдим ителә».

Дамир Таҗиев – төбәк тарихы турында татар телендәге дистәләгән документаль китап авторы. Заманында милли хәрәкәтнең үзәгендә булган, бүгенге көндә Әлмәт шәһәрендә яшәүче Дамир Таҗиев очрашуда үзе дә катнашты, иҗат планнары белән уртаклашты. Коръән уку белән башланган очрашу милләтебезгә изге догалар кылу белән тәмамланды. Соңыннан моннан 25 ел элек салынган мәчеттә бергәләп өйлә намазы укылды.

*«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге*

* * *

## АВГУСТ – СӘЯХӘТЛӘР АЕ...

*Август – ял, сәяхәтләр ае, шул ук вакытта тарихчылар, язучылар өчен эш ае да. Чөнки җәйнең матур чакларында халык белән күбрәк аралашырга, яңа әсәрләреңә материал тупларга, күбрәк йөрергә һәм күрергә дә иң уңайлы вакыт. Интернет челтәрләреннән күренгәнчә, язучы, тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмова да август аенда өендә утырмаган, Казанда корылтай тәмамланугa, туп-туры Себергә очкан... Аның белән әңгәмәбезне шул Себер сәфәреннән башларга булдык.*

### Искәр җыены – милләт җыены!

– ***Фәүзия апа, ишетүебезчә, сез Тубылда уздырылган Искәр җыенында катнашкансыз. Ул нинди җыен, ни өчен Тубылда уздырыла һәм Болгар җыеныннан нәрсәсе белән аерыла?***

– Тубылда уздырылуының сәбәбе – Себер ханлыгының башкаласы шуның янәшәсендәге Искәрдә булган. Болгар җыеныннан аермасы – Искәр җыены өч көн уздырыла, фәнни, милли, мәдәни өлешләрдән тора. Фәнни өлеше Тубылда, «Искәрнең тарихи язмышы» исемле конференция рәвешендә уза; милли өлеше – Искәрнең үзендә, халык җыены, фестиваль-бәйге рәвешендә үтә; өченче көндә инде бәйгегә йомгаклар, котлаулар, зур гала-концерт була. Быел да шулай булды. Бу – Уралның аръягында, Себердә уздырылган бердәнбер шундый фәнни-милли-мәдәни җыен. Себер татарлары җыены, милләт җыены, дисәк тә була, анда төрле милләтләрнең вәкилләре катнаша. Ул инде ундүртенче тапкыр уздырыла. Бу эшләрнең башында Төмән өлкәсенең «Мирас» төбәкара татар оешмасы рәисе Луиза Шәмсетдинова тора.

– ***Быелгысы элеккегеләрдән ни белән аерыла, үзгәреш, алгарыш бармы, үзегез өчен нинди яңалыклар, ачышлар булды?***

– Мин Искәргә беренче тапкыр 2005 елның декабрендә килдем, анда әле каккан казык та юк иде! Һәм шушы вакыт эчендә безнең күз алдында, Иртыш буенда, кара урман эчендә таш мәчет үсеп чыкты, ханнарның астаналары торгызылды, музей, кунакханә, чәйханә эшләп тора, истәлек билгеләре куелган. Иң зур яңалык һәм ачыш менә шушы. Болар барысы да, хакимият ярдәменнән башка, Луиза Шәмсетдинова һәм Дамир Ибраһимовның тарафдарлары белән башкарып чыккан олы хезмәте. Луиза бит әле Күчем ханның яраткан хатыны, Ермак атаманнары тарафыннан үтерелгән Сүзге-бикә яшәгән каланы торгызу өстендә дә эшли.

Искәр җыенында Россиянең егермеләп төбәгеннән (шулай ук Татарстаннан һәм Башкортостаннан), Казакъстанның биш өлкәсеннән галимнәр, төбәк тарихын өйрәнүчеләр, сәнгать әһелләре, иҗтимагый

оешма вәкилләре, татар зыялылары катнашты. Ә инде фәнни конференциягә килгәндә, быел төбәк тарихын өйрәнүчеләр күбрәк иде. Әйтергә кирәк, быелгы фәнни конференциядә өч профессор катнашты һәм чыгыш ясады – Казакъстаннан милләттәшебез, танылган рәссам Камил Муллашев, ул Сүзге-бикә сынының калып-эскизын да ясап алып килгән, архитектура буенча халыкара академия галиме Сагындык Жанбулатов, Кемеровадан мәдәният докторы, милләте белән хакас Надежда Ултургашева. Конференциядә үзем танылган дин әһеле, мәгърифәтче, милли сәясәтче Габдрәшит Ибраһимның рухи мирасын өйрәнү турында сөйләдем, чөнки себер татарларында, Күчем ханнан соң, ул дөньякүләм танылган шәхес. Бу күренеш Искәр җыенының офыкларын тагы да киңәйтеп җибәрде. Бу юлы Казакъстаннан килгән профессиональ казах тарихчылары себер татарлары белән уртак тарих турында сөйләделәр, уртак проектлар тәкъдим иттеләр. Хәзер Искәргә үзбәк зыялылары да ешайды, алар да себер татарлары белән уртак тамырлар эзли. Төрки халыкларның бер-берләренә тартылулары яхшы күренеш, әлбәттә, әмма Себер ханлыгы тарихын үзләренә тарту булмасын иде. Моны гел истә тотарга кирәк. Ә Искәр җыены шул бер калып белән бара, бәлки аңа ниндидер яңалыклар кертергәдер, бу хакта уйларга кирәк. Мин Искер җыенында ел да нәфис сүз бәйгесе комиссиясендә булам, быел шуңа игътибар иттем – шигырь сөйләүче балалар бик аз иде. Ике баланың берсе русча, икенчесе татарча сөйләде, узган елларда унышар бала татарча сөйли иде. Олыларның бер өлеше Муса Җәлил белән Роберт Миңнуллин шигырьләрен, бер өлеше үзләре язганны сөйләде, соңгыларына өстенлек бирдек. Омски шәһәреннән килгән «Ак калфак» оешмасы вәкилләре үз тирмәләрендә «Нәсел дәвамы» дип аталган театральләштерелгән тамаша күрсәттеләр, ул барыбызга да бик охшады, аларга да беренче урынны бирдек. Мин шунда Себердә халык театрлары булмавына игътибар иттем, икенче көнне шундый тәкъдим белән дә чыктым. Телне саклауда бөтен булган чараларны файдаланырга кирәк, ә сәхнә нәкъ шуның урыны инде!

– ***Искәр җыены дәвамлы булыр, дип уйлыйсызмы?***

– Әлбәттә, мин моны бик телим, чөнки, бу җыен себер һәм казан татарларын берләштереп, бер мәйданга туплаган бердәнбер милли-тарихи чара. Һәм ул дәвамлы булырга тиеш. Шушы эшне алып баручы Луиза сеңелемә сәламәтлек һәм сабырлыклар теләп, үзенә лаеклы дәвамчылар әзерләсен иде, дигән өметтә калам. Ул гына да түгел, бу эшне бөтен Себергә җәелдерергә кирәк. Л. Шәмсетдинованың бөтен Себер буенча таралып яткан себер татарлары белән җитәкчелек итеп эш алып барырлык тәҗрибәсе бар бит.

**Чистай җире – калалар иле!**

***– Себердәге татарлар тормышын, аларның проблемаларын күбрәк сез язганнар буенча беләбез, чөнки бөтен кеше барып җитә алмый. Әле Чистай төбәгендә булып кайткансыз. Анда ниләр ниләр ачтыгыз?***

– Мин һәр җәйне диярлек иремнең туган авылы Түбән Татар Майнасына кайтам, элек ул Биләр районына кергән, хәзер Аксубайда. Бу авылда тарих фәннәре кандидаты Рәфыйк Насыйров яши, ул урта мәктәпнең директоры. Ике тарихчы бергә туры килгәч, вакытны төбәк тарихын өйрәнүгә бирәбез, һәр җәйне берәр уртак проектны гамәлгә ашырабыз. Без инде Алексеевски районындагы Шәһре Биләрдә, Суар-Кузнечихада, Кыр Шонталасында, Чистай районының Чирүле Шонталасы авылында, Балык Бистәсе районындагы борынгы Чаллы шәһәрлеге урынында, Аксубай районының Иске Ибрай авылында булдык. Урыннарда зиратлардагы борынгы кабер ташларын барлыйбыз, шәһәрлек урыннарын тикшерәбез, мәчет-мәдрәсәләр тарихын өйрәнәбез, иске кулъязмалар һәм китаплар белән кызыксынабыз, халык белән очрашабыз. Р. Насыйров Кама аръягындагы татар тарихын бик яхшы белә, алар буенча документларны Мәскәү-Казан архивларыннан табып, күп районнарның энциклопедияләре өчен мәчет-мәдрәсәләр, дин әһелләре тарихын язды.

Бу җәйдә без Чистайның үзен һәм янәшәдәге тарихи урыннарны өйрәнергә булдык. Әлбәттә, алты мәчетле Чистайның үзен һәм аның борынгы зиратын барлап-карап чыгу өчен генә дә берничә көн вакыт кирәк. Шуңа күрә бу юлы сәфәребез күзәтү-разведка рәвешендәрәк булды, шул арада да дөнья кадәр мәгълүмат алдык. Чистай турында күләмлерәк хезмәт язарга ниятем булганга күрә, хәзергә бу төбәк турында кыскача гына мәгълүмат биреп үтәм.

Гадәттә, Чистайны рус шәһәре, диләр, ләкин бу дөреслеккә туры килми, аның нигезендә борынгы болгар-татар каласы ята, Чистай зиратындагы XIVнче гасыр кабер ташлары шул турыда сөйли. Бу кабер ташларын без дә барып карадык, алар татар тарихчылары Җәмил Мөхәммәтшин, Рәфыйк Насыйров һәм Нурулла Гариф тарафыннан җентекләп өйрәнелгән, Чистай зиратында хәтта болгар чоры кабер ташы да табылган! Димәк, рәсми тарихчылар язганча, Чистай XVIIIнче гасырда урыслар килеп урнашкач кына барлыкка килмәгән, аңа кадәр дә гасырлар буе татар каласы булып яшәп яткан, бу хакта борынгы кабер ташлары шәһәдәтлек кыла. Тарихи болгар-татар каласы Җүкәтауның да кул сузымында гына булуы бу урынның ни дәрәҗәдә борынгылыгын һәм мәдәнилеген раслый.

Үзем өчен икенче ачышым бүгенге Чистай белән бәйләнгән. Беренче карашка, бүгенге Чистай да урыс шәһәре кебек күренә – монда татар

тарихы белән бәйле урыннар туристлар маршрутына да кертелмәгән, алар турында мәгълүмат та аз. Татарлар биредә патша заманында да 30% артмады, хәзер дә шул тирә. Әмма Чистайда татар тормышы бар, һәм ул, җир астындагы дәрья кебек, өскә бәреп чыкмыйча, астан гына җәелеп ага... Һәм милләт тормышы Чистайның 6 мәчете тирәсенә тупланган – туу, балага исем кушу, никах, үлем-җеназасы, Коръән мәҗлесләре, ислам дәресләре, уку-укытулар, ураза-ифтарлар – барысы да шушы мәчетләр аша эшләнә. Ул гына да түгел, биредә мәчетләрнең эшчәнлеге милли хәрәкәт белән бергә кушылган һәм Чистай мөхтәсибенең «Ислам Үзәге» дип аталган түбә астына берләштерелгән. Без анда да булдык. XX-нче гасыр башларындагы татарлардан калган тарихи биналарның берсе бу, озак еллар кулдан-кулга күчеп йөргәннән соң, ул тагы татарларга кайтарылган. Ике катлы бу таш йортка Бөтендөнья татар конгрессының Чистай бүлекчәсе дә, хатын-кызларның «Ак калфак» оешмасы да, дин сабаклары, татар теле дәресләре бүлмәләре дә сыйган, очрашулар өчен җыйнак кына заллары, ифтарлар өчен ашханәләре дә бар. Ягъни, эшләү өчен бөтен мөмкинлекләр бар, эшлә генә.

Чистайның Татар бистәсен карап-йөреп чыктык, бу, чын мәгънәсендә, ачык һавадагы музей бит! Милләт тарихы анда ташлар белән язылган! Менә Гаяз Исхаки укыган мәдрәсә бинасы, Закир хәзрәт Камалов салдырган, тоткан, эшләгән мәчет-мәдрәсәләр, хатын-кызлар өчен мөселман мәктәп-мәдрәсәләре, Тукайның сөйгән кызы Зәйтүнә яшәгән йорт... Бу тарихи биналарның берникадәре бүген дә милләткә хезмәт итә, кайсылары инде хәрәбә хәлендә җимерелеп ята, кайберләре бөтенләй юкка чыккан... XIXнчы гасыр азагында Ризаэддин Фәхреддин, Гаяз Исхакый, Фатих Кәрими, Гафуров-Чыгатай, Фоат Туктаров һәм тагы йөзләрчә татарлар белем алган «Камалия» мәдрәсәсе бинасында бүген ял һәм үсеш үзәге. Ике катлы бу таш йортта балалар өчен төрле түгәрәкләр эшли, матур гына милли музейлары бар. Узган гасырның 80-нче елларында Казан, Уфа, Самара губерналарыннан берьюлы дүрт йөзләп шәкерт укыган, гөрләп торган бу йортта хәзер тынлык... Әлбәттә, күңел монда яңадан мәдрәсә һәм татар мәктәбе булуын тели, әмма моның өчен халык белән дә, хакимият белән дә нык эшләргә кирәк шул!

– ***Чистайда «Камалия» укулары да уза икән, дип ишеткән идек. Мөмкинелек булса ул укуларда нәрсәләр сөйләр идегез?***

– Минем ул укуларда булганым юк шул, сезнең кебек, ишетеп кенә беләм. Әмма анда катнашсам, әйтер сүзем бар. Нигәдер, Мөхәммәтзакир хәзрәтне тәрикатьче суфый ишан буларак кына өйрәнәләр. Югыйсә ул бит шушы төбәкнең рухи юлбашчысы, лидеры булган. Чистайда хан сараедай мәчет-мәдрәсәләр салдырган, ярты гасырга якын шунда имам-

лык иткән, китаплар, дәреслекләр язган. Аның 2-нче гильдияле купец, ягъни, сәүдәгәр булуын да онытмаска кирәк, дөньясын алып барганда, ул кеше кулына карап тормаган, киресенчә, башкалар аның кулына карап торган! Гомеренең ахырында ул чак кына сөргенгә сөрелмәгән, сөрелгән дә булыр иде – үлеп котылган. Сәбәбе – үзенең мәдрәсәләрендә урыс телен укытудан баш тарткан, цензурага каршы булган, шул рәвешле булса да милләтен һәм өммәтен урыслаштырудан саклап калырга тырышкан. Ул чорда рәсми имамнар арасында ачыктан-ачык патша хакимиятенең урыслаштыру сәясәтенә каршы төшүчеләр сирәк булган, 80 яшьлек Закир хәзрәт шуңа көч тапкан. Аны шул яктан да өйрәнергә кирәк, дип уйлыйм. Ул кызларын милләтнең иң затлы кешеләренә – Муса Бигиевка, Әмирханов, Акчуриннарга кияүгә биргән, аларның никах туйларында аның йорты милләт мәҗлесенә әйләнгән. Габдрәшит Ибраһимовның искә алуынча, «Иттифак» фиркасенең оеткысы да Муса Бигиевның Чистайдагы туенда салына.

– ***Сезнең «Гөләйза» романында да төп вакыйгалар, судлар Чистай шәһәрендә бара бит. Анда эпизодик төстә яшь Закир хәзрәтнең дә образы бар. Бүгенге Чистайда романда сурәтләнгән нәрсәләр сакланган?***

– Беренче чиратта, тарихи биналар, әлбәттә – Татар бистәсе, «Нур» мәчете, чиркәүләр, төрмәләр, казна йортлары... Гөләйза тезләнеп намаз укыган агач мәчет янган инде, 1854 елда аның урынына менә шушы мәчетне салганнар, ул шул заманнан бирле туктаусыз халыкка хезмәт итә. Беләсезме, Чистайда биналар гына түгел, иман өчен көрәш рухы да сакланып калган! Мондагы халык әле Нурулла хәзрәт Мөфлихуновның хак дин өчен арысландай көрәшкән вакытларын хәтерли, сабыр һәм тәкъва Габделхак хәзрәт Саматовны сагынып искә ала, инде безнең чорда нахакка гаепләнеп, иман өчен Себер төрмәләренә сөрелгән Чистай мөселманнарына дога кыла... Чистай татарлар өчен гади урын түгел ул! Ул элек-электән Чулман аръягында татарларның төп мәгърифәт үзәге, Казаннан кала икенче зур шәһәр булган... Аның бу данын яңадан кайтарырга кирәк. Шәһәрнең борынгылыгын, аның татарлар өчен гаять әһәмиятле урын булуын тарихчылар исбатлап, җитәкчеләр каршына салырга, тарихи биналарны саклап калырга, торгызырга, Чистайга яңа рух – милли рух бирергә кирәк, ул моңа лаек!

– ***Шулай ук Чистай тирәсендә тарихи яктан игътибарга лаеклы шактый урыннар бар дип беләм.***

– Бу мәсьәләдә Чистай ялгыз түгел, аның тирә-юнендә борынгы кала урыннары, хан зиратлары, шәһәрлекләр таралып ята, болар инде тарихчылар тарафыннан исбатланган. Чистайдан ерак булмаган Җүкәтау

(Юкәтау) үзе генә дә ни тора! Мең еллык борынгы болгар шәһәре бит ул! Аның чәчәк ату чоры Алтын Урда дәүләте заманнарына туры килә, Җүкәтау бәклеге (кенәзлеге) аның составында да әле шактый вакыт үзенең мөстәкыйльлеген саклый. Хәтта үзенең Кирмәне дә булган, шәһәр бистә һәм авыллары белән 150 гектар мәйданны биләгән. Чулман аша кичү урыны да Җүкәтау турында булган, елгадагы сәүдә юлын да шәһәр хакимияте үз кулында тоткан. Гаять әһәмиятле сәүдә үзәге буларак, Җүкәтау XIV-нче гасырда ук борынгы урыс кулъязмаларында Болгар белән бергә искә алына, ул шулай ук 1360, 1375-нче елгы Көнбатыш Европа карталарында да күрсәтелгән. Чулман буенда бик җайлы урында утырганлыктан, шәһәр XIV–XV-нче гасырларда берничә тапкыр урыс ушкуйниклары-субасарлар тарафыннан талана, әмма ул вакытта әле юкка чыкмый. Җүкәтау шәһәренең әле Казан ханлыгы чорында да яшәгәнлеге билгеле, менә инде ул басып алынгач, Кама аръягындагы татар кала һәм салаларына да кара көннәр килә. Җүкәтау шәһәре дә талана, халкы кылычтан үткәрелә, тарихи кала әкренләп җир белән тигезләнә...

– ***Шул хәтле данлы тарихи урын сакланамы, бу юнәлештә нинди эшләр алып барыла? Музейлары бармы, туристлар йөриме?***

– Анда хәзер берни юк... Ялан кыр... Җүкәтауның бер өлешенә теге заманнарда элеватор салганнар, шактый тарихи җирләр шуның астында калган. Дөрес, тарихчылар бу урынны озак еллар буе өйрәнгәннәр, казыганнар, күп нәрсәләр тапканнар. Алар ярдәмендә, федераль дәрәҗәдәге бу тарихи истәлек ТР Министрлар кабинеты карары белән, 1999 елның 20 августында «Тарихи-мәдәни тыюлык (заповедник)» дип игълан ителгән. Әмма бу карарны тормышка ашыру өчен берни дә эшләнмәгән. Монда, кичекмәстән, музей-тыюлык эшләп куярга кирәк, биналары, штатлары белән. Җүкәтауны туристлар маршрутына да кертергә вакыт, мондагы борынгы тарих белән гүзәл табигать беркемне дә битараф калдырмас иде. Ярты дөнья туристлык белән яши, акча эшли, без булганын да күрсәтә белмибез...

– ***Менә Аркаимны буш далада төзеп куйдылар, юктан бар иттеләр... Ә бездә шундый борынгы тарих һәм шуның кадере юк! Тарихны өстеннән таптап йөрибез, ә шуны зурлап күрсәтә белмибез.***

– Аркаим тарихын да өйрәндем, ул бөтенләй башка урында, шул ук Чиләбе өлкәсенең Варна-Мәчәли исемле татар бистәсе янында, борынгы татар төрбәсе тирәсендә булырга тиеш иде. Аның тирә-ягында йөзләрчә чакрымнарга сузылган «Калалар Иле» дип аталган тарихи урын бар, ул да төрки-татар тарихы белән бәйле. Шул борынгы тарихны төрки-татарларга бирмәс өчен, музей-комплексны Аркаим елгасы тирәсенә китереп салдылар һәм әкият сөйләп, акча эшли башладылар... Чистай-Җүкәтау

тирәсендә дә «Калалар Иле» дип атарлык урыннар күп. Әйтик, без Чистай районының Татар Сарсазы авылында булдык, аның янында халык телендә «Ханнар зираты», дип аталган урын бар. 1854-нче елгы авыл җирләре картасында ул Ташбилге, дип аталган, анда йөзгә якын борынгы кабер ташы булган. Хәзер исә нибары 13 генә калган, алар XIV гасырга карый. Татар Сарсазы авылы зиратында да 1320 елгы кабер ташы бар, шулардан чыгып, авылга кимендә 700 ел, дип әйтергә була, бәлки әле күбрәктер дә, чөнки галимнәр бу яктагы татар авылларын болгар чоры белән бәйлиләр. Татар Сарсазы белән Иске Раман авылы арасында «Әйшә каласы», дип аталган тарихи урын да бар, ул ике елга кушылган чатта утрау булып урашкан. Бу урын да ханнар исем-атамалары белән бәйле, бәлки янәшәдәге Ханнар зираты да аларныкы булгандыр. Р. Насыйровның әйтүенчә, бу төбәк, «Калалар Иле», дип аталырлык икән! Уйлап карагыз, 20 чакрым саен кала. Нығытылган, сакланган хакимият үзәге! Сүз Болгар-Алтын Урда чорлары турында бара: Биләр – Түгәрәк Кала – Әдәмсу – Чуваш Ялтаны – Изгар – Әйшә – Тубылгытау – Җүкәтау – Чистай... Болар барысы да галимнәр тарафыннан өйрәнеп, тарих өчен ачылган урыннар. Әмма халык һәм җитәкчелек үзенең нинди бөек тарих өстендә утыруын, таптап йөрүен белми шул, белсә, аңа бөтенләй башкача карар иде, кадерен белер иде... Чистай төбәге тарихчы-галимнәр тарафыннан бераз өйрәнелсә дә, үзенең лаеклы бәясен һәм урынын алмады әле. Чын мәгънәсендә, «Калалар Иле», Ханнар җире булган бит ул. Һәм моны исбатлау бүгенге көн галимнәренә, милләтнең үзенә кала...

**Авылларда – милләт тарихы!**

***– Узган ел «Казан утлары» журналында милләткә «Кыйссаи Йосыф» дастанын кайтарган, әмма органнар әмере буенча, үзебезнекеләрнең кара көнчелеге сәбәпле, Казан дәүләт университетыннан куылган олуг галим Җәвад Алмаз турында күләмле хезмәтегезне тетрәнеп укыган идем. Быел Самара өлкәсенә шул шәхеснең туган авылына баргансыз икән, дип ишеттем.***

– «Татар галименең аянычлы язмышы», дип аталган язма турында әйтәсез... Әйе, шушы бер ел вакыт эчендә мин Җәвад Алмаз турында шактый яңа мәгълүмат тупладым. Р. Насыйров ярдәмендә, аның туу турында белешмәсен эзләп таптык, ул метриканы Җәвад Алмазның атасы Ногман хәзрәт үз кулы белән тутырган. Ул документтан күренгәнчә, аның чын исеме Мөхәммәтҗәвад, туган елы – 1915, 15 июль, туган урыны, үзе автобиографиясендә язганча, Самара губернасының Челно-Вершинский-Чаллыбашы районы, Благодаровка-Хөсәен авылы. Ә Татар энциклопедиясендә Җәвад Алмаз хәзерге Яңа Чишмә районының Чертуш авылында 1916 елда туган, дип язылган. Чертушта аның атасы Ногман хәзрәт туган, ул да бик

билгеле кеше булган. Аларның нәсел фамилияләре – Манигиннар. Ногман хәзрәт 1908 елда Благодаровка-Хөсәен авылы мәчетенә указлы мулла итеп билгеләнә, балалары шунда туа. Ул авыл Татарстанга терәлеп тора, узган гасырларда анда Кизләү мәдрәсәсеннән дә күчкәннәр. Халыкның сөйләвенчә, бу авылның җирләре Николай патша солдатларына бүләк итеп бирелгән, имеш, шуңа рәхмәт йөзеннән, Благодаровка дип аталган икән. Ә татарлар аны Яңа авыл, дип тә, авылга нигез салучы исеме белән Хөсәен дип тә атыйлар. Теге заманнарда авылның бер башында руслар да яшәгән, хәзер инде татарлар гына калган, аларын да бармак белән генә санарлык. Авылда 1907 елны агач мәчет салынган, ул совет заманында да ябылмаган, эшләп торган. Башлангыч мәктәп искергәч, районнан шушы мәчетне мәктәп итәргә кушканнар. Мәчетне бирмәс өчен, авыл халкы бер җәй эчендә мәктәп салып чыккан. Хәзер инде авылда балалар да юк, мәктәп тә юк, ә мәчет һаман тора! Аның 100 еллыгын уздырганда, бөтен тирә-яктан халык җыела, Татарстаннан да киләләр. Бу мәчет шунысы белән дә гаҗәпләндерде, аның урамнан керә торган ишеге бик тәбәнәк, аннан башны һәм гәүдәне бик аска иеп кенә керергә була. Бу үзенә күрә суфый традициясе булырга тиеш, бәндәнең Аллаһ каршында түбәнчелекле булуын күрсәтү өчен... Мәчетнең эче дә бик үзенчәлекле – теге заманнардан калган агач мөнбәр, кирпеч мич, түр диварда Кизләү тәрикате силсиләсе, аны Мәккәдән күчереп алып кайтканнар, диделәр. Әйткәнебезчә, Җәвад Алмазның этисе Ногман хәзрәт биредә имам булган, әмма силсиләдә аның исемен күрмәдек. Зиратта артык борынгы кабер ташлары юк, әмма XIX гасыр азагында туып, XX гасыр урталарында үлгән дин әһелләренең каберләрендә искечә язылган ташлар бар.

Әлбәттә, Благодаровка-Хөсәен авылында мәчет имамы Ногман хәзрәтне дә, аның улы Җәвад Алмазны да инде белмиләр, хәтерләмиләр. Алай да, Ногман хәзрәтнең беренче хатыныннан туган кызының баласын хәтерләүчеләр булды. Авыл мәчетендә сакланган борынгы китапларның күпчелеген Самараның Җәмигъ мәчете музеена алып киткәннәр, бәлки анда Ногман хәзрәтнең үз кулы белән язылганнары да булгандыр, чөнки ул каләм иясе дә булган бит! 1959–1960 елларда, Казан дәүләт университетында укытканда, Җәвад Алмаз үзе дә Самара өлкәсендә экспедициядә була, Норлат районының Киекле авылында «Кыйссаи Йосыф» дастанының тулы нөсхәсен таба, ул әле XIX-нчы гасыр урталарында ук Кизләү мәдрәсәсендә күчереп язылган була. Җәвад Алмаз үзенең туган якларына килә, әмма кем икәнлеген әйтә алмый, чөнки сәяси репрессияләрдән куркып, ул университет анкеталарында үзен ятим бала дип язган була...

Хәзер бу авыл инде бик кечерәйгән, халкы таралып беткән диярлек. Монда яңа йортлар юк, һәрхәлдә, авылда яшәр өчен шартлар бар, га-

зы-юлы кертелгән. Алай да, гает бәйрәмнәрендә халык туган авылына җыела икән, ул чакта мәчет тә гөрләп эшләп тора, узган заманнарны хәтерләтеп, манарадан азан яңгырый, намазлар укыла. 115 ел бер тапкыр да ябылмаган Хөсәен авылы мәчете һаман милләткә хезмәт итә, урман-далада берьялгызы татарлыкны һәм мөселманлыкны саклап тора...

*– Гадәттә, язучылар клубларда, китапханәләрдә, мәктәпләрдә халык белән очраша, ә сез мәчетләрне сайлыйсыз. Бу ни өчен шулай, үзегез намазлы булгангамы яки башка берәр сәбәбе бармы?*

– Әйе, мин мәчетләрдә рәхәтләнеп халык белән очрашам, аларга татар тарихы, милләт тормышы турында сөйлим. Әлбәттә, мәчетләргә дә болай гына килеп кереп, чыгышлар ясап булмый, аның өчен имамның яки мөхтәсибнең рөхсәте кирәк. Тукай районының Калмия һәм Теләнче Тамак авылларында, шулай ук Питрәч мәчетендә зур-зур очрашулар уздырдым.

Аеруча, Теләнче Тамак авылы турында әйтеп узасым килә. Заманында үзе район үзәге булып торган, ике мәчете, данлыклы мәдрәсәсе, бөтен тирә-юньгә танылган шәхесләре, эшмәкәрләре, мәгърифәтчеләре белән дан казанган бу тирәдәге иң зур татар авылларының берсе булып торган ул. Хәзер дә анда ике мәчет, мәдәният йорты, китапханә, картлар йорты, төрле иҗтимагый объектлар эшләп килә. Әле ул атаклы Хәлфиннар авылы да бит! Хәлфиннар заманында Теләнче Тамак авылында ике мәчет һәм таштан ике катлы ир балалар мәдрәсәсе, агачтан кызлар мәдрәсәсе салдырганнар һәм тотканнар. Моннан кала алар үз авылларында һәм тирә-юньдә дистәләгән ашлык амбарлары, таш биналар, складлар, тегермәннәр, кибетләр тотканнар. Бу төбәктә ашлык сәүдәсе алар кулында булган. Бик күп шәкертләргә һәм шәхесләргә ярдәм иткәннәр. Хәлфиннар нәселендә муллалар, дәреслек язучылар да булган. Алар хәтта Бөгелмәдән Чаллыга тимер юл салдырырга җыеналар, бу турыда 1916-нчы елны Николай патшага мөрәҗәгать итәләр. Әмма революция сәбәпле, тимер юл салынмыйча кала, Хәлфиннарның да бар байлыкларын тартып алалар, үзләрен сөргеннәргә сөрәләр, юк итәләр...

*– Бу авылда Хәлфиннарның нәселе калганмы соң?*

– Әлбәттә, Хәлфиннарның нәсел дәвамчылары биредә дә, Казанда, Чаллыда, башка шәһәрләрдә дә яшиләр. Дөрес, репрессияләр сәбәпле, алар фамилияләрен бабаларыннан аталарына алыштырырга мәҗбүр булганнар. Әйтик, Хәлфиннарның оныгы Вәсим, 1937-нче елда атып үтерелгән атасы Әхмәтзәкинең исемен фамилия итеп алып, Зәкиев булып китә. Ул гаиләсе белән Теләнче Тамак авылында яшәгән, хәзер инде вафат. Авылда аның хатыны, 93 яшьлек Шәмсеруй апа яши. Ул гомер буе укытучы булып эшләгән, балаларга татар һәм алман телләрен укыткан, олыгайган көннәрендә, дин ирегe килгәч, халыкка дин сабагы биргән. Мин

бу авылга килгән саен Шәмсеруй апа белән очрашам, бу юлы да янына кереп, хәлен белдем. Шунысын да әйтәсем килә, Вәсим абый белән Шәмсеруй апаның олы уллары Фәрит Зәкиев – татар милли хәрәкәте җитәкчеләренең берсе, башка балалары да билгеле эшмәкәрләр, танылган кешеләр. Ә 1938-нче елда, әтисе атып үтерелгәннән соң туган Әүфәр Зәкиев – танылган төзүче-инженер, Казан шәһәренең яртысын ул төзи, бу хезмәте өчен хәтта Тукай бүләгенә ия була, Казанда аның исемендәге урам да бар! Күрәсез, яхшы орлыктан яхшы үсенте чыга, ул яхшы җимеш бирә, Теләнче Тамактан Хәлфиннар нәселе моның ачык мисалы. Алай да, Теләнче Тамактан күңелдә бер төер калды, ул да булса – Хәлфиннарның таланган, җимерелгән утарлары һәм янына тирес китереп өйгән җимерек таш мәдрәсә... Моны күңел берничек тә кабул итә алмый.

Әнисе ягыннан Хәлфиннарга барып тоташкан тагы бер атаклы шәхес турында әйтеп үтәсем килә, ул – Габделхәмит Зөбәеров. 1897-нче елда Теләнче Тамак авылында туган бу татар кешесе, бәхетенә, Ризаэддин Фәхреддин ярдәмендә, 1916-нчы елда Төркиягә укырга китә һәм шунда кала. Ул биредә зур галим, тарихчы-этнограф булып җитешә, күп китаплар яза, Анкарада ЮНЕСКОның ачык музейлар директоры вазыйфасын башкара, бабасының фамилиясен алып, дөньяга Хәмит Зөбәер Кошай, булып таныла. Күрәсез, бер татар авылы гына да дөньяга күпме шәхесләр биргән!

– ***Әйе, милләтне милләт иткән шәхесләр турында сөйләп тә, тыңлап та, язып та, укып та бетерерлек түгел. Шуларны барлап, өйрәнеп, милләткә яңадан кайтаруыгыз өчен зур рәхмәт сезгә! Шушы бер ай эчендә генә дә күпме йөргәнсез, күпме күргәнсез! Сезнең бу сәфәрләрне оештыруда милли оешмаларның ярдәмнәре тияме?***

– Себер сәфәрем генә конгресс катнашында булды, калганнарын барысын да үзем оештырдым. Минем язучылар берлеге белән очрашуларда йөргәнем юк. Ул бер көнлек барып-кайтуларда әллә ни эшли дә алмас идем. Татар тарихын һәм милләт тормышын өйрәнү өчен, кайбер урыннарга кат-кат барырга, анда атналар, хәтта айлар буе яшәргә туры килә. Кая барсам да, минем якын дусларым, яхшы танышларым бар, урыннарда күп эшләремне алар ярдәмендә башкарам. Мин аларга тарихларын язып бирәм. Бу эшне яратып һәм ихластан, җиренә җиткереп эшлим. Сентябрь аенда да юлда булдым – Новосибирскида һәм Казакъстанның Семи шәһәрендә очрашулар уздырып кайттым, алары турында аерым язармын әле, ин ша Аллаһ! Шулай гел хәрәкәттә яшәргә, милләтне яңа язмалар белән сөендерергә насыйп итсен!

*Әңгәмәне Рәзинә Хәсәнова әзерләде*

Милли ашлар, сәламәтлекне саклау юллары

Национальная кухня, пути сохранения здоровья

## АЗНАКАЙ ТӨБӘГЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ РИЗЫКЛАРЫ

### *ИТЛЕ ЗУР БӘЛЕШ*

Башта төче камыр эшләнә.

***Камыр өчен*** 1 йомырка, 100 г. атланмай, 50 г. үсемлек мае алына, 200–250 мл. су кушып, яхшылап болгатыла. Аннары якынча 800–900 г. он салып, камыр басыла.

***Эчлек:*** симез ит (сарык, сыер, каз, үрдәк һ.б. ите) – 1,5–2 кг., бәрәңге – 1,5–2 кг., 3–4 башлы суган, шулпа – 400 мл., тәменчә тоз, борыч алына.

Камыр икегә бүленә, якынча 5 мм. калынлыкта таба кырыеннан бераз чыгып торырлык итеп җәелә. Ит белән бәрәңге, шакмаклап туралып, бергә кушыла. Янә ваклап туралган суган, тоз, борыч кушып болгатыла. Әзер эчлек табадагы камырга өеп салына һәм камырның кырыйлары күтәртеп куела. Аннары кечерәк камырны җәеп, бәлешнең өстенә ябыла, читләре чеметеп ябыштырыла. Капкачын уртадан тишеп, калган камырдан бөке әвәләп, каплап куела.

Бәлешнең өстен майлап, мичкә тыгалар. Мич кызу булып, бәлешнең өсте көя башласа, фольга яисә төче камырдан махсус капкач ябарга мөмкин. Бәлешне 1–1,5 сәгать тотканнан соң, мичтән алып, бөкесен ачып алдан әзерләп куйган шулпа салалар, бөкесен ябып, пешеп чыкканчы мичтә тоталар.

### *БАВЫРСАК*

1–2 килограмм бавырсак әзерләү ысулы.

***Камыр:*** 5 йомырка, 2 аш кашыгы үсемлек мае, бер чеметем тоз, пычак очында чәй содасы, 1 чәй кашыгы шикәр комы.

***Әзерләү ысулы:*** Йомыркаларны алдан туңдыралар. Туңган биш йомырканың кабыгын әрчеп, бүлмә температурасында эретергә кирәк. Аннары алар өстенә 2 аш кашыгы үсемлек мае, бер чеметем тоз, пычак очында чәй содасы, 1 чәй кашыгы шикәр комы салына һәм яхшылап болгатыла. Шушы массага он кушып, сыек кына камыр ясала. Аннан тактага бушатып, аңа әз-әз генә он куша-куша, камыр үзләндерелә. Камыр әзер булгач, бишкә бүлеп, һәр кисәк (куллар белән тактада әвәли-әвәли) озынча таяк рәвешендә сузалар, аннары һәркайсы пычак белән 2–3 сантиметр зурлыкта, ромб рәвешендә кыеклап кисәкләргә киселә.

Пешерү ысулы: Иң элек киң зур тимер савытка (эмаль савыт ярамый) салкын үсемлек мае, алдан аерым савытта эретелгән туңмай белән бер стакан салкын су салып болгатыла. Су бавырсакларны күпертү һәм пешерү өчен кирәк. Бавырсак пешәсе май кайнап торырга тиеш түгел. Май җылына башлагач, бавырсаклар төпкә ябышмасын өчен, савытны әкрен генә селкетергә. Май кайнап чыккач, бавырсакларны әкренләп болгатып торырга. 2–3 сантиметр зурлыктагы камыр кисәкләре күперергә тиеш.

Сироп: Төшләрне баллау өчен махсус сироп әзерләнә. Ярты стакан суга бер стакан песок салып кайнатыла, 3–4 минут кайнагач, 3 аш кашыгы бал салып утта тотыла. Кайнаган сироп ябыштыра башлауга әзер санала. Төшләр зур табакка салына, аларның өстенә кайнар сироп коела, тиз генә болгатып, матур итеп өелә.

### *ТАБИКМӘК*

Пешерү өчен 700 мл. җылымса сөткә 1,5 чәй кашыгы коры чүпрә, 4 аш кашыгы көнбагыш мае, 4 аш кашыгы шикәр комы алына, тәменчә тоз салып, яхшылап болгатыла.

Шуңа 700 г. чамасы манный ярмасы, чама белән он салып, куерак камыр ясала. Соңыннан 1 йомырка салып, яхшылап туглана һәм 1,5 сәгатькә җылы урынга кабартырга куела.

Аннан 3 йомырка күпертеп алына, кабарган камырга кушып, тагын ярты сәгатькә калдырыла.

Яхшылап күтәрелгән камырга 700 мл. кайнаган сөт өстәп (аңа чеметеп кенә чәй содасы да кушарга кирәк), 20 минут ял иттерелә, соңыннан майлы кызган табада пешерелә.

Ике яклап та ак май белән майлап (теләгән кеше көнбагыш мае да куша ала) табынга чыгарыла.

### *КАБАК СУЫ*

Кабакның кабыгы әрчелә, эче алына һәм шакмаклап турала. Кәстрүлгә салып, өстен күмерлек итеп су салына, кабак йомшаганчы пешерелә. Пешергәндә бер-ике лимон яки әфлисун, яки икесен дә кушып кайнатырга мөмкин. Кабак йомшаргач, лимон белән әфлисун сөзеп алына, калган масса миксер яисә блендер ярдәмендә вакланып, пюре хасил итә. Менә шул кабак пюресына теләгән сыеклыкта су, шикәр комы өстәп, кайнатып чыгарыла һәм чиста банкаларга тутырып, калай капкач белән ябып куела.

*Ризык әзерләү ысулларын*
*Ә.К. Булатова, А.Ә. Бәдртдинова язып алдылар*

# УКРЕПЛЯЕМ ИММУНИТЕТ

В течении жизни у каждого человека возникают периоды, когда иммунная система ослабевает, и в это время намного легче заболеть. К счастью, природа обеспечила нас достаточно большим арсеналом лекарственных растений, минералов и витаминов, которые улучшают иммунную систему. Вот некоторые из них.

Чеснок. Это чудесное растение не только повышает иммунитет, но также обладает противовоспалительными свойствами, действенно уменьшает уровень холестерина, обладает свойством разжижать кровь. Способствует понижению артериального давления вследствие снижения уровня холестерина и жиров в крови.

***Эхинацея.*** Является активным иммуностимулятором, обладает антивирусным и антибактерицидным свойствами.

***Астрагал.*** Великолепный стимулятор, обладает иммуновосстанавливающими и противораковыми свойствами, может быть использован в борьбе со СПИДом.

***Кукуруза.*** Это привычное всем растение обладает хорошими иммуновосстанавливающими свойствами. Также кукуруза незаменимый ингредиент в почечных сборах при мочекаменной болезни.

***Женьшень.*** К сожалению, по-настоящему действенен только женьшень, растущий в естественных условиях, выращенный же на плантации не обладает и 20% его эффективности. Способствуют укреплению иммунитета также витамин С, бета-каротин и витамин В6.

## При простудных заболеваниях

Хочу порекомендовать некоторые старинные рецепты от простуды.

***Чай из плодов шиповника с мёдом*** укрепляет организм и является хорошим профилактическим средством простудных заболеваний.

***Пустырник и корень цикория обыкновенного*** в равных долях заварить крутым кипятком, как чай, дать настояться и принимать при простудных заболеваниях три раза в день по полстакана.

***Малина.*** Все знают, что малиновое варенье при простудных заболеваниях является одним из старинных лечебных средств. Не только варенье, но и настой из листьев и стеблей малины тоже является хорошим потогонным средством. Отвар из листьев применяется при лечении бронхита, ларингита и как отхаркивающее.

***Полынь.*** В Сибирских деревнях при «жёсткой» простуде и сильном кашле применялось такое средство: 20 г. полыни настоять в полулитре водки (чем дольше, тем лучше) не менее 24 часов. Принимать по столовой ложке три раза в день и перед сном.

***Сок калины.*** Введённый в ноздри по 3–4 капли утром и вечером сок калины, во много раз действеннее нафтизина при любом насморке, включая и аллергические риниты, синуситы.

## На все случаи жизни

***При ангине.*** Надо выжать сок 3-х лимонов, добавить стакан теплой кипячёной воды, и выпить этот кислый коктейль в течение часа, можно и быстрее. Одновременно надо нарезать лимон дольками и держать во рту эти дольки, медленно рассасывая, так, чтобы лимонный сок попадал на миндалины. Повторять процедуру каждые 15 минут.

***От судорог.*** В течение недели употреблять натощак по 1 ст. ложке мёда, запивая стаканом кефира.

***Против кашля.*** Возьмите по 1 стакану мёда, сока черной редьки, свеклы, моркови, всё смешайте в стеклянной банке и принимайте по 1 ст. ложке 3 раза в день, но смесь не глотайте сразу, а подержите её 3 минуты во рту. Храните смесь в прохладном месте.

***Для лечения варикозного расширения вен.*** Наполните на треть пол-литровую бутылку берёзовыми почками и доверху залейте водкой. Настаивайте 10 дней, периодически встряхивая. Настойкой смазывайте больные места.

***От усталости.*** Возьмите ягоды брусники (1часть) и плоды шиповника (3 части). Залейте 0,5 литра кипятка 100 г сбора и кипятите 10 минут. Отвар настаивайте 30 минут. Принимайте по 0,5 стакана 2 раза в день.

***При герпесе на губе.*** Как только почувствуете на губе боль (начало герпеса), сразу же, не теряя времени, помажьте это место зубной пастой (любой).

## При атеросклерозе

При атеросклерозе особенно рекомендованы яблоки, груши, сливы, лук, свекла, помидоры, тыква. Перестаньте пить чёрный чай, заваривайте травку, или шиповник, делайте компот из ягод. Ну а самую большую пользу приносит специальный сок, рекомендованный для больных атеросклерозом. Нужно взять 230 г морковного, 60 г чесночного и 170 г свекольного соков. Всё смешать и принимать по трети стакана 2 раза в день. После такого напитка начинаешь себя чувствовать на десяток лет моложе. Если решили всерьез бороться с атеросклерозом, придётся отказаться от многих своих привычек, пересмотреть свои взгляды на жизнь. Но это не такая высокая цена за здоровье.

## Целебные веники

***Березовый веник.*** Издавна известны целебные свойства берёзы. Отваром берёзовых листьев лечат раны, а воздух в берёзовом лесу по чисто-

те и стерильности не уступает воздуху в операционной. Можно приготовить хороший веник из любого вида берёзы, но лучше всего подойдут ветки берёзы плакучей и берёзы кудрявой. Под воздействием горячего пара листья этих веников не становятся скользкими. Веники наиболее гибкие и послушные, ими легко париться. Старики говорили: выбирай веник в берёзовой роще, а берёзку – возле воды. Они считали, что веник из такой берёзы будет особенно гибким. Во всяком случае, при выборе берёзы нужно обратить внимание на её листья. Верхняя поверхность листа должна быть бархатистой, словно покрыта пушком. Именно такой лист и нужен для веника.

***Дубовый веник*** не уступает берёзовому по популярности и он более прочен. Широкие листья дубового веника хорошо нагнетают пар. В коре дуба много дубильных веществ, которые оказывают лечебное воздействие на различные кожные заболевания. Дубовыми вениками парили воинов перед битвой, они давали силу. Ветки для веника лучше всего заготавливать с дуба, под которым растут большие лопухи. Листья такого веника почти не облетают. Целебные свойства дубовых листьев очень велики. Простое пребывание в дубовой роще нормализует давление у гипертоников. Дубовые веники лучше всего заготавливать в августе–сентябре.

***Эвкалиптовый веник*** скорее лечебный, чем парильный. Вероятно, и вам, читатель, при простудных заболеваниях врач прописывал ингаляцию с эвкалиптовым листом или настойкой эвкалипта. Если в парной побрызгать на стены настоем эвкалипта, а потом этот настой плеснуть на кошелку, получится самая настоящая ингаляция, при этом дышать нужно носом через веник. Наиболее целебен лист эвкалипта в ноябре–декабре. Веники лучше всего готовить в августе. Недостаток эвкалиптового веника в том, что ветки слишком тонкие, чересчур гибкие. Поэтому эвкалиптовые ветки укладывают в середину берёзового веника. И целебный эффект остаётся, и париться удобно. Следует помнить, что для веника годится не любой эвкалипт – нужен такой, у которого ветки гибкие, как у ивы.

***Хвойный веник*** – экзотика для больших любителей. Пихтовый и кедровый привозят из Сибири, а вот еловый доступен всем. Любой хвойный веник нужно заваривать в крутом кипятке 20–25 минут. Если этого не сделать, будете не париться, а мучиться. После запаривания хвойный веник становится мягким, но тут следует проявлять определённую осторожность. Сначала нужно хорошо распарить кожу, пролежав в парной 5 – 7 минут. Кожа распарится и станет менее чувствительной к уколам хвои. В хвое содержится сильно пахнущее вещество – живица. Ещё отец медицины Авиценна говорил, что живица применяется внутрь при язвах, прыщах в легких, застарелом кашле. Это самое сильное средство для

успокоения головной боли. В народной медицине живицу применяли при язвах на коже, фурункулёзе, мокнущей экземе. Раны при применении живицы заживают в 2–3 дня и без боли. Лечат ею свищи, ожоги и много других болезней. Еловый веник можно заготавливать круглый год. Тем, кто не сможет париться хвойным веником, можно положить его на полок и просто полежать на лапнике. Польза будет немалая.

